Безнен МИРАС

07

июль 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Быел «Изге Болгар җыены»на 55 мең кеше җыелды. Идел буе Болгар дәүләте чорында борынгы бабаларыбызның рәсми рәвештә ислам динен кабул итүе истәлегенә багышланган җыен егерме җиденче ел рәттән оештырыла. Быел ул Россиядә ислам дине үсешенә юнәлтелгән мөһим килешүләр төзелүе һәм Болгар җиренең бай тарихын танытучы вакыйгалар белән истә калды.

Изге Болгар юллары...

Р.Кадыйров фотолары

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
07(42)
июль 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

42

1926
№ 5

13 «ИГЕНЧЕ» ЖУРНАЛЫ. *Ленар Гобәйдуллин*

74 СОЛДАТ ЙӨРӘГЕ. Зариф Мөэминов

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 **Ризаэддин Фәхреддин**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Йөрәк түрендәге Йөрек.** *Мөнир Әһлиев*
13 **«Игенче» журналы.** *Ленар Гобәйдуллин*

ДИНИ МИРАС

18 **Таркаулык.** *Айдар Гайнетдинов*

2015 ЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ПАРКЛАР ҺӘМ СКВЕРЛАР ЕЛЫ

26 **Яшел Тау итәгендә.** *Рәмзия Габделхакова*

ТАТАР ГАМЕ

30 **Алтынга тузан кунмый.** *Рәис Зарипов*

ҖИҢҮ — 70!

34 **Кадерлеләр һәм кадерсезләр.** *Фәнзаман Баттал*
40 **Фронтовик-шагыйрь.** *Равил Рахмани*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

42 **Сүз һәм сурәт. Әхтәм Зарипов**

ӘДӘБИ МИРАС

46 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
51 **Тукайга якынаю** *(Түгәрәк өстәл)*
59 **Ачы тәҗрибә авазы.** *Габдулла Тукай*
61 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*
63 **Тукай турында истәлекләр.** *Вафа Бәхтияров*
67 **Урау юллар узып сезгә кайтам...** *Ләйлә Гарипова*
72 **Бер гасырдан соң...** *Факил Сафин*
74 **Солдат йөрәге.** *Зариф Мөэминов*
89 **Мин белгән Муса Гали.** *Рауль Мирхәйдәров*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ТАБИГЫЙ МИРАС

98 **Шөгер ягы — Кара Алтын иле.** *Гәрәй Рәхим*
109 **Бәкер көзе.** *Газинур Морат*

ТАТАР ҖЫРЫ

110 **Иң баһәле мирас!** *Максат Гомәров*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

112 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*
114 Кайтаваз. **Җаекмы, Йайыкмы?** *Әскәр Гатин*

ХӘТЕР САГЫНДА

115 **Сырлы бәләк.** *Гүзәлия Җәләлева*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

116 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның июль ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

118 **Җүләр балык.** *Ширияздан Сарымсаков*

119 **Мирасворд**

120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Июль*

Заказ №О-1772. Тираж — 1500 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 06.07.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, Абдулла Дубин, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Чагылыш». 2009 ел. Киндер, майлы буяу. *Р.Минһаҗев рәсеме.*



Ризаэддин Фәхреддин
(1859-1936)

• Әдип вә галимнәре булмаган кавем — бәхетсез, мәшһүр кемсәләрен оныткан халык — көчсез, әдәбияты булмаган милләт — рухсыз.

• Әхлак белән әдәбият бергә булырлар. Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса, әхлагы да шул рәвештә булыр.

• Озын сүзләрдә кыска гына бер максат була...

• Дөреслек катнашмаган ялганга каршы торуы җиңел, каршы тору авыр булган нәрсә — дөреслек катнашкан ялган.

• Милләтне бәхетле итү исә аны укытып һәм яхшы тәрбия биреп, байлык табу юлларын күрсәтү белән бергә һөнәр һәм сәнәгатьләр өйрәтү булыр.

• Вакыт үткәннән соң үкенүдән бер файда юк.

• Юлбашчыларыбыз исә ислам гыйлеме белән замана әхвале фәлсәфәсен белгән затлар булырга тиеш.

• Халыкка хезмәт итү дәүләткә дә хезмәт итү булыр.

• Үз динен, үз телен, үз гореф-гадәтләрен белмәгән кешегә бер милләт әһеле дә ышанмас.

ЙӨРӘК ТҮРЕНДӘГЕ ЙӨРЕК

(ИСКЕ ЙӨРЕК АВЫЛЫ ТАРИХЫННАН СӘХИФӘЛӘР)

Мөнир Әһлиев,
РФнең атказанган укытучысы, төбәкне өйрәнүче

НИГӘ ЙӨРЕК?

«Киров өлкәсенең административ-территориаль төзелеше» (1998) дигән белешмә-китапта Иске Йөрек авылының Малмыж районындагы иң өлкән авыл икәнлеге, аңа 600 ел элек нигез салынганлыгы язылган.

Авыл урынын шактый вакыт йөреп-йөреп эзләп тапканга, аңа Йөрек дигән исем биргәннәрдер, дип фараз итә авыл аксакаллары. Авыл янәшәсеннән агучы кечкенә генә елганың да исеме — Йөрек. Аңа югарыдан агып төшеп кушылган ике инеш авылны өч өлешкә бүлә.

Каюм, Камай, Камыш исемле марилар, монгол яуларыннан качып килеп, чишмәле елганың уң як ярына урнашкан. Риваятьләргә караганда, аларның берсе шадра булган. Шул сәбәпле, халык авылның бу ягын «Шадыр як» дип атый башлый. Соңрак елганың сул як ярына татарлар килеп төпләнә. Ике милләт халкы башта үзара тату



Йомырка җыючылар Фәйзрахман Хәбибуллин (уңда) һәм Нәби Зарипов. Кукарка шәһәрчеге.1912 ел

Гыйззәтулла байның Германиядәге вәкиле Габдрахман Хәбибуллин

гына яши. Шулай да ике арада еш кына каршылыклар да килеп чыккалаган. Көннәрдән беркөнне татарлар мариларга зур чишмәдән су алдырмый башлый. Камай да югалып калмый, урман эчендәге инеш буеннан чишмә таба. Хәзерге көндә авыл халкы аны «Камай чишмәсе» дип йөртә.

Авылыбызда мари-татар мөнәсәбәтләрен чагылдырган тагын бер табигать ядкяре бар. Марилар шаулап күңел ачарга яраткан. Мөселманнарга исә бу ошамаган. Шунлыктан, марилар күңел ачу өчен урман эчендәге инеш буенда аерым алан тапканнар, шунда җырлый, бии, кәеф-сафа кора торган булалар. «Алан түре» дип (ерак алан) аталган урын бүгенгә кадәр авылыбызның күркәм ял итү урыны.

МӘТӘСКӘДӘН ЙӨРЕККӘ

1552 елда Иван IV Казан ханлыгын яулап алгач хәзерге Арча районының Мәтәскә авылыннан шактый гаилә Йөреккә күченә, авылда яшәүче татарларның саны ишәя. Марилар исә, татарлар белән булган каршылыкларга түзә алмыйча, Малмыжга, ә аннан яңа урынга күчеп, 1556 елда Мари-Малмыж авылына нигез салалар.

ГЫЙЗЗӘТУЛЛА БАЙ

XIX гасыр урталарында Иске Йөрек халкы сәүдә белән шөгыльләнә башлый. Сәүдәгәрләр арасында ярлы крестьян гаиләсеннән чыккан Гыйззәтулла Хәмидулла улы аеруча аерылып торган. Аның төп шөгыле — авыллардан йомырка җыю һәм аны чит илләргә сатып җибәрү. Йомырканы әйләнә-тирәдәге татар авылларыннан гына түгел, бездән шактый ерак булган Кукарка (Советск-Орлов) шәһәрчеге тирәсеннән дә җыялар. Моны Фәйзрахман Хәбибуллинның (рәсемдә уңда) һәм Нәби Зариповның Кукаркада 1912 елның 25 сентябрендә төшкән фотосы дәлилли. Гыйззәттулла бай егетләре җыйган йомыркаларның Германия, Франция, Англия, Америка кебек илләргә барып җитүе мәгълүм. Әлеге илләрнең пристаньнарында, станцияләрендә сәүдәгәрнең үз вәкилләре эшләгән.

Йомырка җыеп сату Гыйззәтулла Хәмидуллинга шактый зур табыш

Йомырка җыючы егетләр. XX йөз башы

китерә. Ләкин уңышсызлыклар да булган. Мәсәлән, истәлекләргә караганда, Америкага бара торган бер пароходы казага тарый: көчле дулкынга эләгеп, йомырка тутырылган әрҗәләре ватыла. Сәүдәгәрнең Малмыжда, хәзерге ремонт-механика заводы урынында, такта яру заводы да була. Бу заводта йомырка тутыру өчен махсус әрҗәләр һәм стружка ясалган.

Авыл баеның берничә урында, шулай ук Йөректә дә кибет тотуы мәгълүм. Көнкүреш өчен барлык кирәк-яракны да авыл халкы шуннан алган. Еш кына товар йомыркага алмаштырылган.

Истәлекләргә караганда, Гыйззәтулла бай гади кешеләргә дә искиткеч мәрхәмәтле булган. Чираттагы уңышлы сәүдәдән соң, аның акчасына зиратның өч ягы таш киртә белән әйләндереп алына. Бай 1916 елны Иске Йөректә вафат була. Мәрхүм үзе, хатыны, кызлары авыл зиратындагы аерым урынга җирләнгән.

Байның вафатыннан соң да авылда йомырка җыю, аны читкә озату эше 1940 елларга кадәр дәвам итә.

ХӘБИБУЛЛА АБЗЫЙ

Хәмидулла һәм Һидиятулла — Габдулла уллары, бертуганнар. Хәмидулла улы Гыйззәтулла һәм Һидиятулла улы Хәбибулла — туганнан туганнар. Хәбибулла Гыйззәтулла бай сәүдәгәрнең ышанычлы кешеләреннән берсе була. Ул йомырканы Алабугага һәм Шәмәрдәнгә алып барганда өлкән озатучы вазифасын үти. Ә йомырка җыйганда, Хәбибулла абзый хәзерге Балтач районында йөри. Көннәрдән беркөнне Түнтәр авылында йомырка китергән Газизәбану исемле кызга күзе төшә.

— Бигрәк чибәр икәнсең, яучы җибәрмичә булмас, Йөреккә алып кайтам әле үзеңне…

— Кайларда соң ул Йөрек? Чибәр егет ашыкмаса, соңга калуы да бар, — дип шаяртыша алар. Хәбибулла өчен шаярту гына булмаган икән бу, ул, чынлап та, озакламый яучы җибәрә. Газизәбануның да чибәр, тырыш егеткә күңеле төшеп калган ахрысы, ул үзе дә, әти-әнисе дә ризалык бирәләр. Шулай итеп, Газизәбану Йөреккә килен булып төшә.

Шаулатып туй иткәннән соң, Хәбибулланың яшь, чибәр кәләшен

1. 1916 елның 26 октябрендә 66 яшендә вафат булган Гыйззәтулла Хәмидулла углының каберенә куелган таш

2. 1926 елның 25 сентябрендә 58 яшендә вафат булган Нурвисал Зариф кызы Гыйззәтулла хаҗи Хәмидулла әһлиясе (хатыны) каберенә куелган таш

ташның алды

яны

ташның арты

3. Ташның янына «Бу тарафта Гафифәбану кабере. 1902 ел, 7 гыйнварда вафат», дип язылса, артына, күпертеп, Шәрифәбану Гыйззәтулла кызының 1907 нче елның 15 июлендә вафат булганлыгы теркәлгән.
Кабер ташының алгы ягына «Гафифәбану, Шәрифәбану Гыйззәтулла кызлары Сасмак авылында имам Мөхәммәдшакир мелла Нурмөхәммәд углының никахында вафат улдылар», дип уелган.

Иске Йөрек авылы зиратындагы ташъязмаларны Ленар Гобәйдуллин укыды.

калдырып, инде ерак сәфәрләргә йөрисе килми. Ул Йөректә, агай-энесе Гыйззәтулла байдан рөхсәт сорап, үз хуҗалыгының таш кладовоенда бер кибет ачып җибәрә.

Кибет дигәч тә, ул вакыттагы кибеттә хәзерге кебек киштәләр ашау-эчү, киемсалым, эчемлекләрдән сыгылып тормаган. Шулай да кибет халыкны беренчел көнкүреш, хуҗалык әйберләре: шырпы, керосин, сабын, прәннек, сирәгрәк булса да, шикәр-кәнфит, ситсы, көрәк, сәнәк, балта белән тәэмин итеп торган. Хәбибулла абзый монда да, әйбергә алыштырып, йомырка җыюын дәвам иткән.

Гаиләнең озакламый ышанычы, таянычы, шатлыгы булып бер-бер артлы ир һәм кыз балалары дөньяга килә: Фәйзрахман, Габдрахман, Габделхак, Гәрәй, Нурдидә, Шәрифә һәм Вәгыйзә.

ИКЕ МӘЧЕТ

XIX гасыр урталарында авылның үзәгендә, ике елга арасында мәчет салына. Аның белән янәшә мәдрәсә дә төзеп куялар. Мәчет каршына янгын сүндерү өчен кирәкле җиһазларны саклый торган лапас та салына. Җәй көннәрендә анда атлы каравыл оештырылуы мәгълүм.

1891 елда авылыбызда тагын бер мәчет ачыла. Аның каршында булган мәдрәсәдә дә балаларга дин сабагы укытылган.

Шулай итеп, XIX гасырда авылыбызның ике мәхәлләсе, ике мәчете була. Ике мәхәлләне инеш аша Әүһәди абзыйның каралты-курасы яныннан (хәзер ул урында — Рәфкат Галиевнең җиләк-җимеш бакчасы) җәяүлеләр өчен салынган күпер тоташтырып торган. Шул сәбәпле, авыл халкы бу инеш-елгачыкны әле дә «Әүкәй елгасы» дип йөртә. Агач күпер 1982 елга кадәр авылның ике өлешен тоташтырып торды. Фәкать турыдан машина йөри торган күпер салынгач кына, агач күпер онытылды, аны төзекләндерүнең кирәге калмады.

БЕР АВЫЛДА ДҮРТ ГЫЙЛЕМ ЙОРТЫ

1915 елда авылыбызда ир балаларны укыту өчен аерым бинада өч класслы «русско-татарская школа» ачыла. Аның беренче укытучысы — атаклы

1891 елда ачылган мәчет

Рокыя Хәбибуллина (уңнан икенче) **кызы КДУ профессоры Роза Хәбибуллина белән** (уңнан беренче)

Түнтәр мулласы Ишмөхәммәтнең улы Габделхәй Динмөхәммәтов. Мәктәптә төрле яшьләрдәге 50-60 бала гыйлем алган.

Бер елдан соң, 1916 елның көзендә, кыз балалар өчен дә мәктәп ачыла. Бу мәктәп Йөрек елгасының сул ягындагы таллыкта, Әсхәт мулла йортының беренче катында урнаша. Мәктәпнең беренче укытучысы Татарстаннан килгән Рокыя апа Мансурова-Хәбибуллина була. Кызлар мәктәбендә исә 45-50 бала укыган.

Шулай итеп революциягә кадәр Иске Йөрек авылында дүрт гыйлем учагы була: «таш мәдрәсә», «аргы як мәдрәсә», «русско-татарская школа» һәм кызлар мәктәбе.

1966 елда Рокыя апаның кызлар мәктәбе турында сөйләгән хатирәләре безнең өчен зур тарихи чыганак:

«Йөрек мәктәбенә 1916 елның 1 сентябрендә килдем. Мин укыта башлаган кызлар мәктәбен авылның алдынгы карашлы яшьләреннән берсе Хәбибрахман Сафиуллин (Хәмидуллиннар токымы) оештырган иде. Уку-язу әсбаплары белән ул тәэмин итте. Китапларны УОНО ир балалар мәктәбенә җибәрә, без шуннан алабыз. Мәктәп өчен аерым бина булмаганлыктан, миңа абыстай укыткан җирдә — Әсхәт мулланың түбән өендә укытырга туры килде. Бөтенесе 40лап бала җыелды. Белем дәрәҗәләренә карап, укучыларны өч класска бүлдем. Беренчедә — 20ләп, икенчедә — 13, өченчедә 8-9 бала укыды. Укыту өчен бернинди уңайлык юк. 2-3 нче класс укучылары икенче сменада укыйлар. Чөнки барысы бергә сәке янындагы зур өстәл әйләнәсенә сыймый иделәр. Сан ягыннан иң азы булган 3 нче класслар өчен сәке өстенә тәбәнәк өстәл куйдык. Кайсы аякларын өстәл астына сузып, кайсы бөкләп утырып, шунда укыдылар. Кышның салкын көннәрендә безнең «мәктәп»тә бозау белән бәтиләр дә була иде. Кайбер көннәрне, иртән балалар җыелганда, бозау янына керткән сыер да чыгарылмаган була әле. Дәрес барганда, мич артында бәтиләр кычкырып, эчне пошырган чаклар күп булды. Әнә шундый шартларда укытырга туры килде миңа.

Балалар уку белән кызыксыналар иде, бар да тырыш һәм сүз тыңлаучан булдылар. Кайбер көннәрдә дәрестән соң мин аларга, бигрәк тә 2-3 нче класс укучыларына, хикәяләр сөйли һәм шигырьләр укый идем. Алар Габдулла Тукай һәм Мәҗит Гафуриның балалар өчен язган шигырьләрен яратып тыңлыйлар иде.

Укыту эшендә беренче елым гына булганлыктан, киңәш-табышка ир балалар мәктәбендә эшләүче Габделхәй Динмөхәммәтовка мөрәҗәгать итә

идем. Дәреслекләрне дә шуннан алып тордым. Шундый кыен шартларда эшләргә туры килсә дә, мин эшемне, укучыларымны һәм авыл халкын яраттым. Балаларның әти-әниләре белән дә яхшы мөгамәләдә булдык.

Бер елдан УОНО миңа Мәчкәрә авылында ачылган кызлар мәктәбенә (зуррак мәктәп) күчәргә тәкъдим итте. Мин каршы килмәдем. Шулай итеп, миңа Йөрек мәктәбендә бер ел гына эшләргә туры килде».

1918-1919 уку елында «русско-татарская школа» һәм кызлар мәктәбе зураеп бергә кушыла, дүрт класслы рус-татар башлангыч мәктәбе оештырыла.

ИШАН УГЛЫ

Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» исемле китабында мәктәбебезнең беренче укытучысы, Түнтәр имамы Ишми ишан улы Габделхәй Динмөхәммәтовның революциядән соң коммунистик идеологиягә бирелеп китүе, хәтта үзенең атасы һәм аның мөридләренә каршы булганлыгы турында мәгълүмат бар. Сүзне Риза хәзрәтләренә бирик: *«Җиһангир ахунд Абзгильдиннан ишеттем: 1917 ел җәй көнендә Диния нәзарәте мөселманнар арасында булган бәгъзы ихтиляфларны (каршылыкларны) хәл итү өчен дип, мине Малмыж нахиясенә (төбәгенә) җибәрде. Шулвакытта бер җыенга очрадым. Мөнбәргә бер яшь егет чыгып сүз сөйләде вә сүзендә: «Малмыж өязендәге хәлләрне ислах кылу өчен Ишмиләрне бетерү лязем (кирәк), Ишмиләр яшәп торган мөддәттә (вакытта) мөселманнар арасына гыйлем вә мәгърифәт таралуга имкян юк (мөмкинлек)!» дип, тәмам итте. Соңыннан белдем: шул егет Ишмөхәммәд ишанның Габделхәй исемле улы булган икән. Җиһангир ахунд сүзе бетте».*

1919 елда Малмыж шәһәрендә 80 яшьлек имам, кадимче мөгаллим, үз чорының күренекле мәгърифәтчесе Ишми ишан — Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов большевиклар тарафыннан контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнеп атып үтерелә. Р.Фәхреддин биргән мәгълүматларга караганда, ишанның коммунист уллары Нурелислам белән Нурлыгаян да авыр елларда әтиләренә таяныч булмаганнар. Сүзне янәдән Риза хәзрәткә бирик: *«Кәмал әфәнде Мозаффардан ишеттем: «Сарапул шәһәрендәге жандарма идарәсендә булган кәгазьләр арасында Ишмөхәммәд хәзрәт тарафыннан әһле ислам өстеннән бирелгән шикаять гаризалары чыккан. Кызыллар шул кәгазьләрне Малмыжга алып килгәннәр дә, бу эшләрдәге шәрикләре (иптәшләре) Закир мулла һәм дә Хәлил исемле кешене, өчесен Малмыжга китереп аттылар. Әгәр дә качмаулары хакында ике коммунист кәфил (җаваплылыкны үз өстенә алучы) булсалар, атуны туктатып торачакларын белдерсәләр дә, Ишмөхәммәднең Нурелислам һәм дә Нурлыгаян исемнәрендә булган угыллары кәфил булмаганнар, үзләре коммунист булганнары хәлдә, аталарын аттырмау хакында аз гына да хәрәкәт итмәгәннәр, бәлки атылуны теләп торганнар. Кәмал әфәнде сүзе шунда бетте».*

Габделхәй Динмөхәммәтов — күп кенә авылдашларымның беренче мөгаллиме, мәктәпкә килгән яшь укытучыларның остазы. Ул хакимият каршында «кызыл» булып кыланып, атасы Ишми ишанга, аның мөридләренә каршылык күрсәтсә дә, күңеле белән бу гамәлләре өчен сызлангандыр, дип уйларга кирәк. Заманга яраклашуы, коммунист туны киеп искелеккә, хәтта Ишми ишаннарга каршы көрәшүе бәлки аңа исән калу өчен бердәнбер юл булгандыр. Бу ата — улны, ул — атаны белми торган заманның, ватандашлар бер-берсенә кылыч күтәргән гражданнар сугышы елларының ачы фаҗигасе.

ЯНГЫННАР

1919, 1921, 1933 елларда Йөрек авылында көчле янгыннар була. 1919

1923 елда ачылган таш мәчет

елның 21 маенда булган янгында 196 хуҗалык янып бетә, шулай ук олы урамдагы мәчет белән мәдрәсә дә (бу вакытта инде ул мәктәп бинасы була) кара күмергә әйләнә. Янгын исә мәчет янәшәсендәге йортның печәнлегеннән чыга: балалар сугыш вакытыннан калган патрон белән уйнаганда дары шартлый. Йортсыз-җирсез калган кешеләрнең бер өлеше дүрт чакрым ераклыктагы урман эчендәге аланда яңа авылга нигез сала.

1921 елдагы янгыннан соң йортсыз калган кешеләрнең бер өлеше элекке афәттән күчеп утырганнар янына урнаша. Яңа авылны башта Төплек (йортлар салырга агачларны кискәннән соң бик күп төпләр утырып калганга шулай дип йөртәләр) дип атыйлар. Тора-бара бу авылга Яңа Йөрек дип исем бирәләр. Яңа Йөрек барлыкка килгәннән соң безнең Йөрек авылы Иске Йөреккә әверелә.

1919 елда яңа уку елы башланганчы авыл халкының тырышлыгы белән Үҗәл авылыннан зуррак бер йорт алып кайтып, аны күпердән өске якка, су буена мәктәп итеп салып куялар.

1919 елда мәчет янганнан соң, авыл ир-атлары гыйбадәт кылырга икенче мәхәллә мәчетенә йөриләр. Шул ук вакытта авыл халкының үз көче белән таштан зур гына яңа мәчет төзелә башлый. Аны төзүдә, таш ташуда бөтен авыл халкы катнаша. 1923 елны мәчет төзелеп бетә, ае да куела.

1931 елның көзендә Малмыж җидееллык татар мәктәбенең 5-7 класслары Йөреккә күчерелә. Малмыждагы «Кече милләтләр техникумы» бинасын да авылыбызга күчереп салалар. 1933 елның җәендә авылда янәдән көчле янгын була, мәктәпнең торак-йортлары янып бетә. 1934-1935 елгы уку елын балалар тиз арада төзелгән яңа мәктәптә каршылый. Ә мәктәпнең 1983 елда ачылган яңа бинасына нигез салыр өчен 20 ел чамасы көрәшергә туры килә.

ИМАМНАР

Авылыбызда исеме мәгълүм булган имамнарның беренчесе — Назыйр хәзрәт. Соңрак Низаметдин Габдулла улы Назыйров 40 еллап имам булып

«Зерновой» колхозы рәисе Рәшид Гафиулла улы Хәлиуллин (уңнан беренче) **Югары чишмә буенда кунаклары белән. 2015 ел**

тора. Низаметдин хәзрәт Төркиядә укып кайткан, заманына күрә алдынгы карашлы, укымышлы мулла була. 1919 елның 17 маенда Низаметдин вафат булганнан соң, муллалык вазифасы Мөбарәкҗан хәзрәткә күчә. Ул исә атаклы Түнтәр мулласында белем алган.

Эшли башлавының беренче көннәреннән үк яшь хәзрәткә янган мәчет урынына яңасын салдыру вазифасы йөкләнә. Таш мәчетнең түбәсен ябу өчен Дмитриевкага барып такта ярдырып алып кайтканда (Нократ буйлап Кумбыга кадәр) сал тарала, салны озатып баручалар суга төшәләр. Алар арасында булган Мөбарәкҗан хәзрәткә салкын тия. Ай ярым авырып ятканнан соң, 1920 елның 7 декабрендә 30 яшендә вафат була. Аның Фоат һәм Асия исемле ике баласы ятим кала.

Мөбарәкҗан хәзрәт вафатыннан соң, 1928 елга кадәр авылда указлы мулла булмый. Шул елны Татарстанның Олы Әтнә авылыннан Һади абый Камаловны Йөреккә мулла итеп алып кайталар. Һади мулла үз эшенә тугрылыклы була, авыл халкына игелекле хезмәт итә. Әмма 1937 елда явыз телләрнең әләге белән, Советларга каршы агитациядә гаепләнеп, аны кулга алалар. Һади хәзрәт төрмәдә һәлак була.

Татарстанда бөтен мәчетләр юк ителгән чорда, Киров өлкәсенең Малмыж районы Иске Йөрек, Яңа Смаил, Татар Конбашы авылларында гыйбадәт кылу йортлары сакланып кала һәм уңышлы эшләп килә. Авылыбызда мәчеткә йөрүчеләр кимегәч, сугыш һәм сугыштан соңгы елларда гыйбадәт кылучылар намазга таш мәчеткә генә килә башлыйлар. Мәчет каршындагы мәдрәсә бинасы 1960 елларга кадәр, авылда яңа клуб салганчы, клуб һәм китапханә буларак файдаланылды. 1985 елда таш мәчетнең түбәсе, манарасы ак калай белән ябыла. 2000 елның язында агач мәчетнең манарасын яңарталар.

***

Иске Йөрек авылының төп горурлыгы — аның уңган-булган кешеләре! Шушы мәкаләдә без төбәк тарихында тирән эз калдырып киткән инсаннарның берничәсенә тукталдык. Әле бит авылыбызда, гомумән Малмыж төбәгендә, Ватаныбызга хезмәт иткән игелекле кешеләр бихисап. Журналның алдагы саннарында алар турында да язарбыз әле, иншаллаһ! ■

برلەشڭز، بۇتن دۇنیا پرالیتارییاتی!

ئیگنچی

تاتارستان جیر ئشلەرن حالق کامیسارییاتن تارافندان،
تاتارستان کرەستیيەن ئۇز ئارا یاردەملەشو ئۇزەک
کەمیتیتن قاتناشن بلەن چعارلا تۇرعان
ئیکن ئاتنالق ئاول کۇن کورنشن ژورنالن.
5نچن یل چعا.

بەیەسی: بریلعا 3 سوم — | 3 ئایعا 75 تیین
6 ئایعا 1 » 50 تیین | 1 نومیری 15 »

ئادریس: قازان، تاتارستان جیر ئشلەری حالق کامیسارییاتی، کیتاب باسدرو بولنگی.

یل 1926	مارت 1	№ 5

بو نومیردە:

ئیدارەدەن.
جیر تۇزو ئشلەرن ئاگرانومییە بلەن بەیلەرگە کیرەك - ئاگرانوم: دانبولات.
نیچك یاحشی کۇن ئیتە باشلارعا؟ - ماروزف.
قش کۇنی تیرس توگو - ف. جەلال.
ترلکلەرنڭ نازالنعن ساقلاو - م. قوربان.
کوچو-کوچرو ئشلەری - زەکی ئەحمەت.
ئاول حوجالنعی، بورچ بیرو شیرکەتلەری

سوتچلك ئشی - ئالینتیف.
یەشرن ترکلك - ع. عەففار.
ئۇز ئارا یاردەملەشو کەمیتیتلەری، ئاول ئوقتوچسی هەم ئاول مەکتەبی - فەسحی.
ۋولس یاردەملەشو کەمیتیتلەرنڭ برنچی ئشلەری - م. ئیسحاقف.
ئاول حاتلاری.
ئەدەبییات - ع. حەبیب.

«ИГЕНЧЕ» ЖУРНАЛЫ

Ленар Гобәйдуллин

Исмәгыйль Рәмиев төзегән альбомда (1926 ел) журнал турында түбәндәгеләр язылган: *«1921 елның сентябрендә Казанда чыга башлады. Татарстан җир эшләре халык комиссариаты тарафыннан айга бер тапкыр чыгарыла торган авыл көнкүреше журналы.*

Беренче номерындагы лозунгы: «Дөньяда хаким — эш». Журнал бертуктаусыз хәзерге көнгәчә чыгып килә, кирәк мөндәриҗә (эчтәлек), кирәк техника ягыннан булсын көннән-көн яхшыра бара һәм авылга карата чыгарылган журналларның иң алдынгыларыннан булып исәпләнә. Журнал баштанаяк авыл хуҗалыгы, кооперация һәм ярлы, урта хәлле крестьян көнкүрешенә багышланып чыгарыла. Соңгы елларында, рәсемнәре күбәю белән бергә, тел ягыннан да җиңелләште. Хәзерге мөхәррире Фатих Сәйфи-Казанлы[1]. Журналга иң якын, торып чыга башлаганнан бирле өзлекмәстән эшләп килүче — К.Халидов. Язышучылары — Татарстанның барлык татар һәм рус агрономнары. Бу журналның нәшриятыннан «Авыл хуҗалыгы» исемендә атналык газета чыгарылды[2].»

Татар энциклопедиясе сүзлегендә 1962 елга кадәр дөнья күргән «Татарстан авыл хуҗалыгы» журналының 1921-1930 елларда «Игенче» исеме белән чыкканлыгы, 1922-1923 елларда татар телендә «Авыл хуҗалыгы сәхифәсе» исемле кушымта газетасы да булганлыгы турында язылa[3].

«Игенче» журналы идарәсе Казан шәһәрендә, Татарстан Җир эшләре халык комиссариатының китап бастыру бүлегендә урнашкан, «Гажур» нәшриятының «Шәрык» типографиясендә басылып чыккан.

1920 еллар — ТАССРда шәхси игенче хуҗалыклары үсү белән бергә кооперацияләрнең дә саны арткан чор. Җир эшләре халык комиссары Йосыфхан Якубов менәниләр яза: *«Авыл хуҗалыгын күтәрүдә, аны социальный эзгә бастыруда авыл хуҗалыгы кооперациясе бик зур роль уйный, Татарстан халкы моны бик яхшылап аңлый һәм шуңар күрә бездә авыл хуҗалыгы кооперациясенең һәртөрлесе көннән-көн үсә. 1925 елның маенда бөтен Татарстанда регистрациягә кергән 901 авыл хуҗалыгы кооперациясе исәпләнә. Дөрес, болар әле бик көчсезләр. Ләкин авыл хуҗалыгы күтәрелгән саен болар да нык эзгә басачаклар. Халыкның кооперациягә булган яхшы карашы шуны бик ачык күрсәтә ала.»*

Журнал Татарстан крестьян үзара ярдәмләшү үзәк комитеты катнашы белән дә чыгарылган. Комитетның кантон һәм волостьлардагы бүлекчәләре журналны яздырып халыкка таратуда ярдәм иткән. Үз чиратында, ярлы крестьян хуҗалыкларын «культура һәм кооперативлаштыру юллары белән күтәрүне иң дөрес чара», дип санаган әлеге комитет, Җир эшләре халык комиссариаты белән килешү нигезендә, «Игенче» сәхифәләрендә «Берләшүдә көч» дигән шигарь белән үзара ярдәмләшү (кооперация) эшләре турында мәкаләләр бастырган.

Журналда «Авыл хуҗалыгы хәбәрләре», «Страхование эшләре», «Корылык белән көрәшү», «Агрономия», «Хайван асрау», «Техника үсемлекләре», «Бакчачылык», «Файдалы киңәшләр», «Чит илләрдә», «Әдәбият бүлеге», «Ничек яхшы көн итә башларга?», «Кош асрау», «Умартачылык», «Корткочлар белән көрәшү», «Сөтчелек эше», «Фән бүлеге», «Авыл хатлары», «Урманчылык», «Ветеринария», «Вак кул эшләре», «Урыннардан язалар», «Болынчылык», «Ат үстерүчелек», «Тәҗрибә эшләре», «Крестьяннар тәҗрибәсеннән» кебек рубрикалар булган. «Әдәбият бүлеге»ндә татар әдәбият белемендә бөтенләй өйрәнелмәгән агрохикәя жанрын күрәбез. «Крестьяннар тәҗрибәсеннән» исемле рубрикада Арча кантоныннан берәү үзенең кукуруз — кәгъбә бодае игү тәҗрибәсе белән уртаклаша. Агроном Ә.Фәхриев үгез ширкәтләре оештыру мәсьәләләре турында язып чыга. «Авыл хатлары» рубрикасы исә татар крестьян хуҗалыгы сулышын тоярга ярдәм итә.

---

[1] Ф.Сәйфи-Казанлы үзенең кайбер мәкаләләрен «Карамалы» имзасы белән бастырган.
[2] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (1905-1925): альбом. — Казан: Гажур, 1926. — Б.185-186.
[3] Гилязов З.З. «Татарстан авыл хужалыгы» / ТЭС. Т5. — Казань, 2010. — С.566.



1925 ел башына кадәр чыгарылган китапларны тезсәк, Казаннан Чиләбегә җитә

Аңлашылганча, журналның төп максаты — авыл халкын игенчелек, терлекчелек, бакчачылык һәм башка авыл хуҗалыгы тармакларындагы фәнни яңалыклар белән таныштыру, игенче халкын аңлы-гыйлемле итү. *«Татар, башкорт крестьяннарына үзләренең авыл хуҗалыгын аякка бастырыр өчен иң җиңел, туры юл — «Игенче» журналын укудыр»*, — дип язылган басманың игълан битендә. Шулай ук журнал кооператив оешмаларының эшен яхшыртуда да алыштыргысыз кулланма булып торган. Хәзерге заман укучысына «Игенче» журналы ТАССР төзелгән елдан массакүләм колхозлашу дәверенә кадәрге авыл хуҗалыгы сәясәтен, кооперацияләр тарихын, татар игенчесенең көнкүрешен, яшәү рәвешен, авылларда булган үсеш-үзгәрешләрне өйрәнү өчен кызыклы тарихи чыганак.

Теләсә кайсы гамәлнең башында аң-гыйлем тора. Моны аңлаган ТАССРның беренче җитәкчеләре татар телендәге махсус әдәбиятка һәм матбугатка зур игътибар бирә. Җир эшләре комиссариатының дәвамчысы булган хәзерге Авыл хуҗалыгы министрлыгы — «Игенчеләр сарае» бүгенге гади авыл игенчесен, терлекчесен агарту өчен нәрсә эшли? Шуны да искәртү мәслихәт: узган гасырның 20 елларында татар авылы өчен «Игенче» журналы бердәнбер басма булмый. Бер үк вакытта Казанда Татарстан Үзәк башкарма, РКП(б) өлкә комитетлары һәм Крестьян йорты — «Крестьян», Пенза шәһәрендә РКП(б)ның вилаять комитеты хозурындагы татар секциясе — «Сабанчы», Мәскәүдә Мәркәз комитеты янындагы татар-башкорт бюросы — «Игенчеләр», Уфада Башкортстан Үзәк башкарма, РКП(б) өлкә комитетлары «Яңа авыл» газеталарын һ.б. чыгарган[4]. Игътибарыгызга «Игенче» журналыннан берничә мәкаләне кыскартып тәкъдим итәбез.

ТАТАРСТАН ҖИР ЭШЛӘРЕ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ КИТАП БАСТЫРУ БҮЛЕГЕНЕҢ ХЕЗМӘТЕ
Татарстанның 5 яше уңае белән

Патша хөкүмәтенең җирле халык ту-

[4] Гайнанов Р.Р., Мәрданов Р.Ф., Шәкүров Ф.Н. Татар вакытлы матбугаты (1905-1924): библиографик күрсәткеч. — Казан: Рухият, 1999. — Б.275-290.

рында торкан кара сәясәте сәбәпле татар крестьяны хуҗалыгы файдалы, яңа юллар белән алып бару өчен кирәкле белемнән мәхрүм ителгән һәм шуның аркасында татар авыллары хуҗалык эшендә бер урында утырып калганнар иде. Шуларны алга алып, Совет властенең һәрбер яктан җирле, ярлы крестьян халкын икътисади һәм мәдәни яктан күтәрү турындагы вазифасын эшкә ашыру юлында, Татарстан Җир эшләре халык комиссариаты янында китап бастыру бүлеге төзелеп, эш башлады. Ачлык шартлары эчендә үткәрелгән беренче елда, крестьян массасы өчен тиз арада җиңел рәвештә укып файдаланырлык кечкенә, вак китаплар һәм плакатлар бастырып таратырга керешә. Болардан китап бастыру бүлегенең үзенә һичбер материальный файда күзәтелмичә, күбесенчә бушка таратылды. Сугышлар, ачлык, җимереклек җиңелеп, икътисади тормыш әкренләп табигый хәленә кайта бару белән, китап бастыру бүлеге дә үзенең хезмәтен крестьян хуҗалыгын нык нигездә төзүтөзәтү максатына карап, шул турыда ярдәм итәрлек китаплар чыгарырга керешә. 3 ел ярым чамасы вакыт эчендә китап бастыру бүлегенең иткән хезмәте түбәндәгечә күренә. Барысы 130 исемләп китап, плакатлар чыгарган, боларның 40ы урысча булып, калган 90 кадәрлесе татар телендә язылганнар. 46 номер «Игенче» журналы чыгарылып, 15 номер урысча журнал чыгарылган. Һәрберсе 42шәр номердан татарча һәм урысча «Авыл хуҗалыгы сәхифәсе» исемендә гәзит чыгарылган. 24-25 нче хуҗалык елында Җир эшләре комиссариаты тарафыннан гел татарча гына барысы 197 табаклык төрле авыл хуҗалыгы әдәбияты чыгарырга билгеләнгән. Ләкин бу, уйлаганнан артык, 250 табакларга җиткерелергә чамалана. Шулай итеп, бөтен учреждение, управлениеләрдә эшләнә торган эшләрнең барысын бергә алганда, быел эшләнәчәк эш 300 табакка җитәчәк.

Чама белән җыелган мәгълүматка караганда, татар әдәбияты туган көннән алып Октябрь революциясенә чаклы булган вакыт эчендә төрле земстволар һәм китап бастыручылар тарафыннан чыгарылган татар телендәге авыл хуҗалыгы әдәбиятының табак саны нибарысы 110-120 табактан артмый. Димәк, революциядән соңгы 3 елдан артык вакытта чыгарылган авыл хуҗалыгы әдәбияты, аннан алдагы йөз елга якын вакыт эчендә чыгарылганнарга караганда өч тапкыр артык була. Китап бастыру бүлегенә, кыска гомерендә ирешкән шул муаффәкыятьләрен (уңышларын) алга алып, 1923 елда Мәскәүдә булган Советлар Союзы Җөмһүрияте күләмендәге беренче авыл хуҗалыгы һәм кустарь промышленность күргәзмәсендә беренче дәрәҗә диплом бирелде.

Китап бастыру бүлеге чыгарган әдәбият, китаплар Урал, Себер өлкәләре, Башкортстан Җөмһүрияте һәм бөтен РСФСРдагы татар, башкорт крестьяннары арасында көннән-көн иң караңгы почмакларга да керә, тарала бара.

1925. — №6. — Б.300-306.

«АКСУ» МЕЛИОРАЦИЯ ШИРКӘТЕ

1924 ел язында Тәтеш кантоны Урта Балтай волосте Аксу авылында мелиорация ширкәте төзелде. Аның торкан теләге күптән, бәлки йөз еллар буенча яхшыртылмый яткан, яз печән бирә торган 60 дисәтинә болынны сукалап яхшырту, крестьян арасына яхшы сорт орлыклар үрчетү һәм башкалар иде. Мелиорация ширкәте төзү белән авыл хуҗалыгы банкы аркылы 3-4 мең акча алынды. Шул акча белән мелиорация ширкәте эш башлады. Авылда бурыч бирү ширкәте булганлыктан, мелиорация ширкәте үзенең акчасын тик яткырмады. Процент ашасын өчен кредитка салды. Авыл хуҗалыгы банкы, ширкәткә бурычны 5-6 елга елына 6%тан биргән иде, ширкәт аны бурыч ширкәтенә, Аксу крестьяннары әйтмешли, «Ак су» банкына аена 12 % белән салды.

Казанда авыл хуҗалыгына бурыч бирү җәмгыяте һәм авыл хуҗалыгы машиналары складлы

Ширкәт идарәсе үзенең гомуми җыелышында бер трактор алырга, дип карар чыгарган иде. Шул карарны җиренә җиткерү өчен тракторчылар курсына үзенең бер членын җибәреп укытты (курска җибәрелгән член — гади крестьян). Бурыч ширкәте аркылы Селькредпромсоюздан трактор алды. Яз башында ук тракторга атланып (!!!) Аксу крестьяны Әхмәт абзый авылга дөбердәтеп кайтып керде. Трактор хәзерендә күрше авылларда җирләр сукалый, мелиорациянең сукаланмаган 40-45 дисәтинәгә якын болынын бу ел көз озакламый сукалап калдырырга тора. Кыш трактор тик ятмасын өчен, идарә Аксуда трактор көче белән [эшли торган] лесопилка куеп җибәрергә карар чыгарды.

Аксу мелиорация ширкәте члены.
1925. — №17-18. —Б.550-552.

КҮЧҮ-КҮЧЕРҮ ЭШЛӘРЕ

Зөя кантонында булган буш җирләр шәһәргә якын, Волга буенда булганга, бу җирләргә, Татарстанда күчү эшләре башлану белән, төрле кантоннарның крестьяннарыннан күчү турында сораулар керә башлады. 23 нче елларда ук буш җирләр крестьяннарга бирелеп бетте. Иван Грозный Казанны алырга хәзерлек күргән вакытта Волга буенда бер татар авылын калдырмаска, дип план сызса, Татарстан Җөмһүрияте мәдәнияттән ераклашкан, Татарстанның караңгы, ерак почмакларында җәберләнеп калган җирсез татар крестьяннарын урнаштырды. Җирсез крестьяннар, күчүнең авырлыгына кармый, 100-150 чакрым җирләрдән, авылдагы иске тормышларын ватып, яңа җирләргә күчеп, яңа хуҗалыкларда яши башладылар.

Баштарак землянкаларда яшәү бик җиңел булмады. Беренче мәртәбә төялеп килеп, яңа җиргә аяк баскач та, арбадан алынган төеннәр, савыт-саба, чиләк, комганнарны агач арасына өеп куеп, шалашлар ясар өчен агачлар киселде. Җил-давылдан сакланыр өчен землянкалар казылды. Землянкалар эчендә киләчәк кайгыртылды. Күчүчеләр арасында күбесенең аты, сыеры юк иде. Атсызларның кайсылары Наркомзем тарафыннан бирелә торган атларны алып, хөкүмәттән бирелгән агачларны ташыдылар, акрынлап каралтылар кора башладылар. Шулай итеп, Зөя кантонында Волга буендагы 6152 дисәтинә элекке бояр җирләрендә яңа тормыш башланды.

Зәки Әхмәт.
1926. — №5. — Б.164.

Аллаһ исемнәре һәм агучы елга мисалы. – Матбагаи Кәримия. Казан, 1907.



ТАРКАУЛЫК

Айдар Гайнетдинов,
ислам белгече

I

Мөселманнар арасындагы таркаулык проблемасы бүген бик актуаль һәм безнең уйлавыбызча, ул чишә алмаслык түгел. Ислам авыр дин түгел, ә кешеләр бәхет-сәгадәттә булсын өчен аларга Аллаһ тарафыннан рәхмәт йөзеннән бирелгән дин. Аллаһның рәхмәте белән татарлар ул проблемаларны чишә алырлар, дигән өметтә калабыз. Аллаһы Тәгалә дә, Аның рәсүле Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм дә бу таркаулыкларның булачагын кисәтеп, безгә үгет-нәсыйхәтләрен ирештерде. Коръәндә дә, пәйгамбәребез хәдисләрендә дә бу турыда күп кисәтүләр бар икәнен беләбез.

Хәзерге заманда төрле идеология һәм агымнар саны артканнан-арта бара. Яңа гына ислам диненә кергән кешеләр кем артыннан барырга, кемне тыңларга белмиләр, чөнки һәрберсе динне төрлечә сөйли һәм аңлата. Кемдер бу очракта нәрсә эшләргә икәнен аңлый, ә кемдер бернәрсә дә аңлый алмыйча ислам диненнән чыга. Бу үзенә күрә бер сынау булып тора. Чөнки пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм әйтте: *«Чынлыкта, сезнең арада (сәхабәләр арасында) озаграк яшәгән кеше бик күп таркаулыклар күрәчәк!»* (Бу хәдис Әбү Дауд, Тирмизи, Ибн Мәҗа җыентыкларында китерелә).

Татар мөселманнары бүленеп, бер-берсен көферлектә гаеплиләр, көрәшәләр, талашалар. Шул ук вакытта алар таркаулыкның өммәтне зәгыйфьләгәнен, көчсезләндергәнен онытарлар. Бу турыда Аллаһы Тәгалә Үзе үк әйтә:

«Аллаһка һәм Аның рәсүленә итагать итегез! Һәм үзара низаглашмагыз, әгәр низаглашсагыз, көчегез, гайрәтегез китәр, таралырсыз, бәлки сабыр булыгыз! Аллаһ, шиксез, сабырларга ярдәм бирәчәк» («Әнфәл» («Табыш») сүрәсе, 46 нчы аять).

Бу таркаулыклар ни сәбәпле килеп чыккан соң? Әгәр дә без аның сәбәпләрен белсәк, иншә Аллаһ, бу проблеманы чишәчәкбез. Алар түбәндәгеләр:

1. Бозык ышанулар, гөнаһлар таралу.

Таркаулыкның чыганагы булып, иң беренче чиратта, гөнаһка баткан мөселманнар санала. Чөнки иң зур гөнаһ — ул бозык игътикад (иман).

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

«Әй мөэминнәр, сезгә ирешкән бәлаказалар һәм кайгылар үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәплеер. Шулай булса да, Аллаһ гөнаһларыгызның күбрәген гафу итәдер» («Шура» («Киңәш») сүрәсе, 30 нчы аять).

«Әгәр яхшылыктан сиңа бер шатлык ирешсә, ул шатлык Аллаһтан, әгәр казадан бер кайгы ирешсә, ул кайгы үзеңнең кимчелегеңнәндер» («Ниса» («Хатыннар») сүрәсе, 79 нчы аять).

> Үзләрен ислам дине исеме астына кертүче бөтен татар мөселманнары төрле вак мәсьәләләргә игътибар итмичә, һәрвакыт бердәм булырга тиешләр.

«Шайтан дусларын җәһәннәмгә салганыбыз кебек, Аллаһка карышып азгынлыкны кәсеп иткәннәре өчен, дөньяда бәгъзе залим кавемне икенче залим кавемгә ирекле кылырбыз» («Әнгам» («Терлек») сүрәсе, 129 нчы аять).

Аллаһ кешеләр өстеннән хакимлекне үзләренең эшләренә күрә бирә! Динле кеше белән динле, ә динсез белән динсез идарә итә.

2. Гыйлемнең булмавы һәм гыйлемсез гамәл кылу.

Бу шулай ук ислам өммәтендәге фаҗига һәм зур проблема булып тора. Эш-гамәлләрне гыйлемгә туры китереп кылу мәҗбүри. Дәгъват, укыту, тәрбия һәм башка шундый бөтен мөселман өммәтенә кагылган мөһим нәрсәләрдә бу бигрәк тә кирәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре бөтен нәрсәне нәкъ менә шулай — гыйлем белән эш иткәннәр. Бу турыда Аллаһы Тәгалә әйтә:

«Әй Мөхәммәд! Әйт: «Бу Коръән күрсәткән юл минем юлымдыр, мин шул юл белән күреп-белеп кешеләрне Аллаһка чакырырмын һәм миңа ияргән мөэминнәр шул юл белән кешеләрне Аллаһка чакыралар, һәм Аллаһы Тәгаләне һәр кимчелектән пакь дип беләмен һәм мин мөшрикләрдән түгелмен» («Йосыф» сүрәсе, 108 нче аять).

Гыйлем — гамәлнең башы, ә гамәлләр исә гыйлемнең нәтиҗәсе булырга тиеш. Гыйлемсез эшләнгән эшнең бернинди дә файдасы булмый, киресенчә, зыян гына салына. Нәкъ менә ислам дине ту-

рында гыйлемгә нигезләнмәгән сүзләр сөйләүчеләр һәм шул сүзләр белән гамәл кылучылар аркасында фикер төрлелеге, таркаулыклар барлыкка килә.

3. Динне ялгыш аңлау һәм аңлату. Ислам өммәтендә начарлык, әшәкелек таралуның тагын бер сәбәбе — динне ялгыш аңлау. Нәкъ менә шул сәбәп исламда күп санлы агымнар һәм секталар барлыкка килүгә китерде. Кешеләр динне пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләренә таянып түгел, ә үзләре мөстәкыйль төшенергә тырышалар. Күп кенә мөселманнар, Коръән һәм сөннәт юлыннан барабыз, диләр. Ләкин алар шуны оныталар: Коръән һәм сөннәтне нәкъ менә сәхабәләр аңлаганча аңлау мәҗбүри, ә һәр кеше аңлый алганча һәм аңларга теләгәнчә түгел. Моны Аллаһ һәм Аның рәсүле салләллаһү галәйһи вә сәлләм таләп итәләр. Аллаһы Тәгалә әйтте:

«Берәү Коръән дәлилләре белән туры юл күрсәтелеп шәригать хөкемнәре өйрәтелгәннән соң рәсүлгә хилафлык кылган эшләрне эшләсә, бу эшләрне берәү ихтыяр итсә, риза булып шул юлга керсә, әлбәттә, аның күңелен шул юлга беркетербез, аннары шул юл белән җәһәннәмгә барып керер» («Ниса» («Хатыннар») сүрәсе, 115 нче аять).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм әйтте: *«Яһүдиләр җитмеш бер төркемгә бүленер, җитмеше җәһәннәмгә, берсе җәннәткә керер. Нәсаралар җитмеш ике төркемгә бүленер, җитмеш бере җәһәннәмгә, берсе җәннәткә керер. Минем өммәтем җитмеш өч төркемгә бүленер, җитмеш икесе җәһәннәмгә, берсе җәннәткә керер». Сәхабәләр сорадылар: «Җәннәткә керүчеләр кемнәр алар?» Пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләм җавап бирде: «Алар минем артымнан һәм минем сәхабәләрем юлыннан баручылар»* (Бу хәдис Тирмизи, Әхмәд, Әбү Дауд, Ибн Мәҗә җыентыкларында килә).

Димәк, динне пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре аңлаган кебек аңларга кирәк икән. Башкача, үз белдеге белән, ничек тели, шулай аңлаган кеше, һичшиксез, адашачак һәм җәһәннәм утына дучар булачак. Аллаһ сакласын!

Динне дөрес итеп аңлау Аллаһы Тәгаләнең зур нигъмәте булып санала һәм Ул аны фәкать хаклыкка омтылучы ихлас бәндәләренә генә бирә. Коръәндә бу турыда түбәндәгечә әйтелә:

«Тәхкыйк, Коръәнне укырга җиңел һәм мәгънәсен аңларга ачык кылдык, әмма Коръән белән вәгазьләнеп гамәл кылучы һәм Коръән куркыткан газаптан куркучы бармы?» («Камәр» («Ай») сүрәсе, 17 нче аять).

4. Нәфес артыннан иярү. Үз нәфесең артыннан иярү шулай ук адашуга илтүче төп сәбәпләрнең берсе булып тора.

Бу турыда Аллаһы Тәгаләнең китабында бик күп әйтелгән:

«Әгәр алар синең китап китерегез дигән сүзеңне кабул итмәсәләр, бел, алар сиңа иман китермәүдә фәкать нәфес һаваларына ияриләр, Аллаһның һидаятеннән башка нәфес һавасына ияргән кешедән дә адашучырак кеше бармы? Нәфесләренә ияреп адашкан залимнәрне Аллаһ туры юлга күндермәс» («Касас» («Хикәя») сүрәсе, 50 нче аять).

«Коръән белән гамәл кылмыйча үзләренә золым иткән кешеләр дәлилсез нәфес һаваларына ирделәр, шундый кешеләрне Аллаһ адаштырганнан соң аларны кем туры юлга күндерә алыр? Аларга ахирәттә ярдәмчеләр булмас» («Рум» сүрәсе, 29 нчы аять).

Гыйлем буенча барырга теләмәгән кешегә, әлбәттә, үз нәфесе артыннан гына барырга кала. Шуңа күрә һәр кеше бу мәсьәләдә үз-үзен тикшереп карарга тиеш.

Күңелендә бу дөньяга карата гына мәхәббәт булган кеше Коръәнне дөрес итеп аңлый алмый. Андый кеше теге яки бу аятьләрне үз нәфесенә ярак-



Бәхет мәчете. – Матбагаи Кәримия. Казан, 1913.



Аллаһ һәм пәйгамбәр исемнәре, мөбарәк бакча. – Матбагаи Кәримия. Казан, 1913.

лаштырып аңларга тотына һәм шуның белән үзенең адашканын сизми дә кала. Хәтта кайбер кешеләр элек бер төрле сөйләгән булсалар, соңыннан, мохтаҗлыкка төшсәләр, җиңел генә акча эшләр өчен икенче төрле сөйли башлыйлар. Мәсәлән, урлауны, рибаны хәләлгә саный башлыйлар һ.б.

5. Дингә төрле яңалыклар кертү.

Боларның ислам дөньясында фетнәләр барлыкка килүгә сәбәп булып торуында шик юк.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

«Әйт: «Өстегездән һәм аяк астыгыздан сезгә газап җибәрергә яки сезгә азган халыкны аралаштырырга Аллаһ, әлбәттә, кадир», — дип. («Әнгам» («Терлек») сүрәсе, 65 нче аять).

«Өммәтләрнең һәрберсенә рәсүлләр күндердек, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз һәм Аннан башкага гыйбадәт итүдән сакланыгыз һәм бидгать гамәлләр белән динне пычратмагыз, дип. Ул өммәтләрнең итагать иткәннәрен Аллаһ һидаяткә салды һәм итагать итмәгәннәренә адашуны беркетте. Инде җир өстендә йөрегез һәм күрегез — ялганчыларның ахыры ничек булган?» («Нәхел» («Умарта кортлары») сүрәсе, 36 нчы аять).

6. Чын ислам галимнәренә мөрәҗәгать итүдән һәм алар артыннан ияреүдән баш тарту.

Пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең: *«Чынлыкта, галимнәр — пәйгамбәрләрнең варислары»* диюенә карамастан, кешеләрнең кайберләре алар юлыннан баруга каршы чыгалар. Бу да өммәтнең адашуына китерә. Галимнәр дигәндә, 5-6 ел ниндидер дини уку йортында укыган кеше түгел, ә кимендә 20-30 ел гомерен башка зур галимнәрдән тырышып гыйлем туплауга багышлаган кеше күздә тотыла. Аллаһы Тәгалә дә Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм өммәтенә, үзләрендә гыйлем булмаганда, галимнәргә мөрәҗәгать итәргә куша. Чөнки һәр кеше проблеманы үзенчә чишә башласа, төпле генә бер фикергә килә алмаска мөмкин. Коръәндә бу турыда түбәндәгечә әйтелә:

«Синнән элек тә синең кебек ирләрне пәйгамбәр итеп җибәрдек һәм аларга шәригать хөкемнәрен вәхий кылдык, югыйсә, бервакытта да фәрештәләрне пәйгамбәр итеп җибәрмәдек, белмәгән һәрнәрсәгезне белгән кешеләрдән сорагыз!» («Нәхел» («Умарта кортлары») сүрәсе, 43 нче аять).

Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм әйтте: *«Аллаһы Тәгалә бәндәләреннән гыйлемне алар арасындагы галимнәрне бетереп кенә ала. Бөтен галимнәр үлеп беткәч, кешеләр үзләренә дини җитәкче итеп надан кешеләрне куя башлаячак. Алар, гыйлемнәре булмаган килеш фәтвалар биреп, үзләре дә адашырлар, аларга иярүчеләрне дә адаштырырлар».* (Бу хәдис Бохари һәм Мөслим җыентыкларында килә).

Хәзерге көндә галимнәре булмаган агымнар, секталар арасында нәкъ менә шушы хәл күзәтелә дә. Алар бик мөһим булган әйберләрне дә шәригать кушканча түгел, ә үзләренең аңлауларына нигезләнеп кабул итәләр. Шуңа күрә дә бик күп мөселманнар адашалар. Бүгенге көндә атаклы зур галимнәргә мөрәҗәгать итү урынына аларны хурлыйлар гына.

7. Шикле дәлилләргә ияреү.

Бу да мөселманнарның адашуына китерүче бер сәбәп. Үз нәфесләрен һәм батыл гамәлләрен яклаган кешеләр еш кына ялган хәдисләр кулланалар. Шулай итеп гыйлемнәре җитәрлек булмаган кешеләрне ялгыш юлга кертәләр, адаштыралар.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

«Әй Мөхәммәд! Ул тиңдәше булмаган Аллаһ сиңа китап иңдерде, ул Коръәндә күбрәге мәгънәсе ачык, аңлаешлы аятьләр, ул аятьләр Коръәннең төп нигезе. Шулай ук Коръәндә мәгънәсе яки тәэвиле ачык беленмәгән аятьләр дә бар, ләкин андый аятьләргә тәэвил ясаудан, ягъни

мәгънә чыгарудан Аллаһ тыйды. Әмма күңелләре хактан батылга авышкан яман кешеләр мәгънәсе ачык түгел аятьләргә иярерләр, кяфер булуны эстәп, яки мөселманнар арасына фетнә салуны теләп, һәм нәфесләренә муафикъ мәгънәләр бирүне теләп, тәэвил ясарлар. Бу мәгънәсе ачык беленмәгән аятьләргә тәэвил ясап, мәгънә бирергә һичкем белмәс, бары Аллаһ Үзе генә белер. Әмма күңелләре хаклык ягына авышкан хакыйкый галимнәр: «Коръәннең һәр сүзенә ышандык, барчасы да Раббыбыздан килгән хак сүзләр, мәгънәсе ачык булган аятьләр белән гамәл кылабыз, мәгънәсе ачык беленмәгән аятьләрне Аллаһка тапшырабыз», — диләр. Кешеләр һәммәсе дә вәгазьләнмәс, фәкать саф күңелле, камил акыллы кешеләр генә Коръән белән вәгазьләнеп гамәл кылырлар» («Гимран» сүрәсе, 7 нче аять).

Шуны да белергә кирәк: һәрбер аятьне яки хәдисне һәр кеше үзенчә аңлап, үз ягына каерырга мөмкин, чөнки Коръәндәге аятьләрне төрлечә аңларга була. Аларны ничек аңларга кирәк икәнлеген зур дин галимнәреннән белә алабыз.

Татар мөселманнары үз нәфесләренә туры килә торган фикерләргә түгел, ә Коръән һәм сөннәттән алынган ачык дәлилләргә генә таянырга тиешләр. Нәкъ менә шул сыйфат Аллаһның дөрес юлга керткән колларына хас.

Коръәндә әйтелә:

«Әмма хак мөэминнәр сыннарга гыйбадәт итүдән һәм бидгать гамәлләрне кылудан сакландылар һәм Аллаһка кайттылар, ягъни һәрвакыт Аңа итагать иттеләр, аларгадыр җәннәт белән сөенү. Колларыма җәннәт белән сөенү бир. Алар сүзне ишетеп яхшысына гына иярерләр, Аллаһ аларны туры юлга күндерде, һәм алар акыл ияләредер» («Зүмәра» («Халык төркеме») сүрәсе, 17-18 нче аятьләр).

8. Адаштыручы дини җитәкчеләр.

Мөселман өммәтенең таркалуына булышлык иткән тагын бер сәбәп — адаштыручы имамнар һәм дини җитәкчеләр. Мондый имамнар һәм «галимнәр» бик күп кешеләрне һәлак иттеләр һәм адаштырдылар.

> **Дин гыйлеменә булсын, башка төр гыйлемгә булсын, кеше күбрәк тартылган саен, ул үзенең никадәр гыйлемсез икәнлеген күбрәк аңлый бара.**

Чынлыкта, галим булмаган, ләкин кешеләр аларны галимнәргә санаганнар үзләренә дә, ислам һәм мөселманнарга да бик зур зыян китерәләр. Мисал итеп күп кешеләрне үтереп, соңыннан тәүбә итәргә теләгән кеше турындагы хәдисне китерергә мөмкин. Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм әйткән: *«Сезгә хәтле яшәгән халыклар арасында туксан тугыз кеше үтергән бер бәндә бар иде. Көннәрдән беркөнне ул дөньяда иң күп белә торган кешене эзли башлый. Аңа галим булып саналган берәү янына барырга киңәш итәләр. Бу бара һәм шул галимнән сорый: «Мин туксан тугыз кеше үтердем, хәзер мин тәүбә итсәм, Аллаһ мине кичерерме?» Теге галим: «Юк», — дип җавап бирә. Бу кеше аны үтерә һәм шулай итеп үзе үтергән кешеләрнең санын йөзгә җиткерә. Ләкин бу кеше барыбер дөньяда иң күп белә торган кешене эзләвен дәвам итә. Аңа тагын икенче галим янына барырга киңәш итәләр. Бу бара һәм шул галимнән сорый: «Мин йөз кеше үтердем, хәзер мин тәүбә итсәм, Аллаһ мине кичерерме?» Теге галим: «Әйе, әлбәттә, тәүбә итәргә сиңа бернәрсә комачауламый»*, — дип дөрес җавап бирә һәм тегесе тәүбә итеп төзәлә. (Бу хәдис Бохари һәм Мөслим җыентыкларында килә).

Бу хәдистән күренгәнчә, дини җитәкче яки галим дөрес җавап бирмәсә, тәүбә итәргә уйлаган кешегә нинди зур зыян салырга һәм адаштырырга мөмкин икән. Бүгенге көндә мондый очраклар күзәтелә, хәтта мисаллар

китерергә дә кирәк түгел, бөтенебез моңа шаһит.

Һәр кеше кыямәт көнендә үз-үзенә җитәкче итеп куйган, ияргән кешесе белән кубарылыр. Шуңа күрә мөселман кем артыннан ияргәнлеген карарга, тикшерергә тиеш. Бу турыда Коръәндә түбәндәгечә әйтелә:

«Хисап көнендә кешеләрне үзләренең пәйгамбәрләре, имамнары һәм башка хуҗалары белән хөкемгә чакырырбыз, берәүгә гамәл дәфтәре уң яктан бирелсә, андый кешеләр дәфтәрләрен шатланып укырлар, алар җеп очы хәтле дә золым итмәсләр» («Бәни исраил» («Ягъкуб балалары») сүрәсе, 71 нче аять).

9. Мәзһәбләр аркасында тарткалашу.

Мәзһәбләр мәсьәләсе дә диндәге таркаулыклар темасы белән күпмедер дәрәҗәдә бәйләнгән, чөнки сөнниләрнең дөрес дип саналган дүрт дини юнәлеш вәкилләре арасында да каршылыклар бар. Ислам дине буенча, кем аларның кайсысын күңеленә хуш дип таба, шуны сайлый ала, әмма башка мәзһәбне сайлаган кешегә тел-теш тидерергә беркемнең дә хакы юк. Шулай ук мөселман кеше бернинди мәзһәбкә дә кермичә, үз гыйлемен кулланып, үз-үзенә мөҗтәһид булган икән, аны да гаепләргә кирәкми. Бүгенге көндә менә бу нәрсә татар мөселманнарына җитеп бетми. Хәтта нindидер бер мәзһәбкә фанатикларча ияреп, башка фикердәгеләрне күрә алмас дәрәҗәгә җитүчеләр бар. Кайда соң монда толерантлык?! Без үзебез башка милләт һәм дин вәкилләре белән дустату яшибез, дип мактанырга яратабыз, ә үзебез нindидер вак фикер төрлелеге аркасында бер милләттән, бер диннән булган дин һәм кан кардәшләребезне кимсетеп, төрле кушаматлар тагып, талашып, дошманлашып бетәбез түгелме? Хәзерге көндә танылган дүрт мәзһәб электән үк ислам галимнәре алдында бертигез дәрәҗәдә торган һәм аларның кайсысы өстенрәк, дигән сүзне акыллы кешеләр куертмаганнар һәм көчләп үз фикерләрен такмаганнар. Эшләр шул рәвешле булса, мәзһәбләр арасындагы каршылыклар да шунда ук юкка чыгачак. Мөселманнарга нindидер дини юнәлеш тирәли түгел, ә Коръән тирәли берләшергә кирәк.

II

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм дә әйткән: *«Минем һәм һидаяттә булган тугры хәлифәләр юлын үзегезгә лязем итеп тотыгыз һәм аңа азау тешләрегез белән ябышыгыз!»*

Ислам динендә бердәмлек, хәзерге көндә бигрәк тә, иң мөһим мәсьәлә булып тора. Моны Аллаһы Тәгалә Үзе Коръәндә әйтә:

«Без сезгә диндә шәригать төзеп бирдек, ул шәригатьне Нухка, һәм сиңа, Мөхәммәд, һәм Ибраһимга, һәм Мусага, һәм Гайсәгә васыять иттек, ягъни йөкләдек: «Без төзегән шул хак дин шәригатен тотыгыз, әмма хөкемнәрен бозмагыз, шәригатьне үзгәртмәгез һәм төрле фиркаләргә, төрле мәзһәбләргә бүленмәгез», — дип, һәр пәйгамбәргә һәм һәр мөселманга әмер иттек. Сезнең кешеләрне хак дин — исламга дәгъват итүегез мөшрикләргә бик авыр эш булды, ягъни ислам динен кабул итү аларга утка керүдән дә авыр булды. Аллаһ Үзе төзегән хак дингә Үзе теләгән кешесен ихтыяр итәр һәм анда тартыр, һәм Аллаһка итагать белән кайткан кешене Ул хак дингә күндерер» («Шура» («Киңәш») сүрәсе, 13 нче аять).

Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә үзләренең диннәрен төрле төркемнәргә бүлеп бетергән кешеләр Мөхәммәд пәйгамбәргә бернинди катнашлары булмаганлыгын хәбәр итә.

Шулай ук Раббыбыз әйтә:

«Тәкъвасыз мөселманнар Аллаһ төзеп биргән хак динне төрле кисәкләргә бүлделәр һәм төрле батыл мәзһәб ияләре булдылар. Әй, Мөхәммәд, син аларның һичбер эшләре турында со-

ралачак түгелсең. Аларның эшләре Аллаһка тапшырылмыштыр, соңрак Аллаһ үзләренә кылган эшләре белән хәбәр бирер» («Әнгам» («Терлек») сүрәсе, 159 нчы аять).

Үзләрен ислам дине исеме астына кертүче бөтен татар мөселманнары төрле вак мәсьәләләргә игътибар итмичә, һәрвакыт бердәм булырга тиешләр. Әгәр дә алар арасында иҗтиһадка караган яки башка мәсьәләләрдә бәхәсләр чыкса, алар бер-берсен күралмау дәрәҗәсенә төшәргә тиеш түгел. Киресенчә, дин кардәшләре булып, ярдәмләшеп яшәргә бурычлы.

III

Дин гыйлеменә булсын, башка төр гыйлемгә булсын, кеше күбрәк тартылган саен, ул үзенең никадәр гыйлемсез икәнлеген күбрәк аңлый бара. Бу бер безнең генә фикер түгел, һәм ул әле генә безнең башыбызга килгән уй да түгел. Бу — хакыйкать. Дөрестән дә, Аллаһы Тәгаләнең гыйлемен белеп бетерү мөмкин эш түгел. Раббыбыз Үзе дә безгә: *«Адәм балаларына гыйлемнән бик аз гына бирелде»*, — дип белдерә. Шулай ук Аның: *«Менә бүген динегезне төзеп бетереп тулы кылдым, бирәсе нигъмәтләремне дә ислам дине белән бергә биреп бетердем сезгә»*, — диюе, бу диннең камил рәвештә безгә иңдерелеп бетеп, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең: *«Әй кешеләр, шаһит булыгыз, мин сезгә Аллаһның хөкемнәрен ирештердем!»* — диюеннән бу диннең камил рәвештә өммәтенә ирештерелүен без барыбыз да аңлыйбыз. Барлык хөкемнәр Аллаһы Тәгаләдән булып, аларны пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең камил рәвештә үтәп күрсәтүен без барыбыз да таныйбыз.

Кеше бит ул шундый зат, кайчакта хаталанырга мөмкин. Ул кимчелекле. Аллаһы Тәгалә тарафыннан әйтелгән: *«Рәсүлегездә сезгә иң яхшы үрнәк»*, — дигән сүзләргә һәм пәйгамбәребез салләллаһү галәйһи вә сәлләмнең: *«Мине күрмичә күргән кебек, минем сүземә иярүчеләр...»*, — дип белдерүенә карамастан, кешеләр Аллаһ һәм Аның рәсүле сүзләрен калдыралар. Ә аннан соң үз араларындагы олугларга охшарга тырышулар, алар үрнәге, алар юлы белән кызыксынулар китә. Күпчелек фикеренә каршы килмим әле, нәрсә, мин генә бик акыллымы әллә, дип кирәкмәгән эшләргә кереп китүләр... Һәм шундый чиктән ашу кебек төрле эшләр инде бу кешегә хакыйкый дин булып күренә башларга мөмкин.

Без барыбыз да Аллаһның түбәндәге аятен беләбез, ләкин бик азлар гына аны гамәлдә куллана:

«Әй, мөэминнәр! Аллаһка итагать итегез һәм рәсүлгә итагать итегез! Шулай ук үзегездә булган Коръән белән гамәл кылып, Коръән дәлилләре белән әмер итүче дини җитәкчеләрегезгә дә итагать итегез! Әгәр бер дини мәсьәләдә бәхәсләшсәгез, ул мәсьәләне Аллаһ китабы — Коръәнгә кайтарыгыз! Әгәр Коръәндә ачык хөкем табылмаса, ул вакытта рәсүл галәйһи вә сәлләм гамәленә кайтарыгыз! Әгәр Аллаһка һәм ахирәт көненә ышансагыз. Әнә шулай һәр эшне Коръән, сөннәт үлчәве белән хәл итсәгез, сезнең өчен хәерле һәм ахыр нәтиҗәсе күркәм булыр» («Ниса» («Хатыннар») сүрәсе, 59 нчы аять). Бу аятьтә ачык мәгълүм булды ки: көчле иман, дөрес дин Коръән, сөннәт белән гамәл кылганда гына буладыр. Алар белән гамәл кылмау Аллаһка һәм ахирәт көненә иманның юклыгына дәлил була аладыр.

Без үзебез бу язмабыздан соң шундый фикергә килдек: юлыбыз бер — Аллаһ күрсәткән юл булырга тиеш. Һәм үрнәк алырга тиешле кешебез — Аллаһы Тәгалә тарафыннан бар галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән хак пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһү галәйһи вә сәлләм. Ә кем башка кешене сайлый — ул аның ихтыяры. **Диндә көчләү юк, өндәү һәм аңлату гына бар.** ■

Яшел Тау итәгендә

Рәмзия Габделхакова

Лениногорски — шаккатмалы гүзәл, әмма кырыс һәм салкын шәһәр. Көзләре дымлы, томанлы. Кышлар иртә килә, урамнарын түшәк-түшәк кар көртләре күмә. Язларын, күрше Әлмәттә тузганаклар ду килеп чәчәк атканда, без әле кар боткасы ерып йөрибез. Язлар озын, җәйләр кыска бездә. Шуңамыдыр, шәһәребезне бик тә чибәр, әмма салкын йөрәкле холыксыз кызга охшатам мин.

Утыз биш ел гомер шунда үткән. Ирем белән бирегә килеп урнашканда октябрь ае иде. Яңгырлы, томанлы иде ул көз. Әмма, чуар күлмәген киеп, өрфиядәй томанга күмелеп, таулар куенында утыручы шәһәр миңа барыбер бик матур һәм серле тоелды.



Бу матурлык юктан бар булмаган, әлбәттә. Биек наратлар, сылу каеннар үскән Яшел Тау итәгендә иң башта җиргә казып ясалган землянкалар, аннары палаткалар пәйда була. Биредә нефтьчеләр һәм төзүчеләр яши. Соңрак палаткаларны бараклар алыштыра, берничә урамлы Беренче посёлок барлыкка килә. Аны **Яшел тау** — Зеленогорски дип йөртә башлыйлар. 1955 елның августында нефтьчеләр бистәсенә шәһәр статусы бирелә. **Яңа Писмән** авылына терәлеп диярлек барлыкка килгән яңа шәһәрне дә Зеленогорски дип атарга булалар. Әмма «бер төркем иптәшкә» бу исем бик гади тоелган, күрәсең, шәһәргә Ленин исемен бирү тәкъдиме белән чыгалар. Шулай итеп, СССР дигән бөек илдә икенче Лениногорски каласы пәйда була (Беренчесе — Казакъстанда).

Бу шәһәргә тәүге тапкыр аяк басучыларның аңа бер күрүдә гашыйк булуын үз мисалымда беләм. 1970 елда әтиебез сеңлем белән мине бирегә туганнарыбызга кунакка алып килгән иде. Җәй уртасы иде ул. Ап-ак йортларның, серле урамнарның яшеллеккә, гөлчәчәккә күмелеп утырган чагы иде. Шул матурлыкны көмеш чыкларга күмеп, асфальт юлларны ялтыратып, яңа гына җылы яңгыр явып үткән. Ничек гашыйк булмыйсың ди?! Бирегә мине шул мәхәббәт һәм «Киләчәктә мин монда яшәячәкмен!» дигән хыял ымсындырып китерде бугай…

Лениногорски үзенең төзеклеге, җыйнаклыгы белән хезмәтен күңел биреп башкарган сәләтле архитекторларга бурычлыдыр, мөгаен. Шәһәр төзелеше Ленинград проект институтының («Ленгипрогор») генераль планы нигезендә алып барыла. Күз алдына китерегез: каланың үзәген өч озын, төзек урам тәшкил итә. Җәяүлеләр сукмагын алмагачлар, юкә, тирәкләр озата бара. Ленинград һәм Шашин урамнарына параллель булган уртанчы

урам — ул әле бүген дә **Ленин проспекты** дип атала — шау яшеллектән тора. Сквер киң урамны кыл урталай бүлә. Мәйданы сигез гектардан артык булган бу сквер күл буена кадәр яшел тасма булып сузылган. Анда рәт-рәт чыршы-нарат, каен, өрәңге, юкәләр үсә. Май аенда алмагач, шомырт агачлары, сирень куаклары шау чәчәккә күмелеп, бар дөньяны аклыкка, хуш искә күмә.

Әлеге агачларны элеккеге зур ерым урынына бөтен шәһәр халкы бергәләп утырткан. Ул елларда атна саен диярлек өмәләр оештырыла. Бакча-скверларны төзекләндерүдә меңләгән кеше катнаша. Бер елда гына да утыз меңнән артык агач һәм куак утыртыла! Шәһәрне яшелләндерү белән Михаил Фомин җитәкчелек итә. Бу тырыш, тынгысыз затны бүген дә рәхмәт сүзләре белән искә алалар. Скверда Фоминның үзенә дә истәлек тактасы куелган. Үзе китсә дә, җирдә изге эше, якташлары хәтерендә якты исеме калган.

Ленин проспектындагы бу сквер — биниһая тыныч яшел почмак, шәһәр халкының иң яраткан урыны. Гашыйк парлар, яшь балалы әти-әниләр, әби-бабайлар бирегә һава суларга, ял итәргә килә. Анда җәяүлегә хөррият, телисең икән, яланаяк йомшак чирәмле сукмактан атла, анысы ошамаса, кәттә туфлиләреңбелән бетон «идәнне» яңгыратып уз. Утырып ял итәр өчен адым саен уңайлы эскәмияләр куелган. Ленин проспекты белән Тукай урамы кисешкән урында, баш очына салават күпере элеп, данлыклы фонтан көмеш тамчыларын сибеп утыра. Данлыклы дим, чөнки аны Лениногорскиның яшьтәше, символы, дияргә була. Моннан ун еллар элек фонтанны яңартырга теләп, сылу балериналарны шыпырт кына каядыр алып киткәннәр, алар урынына алагаем зур шар бастырып куйган иделәр. Моңа Лениногорски халкы аяк терәп каршы чыкты, зарлы хатлар язды, тавыш күтәрде, әмма дә үзенекен итте, балериналар кабат үз урынына килеп басты.

Шәһәр уртасындагы әлеге скверда истәлекле урыннар күп. Аның бер башында, түбәсендә Россия, Татарстан, Лениногорски флагларын җилфердәтеп, өч катлы шәһәр мэриясе утыра, ә икенче очында биек **Нефтьчеләр монументы** күккә сузылган. Аңа **сугыш һәм хезмәт батырлары аллеясы**, **Мәңгелек ут ансамбле** килеп ялгана. Әфган, Чечня конфликтларында катнашучыларга, чернобыльчеләргә

һәйкәлләр дә шушы скверга урнаштырылган. Истәлекле урыннар, һәйкәлләр күп бездә. Исеме телдән төшсә дә, Ленин бабай әле бүген дә Лениногорскиның үзәк мәйданында, кулын алга сузып, кемнәргәдер юл күрсәтеп тора.

Әгәр безнең якларга кунакка килеп, шәһәрегезнең иң матур урыннарын күрсәт әле, дисәгез, мин сәяхәтне шәһәр мәйданыннан башлап, сквер буйлап сезне күл буена алып төшәр идем. Зәңгәр күкләрны кочагына сыендырып, көзге сыман ялтырап яткан ул тыныч күл буена шәһәребезнең тагы бер горурлыгы — **«Ихлас» мәчете** урнашкан. Ә аның каршында гына гөлләргә күмелеп **«Мәхәббәт» паркы** җәелеп ята. Яшь парлар анда **«Мәхәббәт күпере»** оештырып куйды, култыксаларына эленгән йөрәк-йозакларның чутына чыгышлы түгел. Озакламый яңа күпер кирәк булыр, мөгаен.

Лениногорски урман, таулар ышыгында утыра. Шуңа күрә, паркны урман эчендә оештырып куйганнар. Ул шулай дип атала да: **«Урман паркы»**. Лениногорски спортчыларының иң яраткан урыны ул, кышларын чаңгыда шуалар, трамплиннан сикерәләр, җәйләрен роликларда чабалар. Урман һавасын суларга килгән җәяүлеләр өчен бормалы, серле сукмаклар бихисап анда, кереп адашуың да бар.

Әгәр безнең гүзәл калабызга югарыдан хозурланасыгыз килсә, мин сезне Яшел Тауның иң биек ноктасында урнашкан **Ротондага** алып менәрмен. Шунда сер итеп кенә, Лениногорскига багышланган җырымны сөйләп (җырларга моңым юк...) күрсәтермен:

Горур таулар кочагына
Иркәләнеп сыенгансың.
Шушы җирне нурга күмеп,
Ямьләндереп син тугансың.
Лениногорск — нурлы калам!
Тауларыңда шаулый урман.
Гөлбакчадай урамнарың,
Сине күреп туялмамын. ■

АЛТЫНГА ТУЗАН КУНМЫЙ

Рәис Зарипов

Халык арасында бер мәзәк йөри. Галәмгә беренче космонавт очу турындагы хәбәрдә ул чактагы Илбашы **Никита Хрущёв** «Галәмдә — Гагарин!» дигәнне «Галәмдә — татарин!» дип аңлаган һәм бик ярсып:

— Галәмгә татар очарга тиеш түгел, тиз арада кире борыгыз! — дип боерган, ди, имеш.

Дөнья хәлен кем белә, бәлки, чынлап та, шулай булгандыр?! Безгә ул ягы караңгы. Әмма кызыгы шунда: **Юрий Гагаринның** тормыш юлы татарлар белән тыгыз бәйләнештә үтә. Аның, мәсәлән, галәмне яуларга тиешле беренче төркем очучылар арасындагы бердәнбер татар егете **Марс Рәфыйков** белән яхшы мөнәсәбәттә булуы мәгълүм. Хәрби самолётларда очарга аны икенче бер милләттәшебез, Ырынбур югары хәрби авиация училищесы очучы-инструкторы **Ядкәр Шакир улы Акбулатов** өйрәтә. Аның хакында Юрий Гагарин:

— Ул мине зәңгәр күкне бөтенләй башкача күрергә өйрәтте. Самолётларны, очу серләрен, эти миңа балта белән фуганка тотарга өйрәткәндәй, гаять гади итеп аңлатты, — дип еш әйтә торган булган.

Билгеле инде, «Галәмгә юл» китабын «Очарга өйрәткән укытучыма һәм тәрбиячемә» дигән сүзләр язып бүләк итүе илдә генә түгел, ә бәлки бөтен дөньяда беренче булып галәм киңлекләрен иңләгән шәхеснең үз остазына карата ихтирамын ачык күрсәтә.

Бактың исә, Гагаринның беренче шофёры да татар булган икән. Ул — Тукай районының Теләнче Тамак авылында туып-үскән **Гариф Сәйфиев** атлы егет. Хәрби хезмәтен Мәскәү янындагы космонавтлар әзерләү үзәгендә үтә. Өч ел дәвамында бик җаваплы вазифа йөкләнә аңа: якташлары белән космонавтларны йөртә. Космоска беренче булып юл ярган Юрий Гагариннан тыш, **Герман Титов, Валерий Быковский, Валентина Терешкова, Андриан Николаев, Павел Попович** белән якыннан аралаша. Тырышлыгы, уңганлыгы, осталыгы белән аларның хөрмәтен казана. Әлбәттә, әлеге уңай сыйфатлары Юрий Гагарин игътибарыннан да читтә калмый. Ул космонавтлар әзерләү Үзәге башлыгы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое генерал-полковник **Михаил Одинцовны** йөрткән Гарифка

Беренче рәттә (сулдан өченче) – **Никон Егоров; икенче рәттә** (сулдан өченче) – **Юрий Гагарин**

үз шофёры булырга тәкъдим итә. Ник ышангандыр, күрәсең, беренче машинасын сайлап алуны тулысынча аның ихтыярына калдыра.

Хәрби хезмәте тулгач, дусты Юраның аны үз вазифасында калырга кыставы да кызыклы. Әле хәтта сеңлесе белән таныштыруны да кирәк таба. Тик менә авылдан чыккан татар малайлары нечкә күңеллерәк шул алар, туган төбәкне ныграк сагынучаннар. Гарифның да туган ягын чит-ят төбәкләргә алыштырасы килми, авылга кайтырга карар кыла. Мәгәр космонавтлар Үзәге белән ике яклы элемтәләре озак еллар дәвам итә.

«Галәмгә юл» китабын «Очарга өйрәткән укытучыма һәм тәрбиячемә» дигән сүзләр язып бүләк итүе илдә генә түгел, ә бәлки бөтен дөньяда беренче булып галәм киңлекләрен иңләгән шәхеснең үз остазына карата ихтирамын ачык күрсәтә.

Янә бер мавыктыргыч язмышлы шәхес — Мөслим районының Яңа Усы авылыннан чыккан **Никон Егоров** — Юрий Гагаринны яхшы белгән. Илнең галәмгә омтылган чагы. Беренче космонавтлар төркеменә берничә мең хәрби арасыннан ике дистә ир-ат вак иләктән иләнеп сайлап алына. Аларны галәмгә әзерләүче галимнәр төркеменә Жуковский исемендәге хәрби һава академиясенең икътисад кафедрасы мөдире, икътисад фәннәре кандидаты, полковник Никон Егоров та кертелә. Сугышның башыннан алып ахырына кадәр фронтның алгы сызыгында булган кыю командир әнә шулай итеп булачак космонавтларга политэкономиядән белем бирә. Татар милләте исә тагын бер каһарман улы белән хаклы рәвештә горурлана ала: Юрий Гагарин, Герман Титов, Валентина Терешкова, Валерий Быковский һәм башка күп кенә совет космонавтлары — якташыбыз, милләттәшебез Никон Романовичның шәкертләре.

Никон Егоров 1906 елда туа. Кешелек тарихындагы гаять катлаулы һәм кырыс дәвернең башланган мәле. Шул гасыр башында туганнарны дәһшәтле чорлар сагалый. Усы егете Никонга да зур сынаулар әзерли язмышы. Беренче Бөтендөнья сугышы башланып өч ел үтүгә, Россияне революциянең канлы ялкыны чорнап ала. Ул Гражданнар сугышына әйләнеп китә һәм дүрт еллап дәвам итә. Нәтиҗәдә

дистәләрчә миллион кешенең гомере өзелә, шуңа ачлык афәте өстәлә, авыл-калаларны ятим, үксез балалар баса. Янә шунысы игътибарга лаек: дәһшәтле «кызыл террорлары» белән тарихка канлы юллар язып калдырган яңа хакимият яшь буынга карата, киресенчә, мәрхәмәтле сәясәт үткәрә. Илдә азмы-күпме тынычлык урнашуга, урам чатында калган балаларны дәүләт канаты астына сыендыру җәһәтеннән җитди адымнар ясала башлый. Күрше Башкортстанның Бәләбәй каласында 1922 елда педагогия техникумы ачылуы — шуның бер чагылышы. Шул хактагы хәбәр Мөслим төбәгенә дә килеп ирешә. Моны ишетү белән, тәвәккәллеге белән аерылып торган Никон юлга кузгала.

Зирәк үсмерне кире бормыйлар — техникумга кабул итәләр. Аң-белемгә омтылышы көчле, тиз арада үзен уңай яктан гына таныта. Җыелышларда кыю чыгышлары белән җәлеп итә, студентлар хорында һәм спорт ярышларында теләп катнаша. Андый актив кеше игътибар үзәгеннән читтә кала димени — техникумның комсомол секретаре итеп сайлап куялар үзен. Укуын тәмамлагач, Бакалы районындагы Верхне-Троицк авылы крестьян яшьләре мәктәбенә мөдир итеп җибәрәләр.

Сыйнфый көрәшнең кызган чагы. Ата — улны, ана кызны белми. Берәүләр гомерләре буена җыйган мал-мөлкәтләрен саклап җан тартышса, икенчеләр, киресенчә, аларның байлыкларын уртак милеккә әйләндерү өчен көрәшә. Никон — соңгылар сафында. Туган һәр көне яшәү белән үлем арасында үтә. Төнлә читән артыннан атып та, янап та карыйлар. Мәгәр куркыта алмыйлар. Күрше Водвиженка авылындагы комсомол секретаре **Илья Черняткинны** кулак **Щукин** атып үтергәч, Никон аның урынына баса. Бераздан, партиянең өлкә комитеты сыналган яшь егетне Мәскәүдәге Орджоникидзе исемендәге икътисад институтына укырга җибәрә. Яхшы укый, аспирантурада кала.

Ә бу вакытта туган авылында бөтенләй башка вакыйгалар булып ята. Авылдашлары «ярдәме» белән атасын кулак ясап авылдан сөрәләр. Өч ел «утырып» кайта. Югыйсә, эшчән һәм уңган игенче. Туплаган байлыгы юк. Әмма ялкау хөрәсәннәрне кызыктырырлык, көнчелек утында яндырырлык алтыпочмаклы йорты, аты һәм сыеры бар. Бүген Усы авылында яшәүче сеңлесе **Галина Романовна**, моны көнчелек галәмәте белән кылынган явызлык булгандыр, дип гөманлый. Ни дисәң дә, үз атасын саткан **Павлик Морозовлар** заманы бит. Туган-туганны, күрше күршене аяп тормаган.

Әнә, Галина Романовнаның каенатасын, ягъни ире Прокопийның атасын ун елга утыртып куялар ич. «Кулак» тамгасы тагып. Туры сүзле була **Дмитрий Прокопьевич**. Авылдашларына: «Шушы власть яшәсә, уч төбемә йон чыгар», — дип белдерә. Әлбәттә, шул ук төнне алып та китәләр. 1943 елда көч-хәл белән Пермь якларыннан туган төбәгенә кайтып егыла ул.

Никон исә — Ватан сугышында. Җиңүдән соң Берлин коменданты, генерал-полковник Николай Берзарин карамагына җибәрәләр. Үзәк комендатурада дүрт ел буена икътисади идарә башлыгы вазифасын башкара. Бөтен Германия җимерелеп беткән. Әйтерсең, ул хәрабәләрдән генә тора. ГДРның халык хуҗалыгын аякка бастыруда Никон Егоровның да саллы өлеше бар.

1949 елда, ниһаять, гаиләсе янына Мәскәүгә кайта. Кабат хатыны **Елена Михайловна**, кызлары **Люда** һәм **Таня** белән бергә яши башлыйлар. Өч Кызыл Йолдыз һәм Кызыл Байрак ордены, күп санлы медальләр белән бүләкләнгән өлкән офицер тыныч тормышка кайта. Жуковский исемендәге хәрби-һава академиясенең политэкономия кафедрасы мөдире итеп билгелиләр күренекле якташыбызны. 15 ел шул җаваплы вазифада эшли.

Мәгәр туган авылын бер дә онытмый. Җае чыккан саен кайтырга тырыша. Сагынуы көчле булган, күрәсең, Усы урман-кырларын әйләнми калмый.

Чишмәләрен барлый. Агроном булып эшләүче кияүләре Прокопийны бик үз итә. Аның сиртмәле мотоциклы да ярап куя табигать хозурына чыгарга.

— Туган яктан бизмәде, гел ашкынып кайтты. «Әһ» тә дими 20 чакрым араны узар иде. Матур җырлый. Үзе — көрәшче. Киңәш сорап килүче авылдашларның да иге-чиге булмый иде ул кайтканда. Үзебез дә еш барып тордык кунакка, — дип үткәннәрен искә ала Галина Романовна.

Мантыйк буенча, андый якташың белән горурланырга, аңа карата ихтирамның иң зурысын күрсәтергә кирәк тә соң. Юк шул! Һаман шул хөсетлек, көнчелек кимерә милләтне.

Тик, ни кызганыч, күзләрен көнчелек сөреме каплаган авылдашлары да табыла араларында. Алары еш кына шикаять язып юаналар. Анда язганнарның төп мәгънәсе: «Ни өчен Усы авылының «кулак малае» шундый зур урында эшли?» — дигән сорауга әйләнеп кала. Нәкъ менә андыйларның «тырышлыгы» белән тагын да югарырак дәрәҗәләргә ирешә алмый кала Никон Романович. Өч тапкыр инфаркт кичерүе һәм алтмыш яше тулуга башына кан савудан вафат булуы тәгаен әлеге хөсетлекләр нәтиҗәсе булгандыр, дип расларга нигез бирә.

Ни генә димәсеннәр, мондый вазгыять һич башка сыймый. Илдә иң олы ихтирам-хөрмәткә ия булганнар — галәмне яулаучылар. Юрий Гагарин исеме бөтен дөнья халыклары теленнән төшми. Күпләр өчен аны ерактан гына булса да күреп калу — тормышка ашмас хыял. Ә Никон Егоров Юрий Гагарин һәм башка космонавтлар белән даими аралаша, бергәләп төшкән фотосурәтләре Усыга да ирешә. Мантыйк буенча, андый якташың белән горурланырга, аңа карата ихтирамның иң зурысын күрсәтергә кирәк тә соң. Юк шул! Һаман шул хөсетлек, көнчелек кимерә милләтне.

Берчакны шулай Усыга чакыртып кайтаралар үзен. «Кулак малае»ның данлыклы исеме тәки тынгы бирми тар күңелле кайберәүләргә. Якташларын каралтырга теләүчеләр клубка җыела. Райком секретаре да килеп җиткән. Чөнки тәртибе шулай. Никонны күрүгә, тегеләр кыбырсый башлый.

— Син, Никон Романович, чыгып тор инде, авылдашларың сөйләргә кыймый үзең булганда, — диләр аңа.

Тыңлый. Хәрби кеше бит. Әмма чыгып бераз торуга: «Мин Мәскәүдән ишек артында торырга кайтмадым», — дип кире керә.

Ул кергәндә Ермолай дәдәй дигәннәренең Егоровларның ничә дисәтинә җир биләүләре турында сөйләп торган чагы була.

Никон Егоров:

— Бәй, сезнең җирләрегез безнекеннән күбрәк түгел идеме соң?! — дип, тегене үз урынына утырта.

Мондый омтылышлар берничә мәртәбә кабатланса да, хөсет җаннар уңышка ирешә алмый. Алтынга тузан куна димени? Бөек Ватан сугышы ветераны, күп орден-медальләр кавалеры полковник Никон Романович Егоров үзе дә ваклыклардан өстен кала белә. Иң мөһиме: мондый ыгы-зыгы аның туган ягына мәхәббәтен, авылдашларына ихтирамын юкка чыгара алмый. Үз төбәгенең чын патриоты булып кала. Якташлары да онытмый аны. Мөслим музеенда аның хакында байтак материал тупланган.

Гәрчә ул күбрәккә лаек. Моны дусты, Уфа журналисты Сөләйман ага Сәетбатталов бик ачык итеп язып калдырган:

«...Татар халкы үзенең бу данлы улы белән горурлана ала. Зур галим, хәрби эшлекле иде Никон Романович Егоров. Аның гомер юлы һәм эшчәнлеге яшь буыннар өчен үрнәк булып торырлык». ■

КАДЕРЛЕЛӘР ҺӘМ КАДЕРСЕЗЛӘР

Фәнзаман Баттал

Инде янә ата-бабаларыбыз кебек әдипләребез хәленә, кичерешләренә кире кайтыйк — нәрсә генә димә, аларның тормышы безнекеннән дә фаҗигалерәк булган бит… Безнең әле, шөкер, өс бөтен, борыннан чыга төтен — сигаретларыбыз кулда, баш очыбызда Ильич лампасы балкый, — димәк, каләмебез дә чираттагы юлда!

Татарстан язучыларының тагын бер үтенечен игътибардан үткәрик. Монысы ТАССРның Халык Комиссарлары Советына 9 декабрьдә язылган:

«Татарстанның иң күренекле язучыларыннан саналган Мирсәй Әмирнең инде ТДАП (ТДАТ түгелме икән? — Ред.) тарафыннан куелуга кабул ителгән Ватан сугышы турындагы пьесасын эшкәртү-кабат эшләү белән мәшгуль булуын, театр репертуарында оборона пьесаларының юклыгын

* Ахыры. Башы журналның 6 нчы санында.



#7/166

Зам. Председателя СНК ТАССР

тов. ТЕНЧУРИНУ

В виду того, что один из крупнейших писателей Татарии тов. Мирсай Амиров занят над работой по переделке пьесы об отечественной войне которая в основном принята ТГАП к постановке и учитывая, что в репертуаре Театра нет оборонных пьес Правление ССП ТР просит Вас дать распоряжение об освобождении тов. Амирова от посылки на трудовой фронт.

т.секр.Правления ССП Татарии: /Имамутдинов/

истә тотып, Татарстанның Язучылар союзы иптәш Әмировны хезмәт фронтына җибәрүдән азат итү турында боеруыгызны сорый».

Димәк, татар язучыларының ул чордагы иң оста каләмлесен — театр сәнгате өчен бер-бер артлы талантлы, үтемле трагедияләр һәм комедияләрне, көн кадагына суга торган публицистик әсәрләрне, җитди һәм юмористик хикәяләрне каләменнән коеп кына торучы әдипне халык теленә «трудармия» булып кергән, теге яки бу сәбәпләр аркасында сугышка җибәрергә ярамаган кешеләрнең коллык урыны дип саналган, авыр хезмәт шартлары белән күпләрне гарипләндергән хезмәткә тыкмак булганнар. Чынбарлыкта аны болай аңларга кирәк: «Чурту-матр, татарин, үзеңне сөйгән, әсәрләреңне сокланып укый торган татарларың белән!..»

Ә инде «трудармия»нең нәрсә икәнен сабый чагымнан ук үзем дә беләм. Чөнки сугыш башланганда кырык сигез яшьлек әткәмне, олы яшьтә булуы аркасында фронтка ук җибәрә алмасалар да, шушы «трудармия»гә аткарганнар — Казанда бил бөккән, иң авыр эшләрдә көне-төне дүрт ел буе иза чиккән... Берочтан анысын да әйтеп үтим: мин әткәмнең нинди кыяфәтле кеше икәнен дә илле өч яшендә генә белә башладым. Ул киткәндә ике яшьлек хәтер утырмаган бала булганмын, ә инде ул кайтып төшкәндә мәктәпкә керү дәрте белән йөрүче малай идем... Үсә төшкәч, әлеге «трудармия»нең нәрсә икәнен әледән-әле сөйләп ала иде әткәй. Инде дә язучыга әверелә башлавымны аңлагач, кайгыга калгандай, әйтеп куйды:

— Бәхетең булмас, улым, язучы булсаң... Мин язучыларның хәлләрен «трудармия»дә чакта нык аңладым. Ашарларына да юк иде аларның. Анаң миңа мичтә киптерелгән ит, бәрәңге ташып торды бит. Ул мескеннәр менә шуларны ашашырга килә иде. Ә инде Мәскәүдән китерелгән язучылар илдә сугыш барганын да белмәгәндәй, затлыдан-затлыны эчеп, тәмледән-тәмлене ашап, ирләре сугышка киткән хатыннар белән тансы-мансы кичәләрендә кәеф-сафа кора иде. Безнең өстән командавайт иткән әфисәрләр дә шулар белән типтерде.

Мирсәй Әмир, беркатлырак итеп фикер йөртсәк, минем әткәй янына җибәреләсе булган. Ләкин җибәрми калдырганнар. «Рәхимлек» кылып... обком кушып фронтка — сугыш мәхшәренең уртасына тыкканнар. Андагы «Ватан өчен» газетасын чыгаруда катнашсын, дип... Шөкер, исән калган! Сугыштан соң да утыз биш ел иҗат итү бәхетенә ирешеп дөнья куйды, мәрхүм...

Сугышка киткән язучыларыбыз үлә-кырыла тора, ә Мәскәүдән, СССР Язучылар союзыннан хатлар, телеграммалар һаман агылып тора.

Табылган бер өем документларның кайберләрен укыганда хурлану-гарьләнүдән күзгә яшь тә килә кайчак... Күңел сизә, бик сизә: Татарстан Язучылар оешмасы чынлыкта бөтен татар дөньясының Язучылар союзы бит инде ул, югыйсә, әмма югары түрәләрнең генә түгел, вак-төяк идарәләрнең дә союз белән санлашмавы, аның үтенечталәпләрен укып та карамавы, колакка да элмәскә тырышуы, кадерсез күрүе ярылып ята. Мәсәлән, ул чорда татар әдәбиятының аксакалы, иң абруйлы әһеле булган Шәриф Камалның фатиры 25 нче йортлар идарәсенә караган. Союз җитәкчеләре, олуг әдипкә иҗат шартлары тудыруны кайгыртып... «домоуправ»ка үтенечле хатлар

яза! Камалның Ленин орденлы язучы булуын, аның фатирында болай да эвакуациядәге ике кешенең урнаштырылуын һәм әдипнең «серьёзно болен» икәнлеген, зур, мөһим әсәр иҗат итүен, шуңа күрә аңа аеруча игътибарлы булырга, тынгылыгын бозмаска кирәклеген аңлатырга тырышканнар. Казан шәһәр советы депутаты икәнлеген дә язарга онытмаганнар. Болай ук вакланунын сәбәбе нәрсәдә соң? Сәбәбе шунда: әлеге «домоуправ» әдипнең фатирына тагын ике-өч кеше кертергә карар кылган икән! Файдасы тигәнме соң әлеге үтенечле хатның? Юк. Чөнки, бая (*алдагы санда — **ред.***) аңлап үттек инде: бу хат язылган вакытта Шәриф Камал фатирында дүрт өйдәш яшәгән булса, яңа документ раславынча, ул җидегә җиткән…

Кайсы язучы ничектер, белмим, ләкин үзем мондый хәлдә яза алуымны акылга сыйдыра алмыйм. Бүлмәмдә бер генә кунак уралып йөрсә дә, мин инде язучы түгел, кулым каләмгә үрелми… Шундый хәлдә берничә көн яшәргә туры килеп, зиһенемдә тәмам өлгереп җиткән кайсыдыр әсәремне көнендә-вакытында кәгазьгә бушатмасам, баш миемнең дә, йөрәгемнең дә кабарганын сизәм; эчендәге суы шаулап кайнап утырган, әмма клапаны ачылмый торган пар казаны кебек шартлармын сыман… Мөгаен, Шәриф Камал да шул халәттә яшәгәндер. Чыдагандыр, түзгәндер дә «шартлагандыр»… Чөнки чит-ят кешеләр мыжгыган шушы «базар» уртасында яза алмаудан гаҗиз булып бер генә ел яшәгән һәм кинәт (скоропостижно) үлеп тә киткән ул… Язмамның беренче өлешендә Мәскәү эвакуацияләгән орденлы язучыларның нинди зур хөрмәттә булуын шәйләгән идек инде. Алар Татарстанның кашында, зур түрәләрнең игътибар үзәгендә яшәгән. Ә шундый ук Ленин орденлы татар язучысының язмышы белән куян шулпасының шулпасы дәрәҗәсендәге «домоуправ» та уйный алган, үлемен тизләткән… Әлбәттә, ул чорда тылдагы татар язучылары кичергән күп фаҗигаләрнең бер мисалы гына бу.

Ә өстән таләпчән, мәҗбүр итүчән телеграммалар һаман-һаман килә тора…

«Казань. Дом печати, Союз писателей. Ицхакову.

Убедительно прошу помочь выездом Чистополь матери писательницы Брайниной из Казани».[1]

«Ицхаков»ка, ягъни Исхаковка икән, димәк, бу хатынның кадерле анасына Татарстан Язучылар союзы акча да бирергә тиеш була, дигән сүз. Тик шунысы бар: вак язучы булгандыр бу Брайнина. Аны да энциклопедиягә кертеп «мәшәкатьләнмәгәннәр». Күрәсез, кем әйтмешли, эте дә, бете дә, аларның туган-тумачалары да хөрмәттә Мәскәүнекеләрнең…

«Ольга Николаевна Дымникка хәбәр итегез: Роговның Мәскәү группасы Казанга чыга, аннары Чистайга. Профессор Дымник та бара».


ПРОХОДЯЩАЯ
МОСКВЫ 1 16305 22 25 1638
=КАЗАНЬ СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ=ОЧЕНЬ
ПРОШУ ОКАЗАТЬ ПОМОЩЬ ПРОПИСКИ
КАЗАНИ МОЕЙ СЕМЬИ СЕМЕЙ ПИСАТЕЛЕЙ
АРДОВА ФИННА КАТАЕВА
ЗАРАНЕЕ ТОВАРИЩЕСКИ БЛАГОДАРЮ=ВИКТОР
ГУСЕВ+

«Минем гаиләгә, Ардов, Финн, Катаев гаиләләренә Казанда пропискага кертергә ярдәм итүегезне зинһарлап сорыйм. Алдан ук иптәшләрчә рәхмәтлемен.

Виктор Гусев».

«Молния. Прошу встретить содействовать посадке пароход Чистополь моей матери едущей эшелоном писателей. Буду очень обязан.

Фадеев».

[1] Стилистика һәм орфография оригиналдагыча бирелә.

СССР язучылар башлыгы Фадеевның серле, аңлашылмый торган телеграммасы да бар. Кемгә, ни өчен җибәргәне дә, нинди йомышы барлыгы да билгеле түгел. Адрес та имза — вәссәлам…

«Балтасинский район, деревня Старая Салаус, Артель Кызыл Тукуче.

Секретарь Президиума ССП СССР, член ЦК ВКП(б) Фадеев».

Мондый телеграмманың хикмәте нәрсәдәдер — белгән юк. Ә инде «Старая Салаус» дигәне зур да, борынгы да Иске Салавычтыр…


Бланк № 78
КАЗАНЬ
ОБКОМ
ВКП /Б/ СЕКРЕТАРЮ
ОБКОМА АЛЕМАСОВУ
МОСКВЫ 69/0109 55 11 2001=
=СОГЛАСОВАНИЮ ДИРЕКТИВНЫМИ ИНСТАНЦИЯМИ
ПРОШУ ПЕРЕВЕСТИ ЧЕЛЯБИНСК УСТРОИТЬ НА
ЖИТЕЛЬСТВО ВМЕСТЕ СЕМЬЕЙ ЭСТОНСКОГО
ПИСАТЕДЯ ОСКАРА УРГАРТА ПРОЖИВАЮЩЕГО
СТАНЦИЯ ШЕМОРДАН БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОН
ДЕРЕВНЯ КУРМАЛА И ЖЕНУ ЭСТОНСКОГО ПИСАТЕЛЯ
ХИЙРА АЙМИ КАРЛОВНУ ХИЙР ПРОЖИВАЮЩУЮ

«Директив инстанцияләр белән килешү нигезендә, эстон язучысы Хийрның хатыны Айми Карловна Хийрны Балтач районындагы Курмала авылында яшәүче эстон язучысы Оскар Ургарт гаиләсе белән яшәрлек итеп урнаштырырга».

Бу телеграмманың кайдан килүе дә билгеле түгел. Серле… Ул, Татарстанның ВКП(б) обкомы секретаре Алемасовка адресланса да, архивта Язучылар союзы документлары белән бергә тупланган. Димәк, «к делу» дигән тамганы сукканнан соң, гамәлгә ашыруны Язучылар союзына йөкләгәннәр. Бу эстоннарны ни өчен Татарстанга качыруларының сәбәбе дә аңлашыла… 1940 елда, ягъни сугышка бер ел кала, Сталин гаскәрләрен Эстониягә кертеп, бу илне канга батыра һәм анда совет власте урнаштыра, тиз генә Йоганнес Варес дигән шагыйрьгә партбилет тапшыртып, аны премьер-министр итеп куйдырта. Шушы Варес тарафына карьера яратучы кызыл фикерле берничә шагыйрь да туплана. Алар коммунистик рухтагы әсәрләр язып, эстон халкының нәфрәтенә дучар була. Сугыш башлангач, бу төркем, гаиләләре-ние белән Эстониядән ашыгыч рәвештә кача. Мөгаен, Хийр белән Ургарт та шулар «әртил»еннәндер. Әдәбиятта уңышлары чамалы булганлыгы шәйләнә: аларның исемнәрен дә энциклопедиягә кертүне кирәк тапмаганнар…

Шушы юларны язганнан соң, мин кабат архивта казынып кайттым. Тырышкан табар, ташка да кадак кагар, дигәндәй, берсенең — Оскар Ургарт дигәненең Татарстан Язучылар союзына язган хатына юлыктым. Сизенүем алдамаган икән — бу икәү чыннан да әлеге Йоганнес Варес янына елышкан затлар булган! Хатын болай башлаган Ургарт:

«Курмала, 28 август, 1941.

Июль аенда мине, ягъни эстон язучысын, Эстония совет язучыларының Оештыру комитеты членын, КП(б)Э Үзәк Комитеты каршындагы әдәбият-сәнгать мәсьәләләре буенча инструкторын Эстониядән эвакуацияләделәр. Август уртасында мин Татарстанга килдем һәм гаиләм белән бергә колхозда эшлим…»

Хат ахырында төгәл адресын да күрсәткән: *«ТАССР, Шәмәрдән станциясе, Балтач районы, Курмала авылы».*

Бу хат ул кешегә азмы-күпме ихтирамымны да уятты хәтта. Эвакуацияләнгән каләм ияләре арасыннан бердәнбер Ургарт татар әдәбияты белән кызыксынуын белдергән, «эштән бушаган чакларымда бик тә татар әдәбияты һәм мәдәнияте белән танышасым килә, шуңа күрә татар әдәбияты һәм мәдәнияте турында урыс телендә язылган кулланма китапларның кайсыларын укырга икәнен күрсәтсәгез икән лә», дигән… Изге нияте аңлашылды, тик шунда ук яңа сорау туды: курмалалылар Эстония коммунистлар партиясенең Үзәк

Бу безнең язучыларыбызның сугыштан исән-имин кайткан бер өлеше генә... 1 рәт (сулдан уңга)**: Әдип Маликов, Мөнир Мазунов, Сибгат Хәким, Шәһиморат Зәйни, Мәхмүт Хөсәен, Шәрәф Мөдәррис. 2 рәт: Халикъ Садри, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Афзал Шамов, Риза Ишморат, Госман Бакир. 3 рәт: Габдрахман Әпсәләмов, Гамир Насрый, Әсгать, Абдулла Әхмәт, Вадим Земной, Хатип Госман. 4 рәт: Әмирхан Еники, Әхмәт Исхак, Әхмәт Фәйзи, Хәсән Шабанов. Матбугат йорты. 1947 ел, 27 апрель**

Комитетында (!) дәрәҗәле кеше булган Ургартның үзләрендә колхозчы булып эшләвен онытмыйча тарихларына кертә белделәр микән? Ни дисәң дә, тарихи мизгел бит бу! Горурланырга кирәк! Әмма теге Хийрның миссиясе аңлашылып бетмәде. Ул да, директив инстанцияләр белән килешенеп җибәрелгәч, гади генә Хийр булмагандыр инде. Затлы Хийр булгандыр! Бәлки, аның хакында шул Курмала тарихында кайбер мәгълүматлар сакланадыр? Алар үзбелдекләре белән генә килеп урнашмаганнардыр бит инде бу авылга? Балтач аша килгәннәрдер, һичьюгы, авыл советында теркәлгәннәрдер…

Әйе, андыйларны, әҗәлдән аралап, эшелоннар белән бик тә ышанычлы, кунакчыл милләт куенына меңәрләп ташыганнар, кадер-хөрмәттә яшәткәннәр. Ләкин шул ук дустанә милләтнең үз улларын һәм кызларын шул ук эшелоннар белән әҗәл кочагына – сугышка аткарып торганнар! Бу җәһәттән яудан исән кайткан әдипләребезнең сөйләгән хатирәләре дә онытылмый… Сугыш башланган атналарда Мәскәүдән Казанга килүче һәм Казаннан фронтка китүче ике эшелон, бер вокзалда туктальп, юлда очрашканнар. Ике эшелоннан да күпләп төшкән халык, берберен күреп, кочаклаша, хәл белешә башлаган. Баксаң, тегеләре дә, болары да әдәбият-сәнгать әһелләре икән:

– Кая барасыз?

– Эвакуациягә. Сезнең Татарстанга. Чөнки фашистлар якынлаша. Үлемнән саклану кирәк… Ә сез кая барасыз?

– Фашистларга каршы сугышка. Илне сакларга…

…Татар әдипләренең бөтенләй кырылып бетү ихтималыннан пошаманга төшкән идарә башлыклары Мәскәүгә яңа үтенеч юллыйлар:

«СССР Совет Язучылары Идарәсе Президиумының Җаваплы секретаре иптәш Фадеевка.

Күпчелек татар язучылары Ватан сугышының алгы позицияләрендә катнаша. Соңгы өч айда күпләреннән хәбәр дә юк. Бу рәхимсез сугышта та-


Ответ.секретарю Президиума Правления
Союза Советских Писателей СССР

тов. ФАДЕЕВУ

Многие татарские поэты и писатели участвуют бойцами отечественной войне на передовых позициях. От многих из них уже нет никаких известий за последние три месяца. В этой суровой войне татарская литература может потерять значительные кадры, выращенные за годы революции. Большой потерей для татарского народа была бы гибель поэтов и писателей, как т.т. Муса Джалиль, Махмуд Максуд, С. Хаким, А. Алиш, Г. Галеев. Эти писатели и поэты, за 20 лет дали немало замечательных произведений и татарский народ заслуженно гордится ими. Для сохранения наиболее талантливых писателей и поэтов, признанных всем народом, считаем необходимым позаботиться и об их безопасности. Поэтому Правление ССП ТАССР и первичная организация ВКП/б/ при Союзе просят Вас ходатайствовать перед соответствующими органами о переброске нижепоименованных татарских писателей для работы в тылу:

1. Муса Джалиль /Муса Мустафович Залилов/ гор. Щигры, Курская область почт.ящик 32, литр " С"
2. Махмуд Гисамович Максудов – Москва 14, п/я.215/01 Партбюро.
3. Сибгат Тазиевич Хакимов –
4. Абдулла Барыевич Алишев.
5. Гариф Закирович Галеев –

Ответ.секр.Правления ССП ТР: /Имамутдинов/

Секретарь первич. организ. ВКП/б/ при ССП / Г. РАЗИН/

тар әдәбиятының революция үстергән күп кадрларын югалтуы ихтимал. Әгәр Муса Җәлил, Мәхмүт Максуд, Сибгат Хәким, Абдулла Алиш, Гариф Галиевләр һәлак булса, мондый хәл татар халкы өчен аеруча зур югалту булачак. Бу язучылар һәм шагыйрьләр егерме елда искиткеч әсәрләр бирде һәм татар халкы алар белән лаеклы горурлана. Аеруча талантлы һәм танылган язучыларны, шагыйрьләрне саклап калу максатында, шушыларының булса да хәвефсезлеген кайгыртуны бик мөһим санап, ТАССРның Совет язучылары союзы һәм аның ВКП(б) башлангыч оешмасы тиешле органнардан бу татар язучыларын тылда эшләүгә күчерү (переброска) турында кайгыртуыгызны (ходатайство белдерүегезне) сорый.

Совет язучыларының Татарстан союзы идарәсенең җаваплы секретаре: Имаметдинов.

Совет язучыларының Татарстан союзы идарәсенең ВКП(б) башлангыч оешмасы секретаре: Разин».

Шәрехләү дә кирәк түгел: ошбу үтенеч тә, бүтәннәре кебек үк, игътибарсыз кала. Аның барып җитү-җитмәве дә билгесез. Чөнки Мәскәүдә җавап бирүне дә кирәк тапмаганнар… Ә нәтиҗәсен беләбез: Муса Җәлил белән Абдулла Алиш, ил өчен көрәшә торгач, әсирлеккә төшә, гитлерчылар тарафыннан үтерелә; ә инде Сибгат Хәким, Гариф Галиев һәм Мәхмүд Максуд сугышның ахырына кадәр фронтның алгы сызыгында булып, исән кайталар. Хәвефләрдән кайсыдыр «ходатай»лар түгел, Ходай үзе саклаган!

…Тагын йөзләрчә бит дәвам итәрлек тарихи материалларым булуга карамастан, туктатам мин бу язмамны… Бик кирәкле, халык белергә тиешле тема икәнен аңласам да, авызлыклап сезнең карамакка калдырам, җәмәгать. Туйдым… Йөрәккә авыр…

Ләкин тынып, бергә-бергә аз гына уйланып утырыйк, дөнья бөекләренең сугыш хакында әйткән-язган фикерләре белән танышып алыйк.

Томас Манн: *«Сугыш ул тынычлык вакытындагы проблемалардан куркакларча качу».*

Бөек Фридрих: *«Әгәр дә безнең солдатлар ни өчен сугышканыбызны аңласа, аларны сугышка алып барып булмас иде».*

Вольтер: *«Мин сугышта җиңеп чыккач баеган бер генә халыкны да белмим».*

Герберт Гувер: *«Сугышны картлар башлый, ә үлемгә яшьләр бара».*

Уршула Козел: *«Сугыш ул бетми, ял итеп кенә тора».*

Джон Кеннеди: *«Йә кешелек сугышны бетерер, йә, алай булмаса, сугыш кешелекне бетерер».*

Уолтер Мондейл: *«Өченче Бөтендөнья сугышының ветераннары булмаячак».*

Йә, уйландырамы акыл ияләренең фикерләре? Киләчәктә дә сугышырга дәртегез бармы әле?

Мин, карт язучы буларак, бары тик үземнән соң яшәячәк каләмдәшләремә бер генә васыять әйтеп калдырам: сугышта җиңүчеләр турында да, андагы батырлыклар хакында да язмагыз. Халыкны рухландырып, яңа сугышка тыгарга теләвегез, дип исәпләнер… ■

ФРОНТОВИК-ШАГЫЙРЬ

Равил Рахмани

Рамазан Байтимеровның исемен ишетеп белсәм дә, шигырьләрен укыганым юк иде әле. Шуңа да алар белән танышу минем өчен шактый кызыклы булды – мин күңелемдә авторның җанлы образын һәм ул тудырган иҗатның конкрет контурларын төсмерләргә тырыштым.

Иң әлек шул ачыкланды: Рамазан Байтимеров фронтовик-шагыйрь икән. Аның иң әйбәт шигырьләре дә, һичшиксез, шушы теманы ачыклауга багышланган. «Йөрәктәге эзләр», «Шуңа микән» шигырьләрен генә алыйк. Аларга автор сугышның бөтен фаҗигасен һәм бөтен китергән газапларын ышандырырлык итеп сурәтләүгә, үзенең сугышка булган нәфрәтен тәэсир итәрлек формада белдерүгә ирешә. Шунысы әһәмиятле, сугыш Рамазан Байтимеров өчен шулай янып, борчылып эчкерсез сөйләшү темасы гына түгел, сугыш хатирәләре аның хәтта сәнгатьле фикерләвенә дә үтеп керә. Автор иҗатында очраган шигъри образларның күбесе шул аспектта барлыкка килә:

Ике дөнья чиге — окоп...
(«Ул син идең»)

Утлы еллар ачы газапларын
Артыграк, ахры, татытты:
Яңгыр булса — пуля яуган төсле,
Канау күрсәм, карыйм: «Окопмы?»
(«Шуңа микән»)

...Һәм җыр язып, ерак-еракларга
Ак күгәрчен сыман очырам.
(«Җырым — ак күгәрчен»)

Рамазан Байтимеровның икенче игътибарга ташланган үзлеге — аның гражданлыгындадыр, мөгаен. Утны-суны кичкән бу тәҗрибәле олы буын кешесенең укучыга бүгенге тыныч тормышта да әйтер сүзе булу, әлбәттә, гаҗәп түгел. Шигырь-поэмаларны укыганда, бу рух үзен гел сиздереп тора. Әнә автор «Озын төннәр буе йокы алмый» шигырендә иҗат каршылыклары турында фикер йөртә, «Мәңге яшь, мәңге таза» шигырендә тормыш итү, яшьлек һәм картлык турында уйлана. Көрәшчеләргә, сәнгать кешеләренә, әдипләргә, гади хезмәт халкына үзенең җылы сүзен әйтергә ашыга («Багышлаулар циклы»). Аның фронт һәм хезмәт батырларына багышлап язылган башка әсәрләре дә шушы тематик төрлелек, публицистик кайнарлык белән аерыла. Кыскасы, кулъязма китапны тулаем укып чыкканнан соң бернәрсәгә ышанасың — әдипнең гражданлык позициясе нык, актив. Һәртөрле негатив якларга, гаделсезлеккә, күз буяуларга ул рәхимсез. Минемчә, аның бу сыйфаты бүгенге бик күп яшьләргә һәм яшь авторларга үрнәк итеп куярлык.

1986

Рамазан Байтимеров

ҖИҢҮ ҖЫРЫ

Ерак иде ул көн, озак көттек,
Бер кайгы да урап узмады.
Мең ярым көн буе көрәш барды,
Мең ярым көн көттек без аны.

Җиңү килде җирне нурга күмеп,
Шатлык белән күзне чылатып;
Килде ул көн горур күкрәкләрдә
Орден-медальләрне чыңлатып.

Кан түсенә кереп, көнбатышта
Һәр көн саен таңнар алланды.
Киң кырларда, мартен яннарында
Озын көннәр төнгә ялганды.

Җиңү яулый тыныч көрәшчеләр,
Гөлләр үсә Ватан кырында.
Илдән илгә, телдән телгә күчеп
Җыр яңгырый бәхет турында.

ҺӘЙКӘЛ БУЛЫП

Салып суга, утка, ялкыннарга,
Кырыс заман безне сынады.
Башлар күп күрделәр,
Ташлар эределәр,
Көннәр-төннәр дәһшәт сулады,
Безнең ныклык ләкин сынмады.

Чын батырлар гына йөрәк белән
Каплый ала ялкын утларны.
Җирнең киләчәген,
Нурын, гөлчәчәген,
Туган җирне, туган йортларны
Һәлакәттән алар коткарды.

Сулар агар һаман, һәрбер заман
Үткәннәргә карар борылып.
Бөек җиңү балкыр,
Тарихларда калкыр
Һәйкәл булып, үлмәс җыр булып,
Мәңге сүнмәс якты нур булып. ■

1943 ел

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Әхтәм Зарипов

«... 1941 елда иген уңышы мул чыкты. Абый, гаилә өлешенә тигән барлык икмәк запасын саттырып, баян алды. Районда беренче һәм бердәнбер баян була ул.

— Нигә кирәк ул сиңа, барыбер фронтка алачаклар бит, — дигәндә: — «Энем уйнар!» — дип җавап бирә торган булган, имеш.

Баянда уйнап кеше куандырмасам да, тормышымда аның роле зур булды. Алар турында «Хатирәләрем-хәзинәләрем» дигән язмамда язып та бастырдым. Хәзер ул баян турында искә төшерүем тәкъдим ителгән фоторәсемгә бәйле.

Шәҗәрә бәйрәменә туган авылыма кайткач, бергә үскән күршем Фәварисны очраттым. Ул инде лаеклы ялда, гомере буе профсоюзның җитәкче вазифаларын башкарган мәртәбәле шәхес. Туган-үскән йорт урыннарыбызны күрергә дип баргач, бәрәңге бакчаларыбызның ташландык хәлдә булуы гаҗәпләндерде. Ә без үскәндә әнкәйләр җирне көрәк белән генә казып утыртсалар да, үз мәйданнарыннан бер карыш та күршегә бирмәсләр иде. «Ызанны бозгансыз, безнең якка кергәнсез», — дип, һәр яз саен җир өчен кычкырышалар иде. Кыскасы, әнкәйләр берберсенә каршы булса, без, малайлар өчен җирнең кечерәк булуы әйбәт — утыйсы, кәтмәнлисе, күмәсе бар бит!

Ничәнче ел иде микән — мөгаен, 1943 ел булгандыр — күршемнең әтисе мәрхүм, минем абый да яу кырында ятып калган — авылга «кәртечке төшерүче» килә. Безнең әнкәй үтә дини — «кәртечкегә төшү гөнаһ», — дигәнгә ышанган кеше.

Фотографны өенә күршебез Нәсимә җиңги чакыра, кайчандыр улы Фәварисны суга батудан коткарган мәрхүм Әүдакның энесен дә, ягъни мине, баяны белән кереп ала.

Күрәсең, баянлы булгач, дәрәҗәлерәк чыгар, дип тә уйлаганнардыр.

Кәртечкегә төшелә дә, шуның белән онытыла да. Фотограф өч рәсемгә 30 күкәй сорый. Безнең әнкәй 10 күкәй бирми генә түгел, рөхсәтсез төшергән өчен тавыш чыгара, «гөнаһлы иттегез», дип каргый.

Күршебез Нәсимә җиңги, чарасызлыктан, фотодагы минем йөзне тырнап җуйдырырга мәҗбүр була. Озак еллар шул фотоның рамда торганын хәтерлим.

— Нигә шулай битсез мин? — дигәч, күрше җиңги: — «Анаңнан сора!» — ди иде.

...Күршем Фәварис, ниһаять, өч фотодан берсенең кайсыдыр туганнарында саклануын белеп алып, шуны табып, әле бер ай элек кенә миңа сала. Күрәсез — фотографы да һөнәренә хөрмәтсез кеше булганга охшаган... Истәлек өчен ярый инде, дип җитешсезлекләренә күз йомасы гына кала».

Базы елгасы буенда. Уңда – Зыя Мансур. 1955 ел

***

«Еракта калган 1955 елның җәендә күршедәге Җитемәк авылына (Башкортстанның Дүртөйле районы) язучы-шагыйрь Зыя Мансур кайтып, дәваланып ята икән, дигән хәбәр ишетелде. Сугыш вакытында аның хатыны безнең авыл клубында «культурник» булып эшләгән иде. 10 классны медальгә бетерүче исеменә лаек булсам да, җисеме башка кешегә бирелү сәбәпле, укырга керә алмау куркынычы тугач, киңәшчеләрем Зыя Мансурны күреп сөйләшергә киңәш иттеләр, Казан институтларында аның сүзе үтми калмас, диделәр.

Эзләп таптым. Хәлне аңлаттым. Баянда уйнавымны, шигырь язатуымны, сәнгатькяр булырга теләгем барлыгын белдердем.

— Берәр шигыреңне яттан беләсеңме?

— «Мокамай»дан башка шигырьне яттан белмим.

— Күптән язасыңмы?

— Мин язмыйм, сөйлим генә ич...

— Шагыйрь булу өчен үзең язу кирәк бит, энем.

— Сугышта үлгән абыем артист булган минем. Әгәр артист булсам?

— Ничә яшендә үлгән абыең?

— 18дә...

— Шуңа синең дә артист буласың киләме?

— Ярап торыр иде әле... укырга кереп булса...

— Белмим шул, укып кына артист чыгар микән соң?! Мәгәр укып кына шагыйрь булып булмавын беләм. Ярый, кем булырга теләгәнеңне ачык белү — әйбәт. Быел Казан театр училищесына набор бары-югыннан бихәбәр. Анда кайчандыр партком секретаре булып Нур Гайсин дигән шагыйрь эшләгән иде. Мин сиңа аның координатларын бирермен, бәйләнешкә кереп сорарсың... — Шулай диде миңа Зыя абый.

Кердем, сорадым, белдем: «Набор юк, көтелми дә», — диделәр.

Биш ел Мәскәүдә укып кайткач, Г.Камал театрында эшләгәндә, очраклы рәвештә генә Зыя Мансурның Комлев (*хәзерге — Мөштәри*) урамында, безгә каршы йортта яшәвен белдем.

Радиопостановка өчен А.Довженконың бер хикәясен тәрҗемә иттерү сылтавы белән күрешеп чыгарга керсәм, ул бик каты авырып түшәктә ята иде.

Шулай да, китапны калдырырга кушты, танышып чыккач та хәбәр итәргә булды.

Тәрҗемә ителгән хикәяне алырга кергәндә, Зыя абзый түшәктә түгел, язу машинкасын текелдәтеп утыра иде инде.

— Хәлләнеп киттем бит әле, Довженко булышты, ничек моңа кадәр шундый олы талантны белми яшәгәнмендер, сиңа зур рәхмәт, яңа бер дөнья ачтым, — дигәне хәтердә.

Бу 1964 елның ахыргы, 1965 елның әүвәлге көннәрендә булгандыр, дип уйлыйм. Мин аңа үзем төшереп эшләгән шушы тонык фотоны биргәч, ул аңа карап, озак кына уйланып утырды да:

— Син... шул егетмени? — диде.

Мин: «Шулай булып чыга», — дидем.

Тавыш-тынсыз һәм яшьсез генә елап алгач, ул: «Мин бу фотодагы балыкчы түгел шул инде, хәзер үзем коры ярга чыгарып ташланган балык хәлендә», — дип әйткәч, озаклап йөткерүе, учлап дару эчкәне хәтердә уелып калган...

Радиопостановкамны тыңлый алгандырмы, юкмы — сорый алмадым...

Бөек Җиңүнең 20 еллыгын да бәйрәм итә алмады фронтовик шагыйрь Зыя Мансур...

Урыны җәннәттә булсын.

***

«Мәскәүдә артистлыкка укырга кергәч, таныш-белешләрне, якташларны эзли башладым.

Юксынудан яисә сагышны басар өчен генә түгел, әҗәткә акча алып торыр өчен дә ышанычлы таныш кешеләр кирәк иде.

Беренче курстан соң микән, икенче курстан соңмы — безнең татар студиясе, якташлар белән очрашуга махсус концерт әзерләп, төрле институтларга хәбәр салды: «Килегез, күрегез, белегез!»

...Очрашуга килүче милләттәш студентлар арасында Габделхәй Сабитов белән Рәшит Гәрәйне очрату минем өчен аеруча кыйммәтле иде. Шуннан соң без бер-беребезгә кунакка йөрешә башладык.

М.Горький исемендәге язучылар институты студентлары Переделкинодагы мәшһүр язучыларның дачаларында яшиләр иде.

Рәшит белән Габделхәй мине, Минзәләдән килгәнлектән, үзләре оештырган якташлар очрашуына чакырды. «Переделкино»дан Чуковский дачасына, Рафаэль Сафин дигән башкорт шагыйренең китабын «юарга» 2-3 кыз ияртеп килсәң дә була», — диделәр алар, бераз серлерәк итеп.

Мин бу чакыруны башкорт студиясе кызларына да әйттем. Бер тулай торакта яшибез бит! Бер көтү булып бардык.

Рафаэль Сафин сыйны мулдан әзерләгән иде. Мәҗлес бик күңелле узып, шундагы кайбер танышлыклар мәхәббәткә әверелде, гаилә дуслыгына да күчте. Рәсемгә килгәндә... Күмәк төшкәнендә алгы рәттә сулдан беренче утыручы студент Рәис Низамов — соңрак танылган башкорт язучысы, уңнан икенче — мәшһүр Рафаэль Сафин, Өфе (Уфа) каласында безнең театр спектакльләренә килгәч, шушы очрашуларны гел сагынып искә ала иде.

Икенче курсны тәмамлагач, өйләнеп, Җәмиләмне Мәскәүгә алып килдем. Ул фатирда торып эшләр, ә мин укуымны дәвам итәрмен, дип планлаштырган идек.

Фатир табып булмады. Ярдәм эзләп Габделхәй белән Рәшиткә киттем.

Уңнан сулга (аягүрә)**: эшләпә тотканы – мин, (...), Рәшит Гәрәй, Габделхәй Сабитов... 1956 ел**

Бу вакытта алар Добролюбов урамындагы студентлар тулай торагына күчкән иде. Икесе бер бүлмәдә яши.

Хәлне сөйләп аңлаткач, Рәшит шундый тәкъдим ясады: «Җәмиләң фатир табып булмады, дип кайтып китәргә ашыкмасын, бергәләп эзләрбез. Ә хәзергә безнең шушы бүлмәдә яшәп торыгыз. Без, Габделхәй белән алмашлап, күрше бүлмәдә кунгаларбыз. Икегез бер караватка сыярсыз бит?!»

Без, бер ай чамасы Рәшит-Габделхәй бүлмәсендә торып, фатир эзләсәк тә, таба алмадык...

Күпмедер вакыттан соң бу ике мәрхәмәт иясен бәхилләтергә дип барсам — Габделхәй, институтны ташлап, Казанга кайтып киткән, Рәшитнең үз мәшәкатьләре баштан ашкан чак иде. Комсомол секретаре буларак, аңа Евгений Евтушенконы комсомолдан чыгару «эшен» йөкләгәннәр икән.

— Юк өчен борчылып йөрмә. Артист булып эшли башлагач, премьераларыңа чакырырсың! Бәхилләтүең шул булыр!» — диде ул миңа.

Шунысы үкенечле: артист чакта да, режиссёр булгач та бәхилләтү җае чыкмады. Ә бит чыгарырга була иде. Сибгат Хәкимгә багышлап сценарий язган иде Рәшит — төшерелмәде...

Бер елны Минзәлә театрына спектакль куярга баргач, шагыйрьне очратам.

— Син нишләп монда? — дим.

— Мин Минзәләдә канат чыгарып очтым бит, инде менә оя корырга дип кайттым! — ди.

Вакытлыча район газетасы редакциясендә эшли икән. Башка очрата алмадым. Корган оясы исәнме икән?

...Габделхәй дә ашыгып китте бу дөньядан.

Бурычыңны үз вакытында түләү-бәхилләтү кирәк шул. Югыйсә, ул, төзәлмәс яра кебек, үзен гел дә хәтерләтеп, күңелне тырнап тора. Кичер мине, шагыйрь! «Сибгат» дигән сценариеңны фильмга әверелдерү уе белән яшим...

Шул уйларым вә ниятләрем сиңа дога булып ирешсен.

Ә бу фотолар күреп белмәгәннәргә сезне хәтерләтсен. ■

Редакциядән: *Күренекле режиссёр, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Бөтенсоюз телевизион фильмнар фестивале лауреаты Әхтәм Зариповка 15 июльдә 80 яшь тула. Журналыбызның актив авторын шушы күркәм гомер бәйрәме белән тәбрик итәбез!*

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Бер Ул – аның шулдыр иң төп сыйфаты,
Күңелдән ерак тот син кыяфәтен.

Олуглык Аңар ул, бөеклек Аңар,
Кодрәт-ихтыярда Аңар юк сыңар.

Яралтты Ул сансыз мәхлүкъ, колларын.
Барчасына насыйп өлеш чыгарды.

Зәңгәр күк яралтты, күтәрде биек,
Ай-көн, йолдыз белән бизәлде бу күк.

Түбәне – җара җир һәм зәңгәр сулар,
Түбәсе – эссе җил, ялкынлы утлар.

Теләде теләген Үз теләгенчә,
Аңар катылмады һичбер ярдәмче.

Теләсә, ярлыкар гыйбадәтсезне,
Теләсә, арзанлар гыйбадәтеңне.

Теләгән нәрсәсе булыр «бул!» дисә,
Йөретер казасын Үз теләгенчә.

Исәпсез мең сәлам бөек сәүчегә –
Ул изге кулавыз булачак безгә.

Илбиккә догада булып хат яздым,
Сәламемне әйтер өлгер туганым.

Рәхим итеп, илбик язган үз сүзен,
Укыдым язганын – яктырды күзем.

Күп иге аңлатма, үгет-нәсихәт,
Һәрбер сүзе миңа нинди мәрхәмәт!

Янә вәгъдә кылган сансыз игелек:
Шәрәфле урын вә нигъмәт, игелек.

Мондый хөрмәт өчен кайбер кешеләр
Бар дөньяны гизеп, азап чиктеләр.

Бер хезмәтсез генә бу дәрәҗәгә
Керсәм, булмагае сәер, гаҗәбә[1].

Вә ләкин бүтән бер хөртлек бар монда:
Мин үлгәч яманат калыр артымда.

Беренчедән, чөнки, юк зур хезмәтем,
Ил искә алырлык берни кылмадым.

Бу бапта үрнәк юк – ниләр кыласы,
Күрсәтмәсез нишли инде хезмәтче.

Теләсә, ярлыкар гыйбадәтсезне,
Теләсә, арзанлар гыйбадәтеңне.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Гаҗәбә – «гаҗәп хәл».

**Табын көн-төн бары Аллага гына,
Ачык тот капкаңны аңарга гына.**

Икенчедән, дөнья усал дип белеп,
Тәүдәрәк йөрдем мин усаллык кылып.

Һәм хәзер Тәңрегә сыгынам көн-төн,
«Динем-иманымны кылсын, –
дип, – бөтен».

Тамагыма җийем, өстемә кием
Өчен тикшеренми яраткан Иям.

Сиңа дөньялыкны кызганмый биргәч,
И, батыр, миңа ник бирмәсен икән?

Тудырды, үстерде бу көнгә тикле,
Янә шулай итәр, и, дөнья бийе!

Ни бар, изге-яман, бар-юк сыйфатым
Ходайдан киләдер димен, юмартым.

Ходай капусында кыламын табуг:
Барча халык үтә торган зур капу.

Инде синең генә капкаңа барып,
Ни теләрмен синнән, вакыт уздырып.

Икебез Тәңренең тиң колларыбыз,
Ходай каршында тиң бар кылганыбыз.

Бәс, ник табынырга тиеш мин сиңа,
Табугым дисәң, мин инде хурсынам.

Ни шәп әйткән ошбу хакта бер галим,
Ишет менә шуны, и, изге җанлым:

«Эш һәм аш биргәнгә табынма бер дә:
Нигә табынсын, ди, бәндәгә бәндә.

Табын көн-төн бары Аллага гына,
Ачык тот капкаңны аңарга гына.

И, илбик, дүрт хаҗәт куям алдыңа,
Үтәсәң шуларны табыныйм сиңа:

«Беренчесе – булыйм мин кимчелексез,
Яшьлек мәңге булсын – бу икенчесе.

**Аш-су җитә миңа, шулай ук кием,
Тагы кирәк булса, Аллам бирер, дим.**

Өченчесе – гомер узсын бер шиксез,
Дүртенчесе – байлык бир миңа чиксез».

Шул дүртне булдырсаң сиңа табынам,
Җанымны багышлап, бер бәндәң булам.

Шуларны бирәлсәң иде, илбигем,
Үземне кол кылып мин бирер идем.

Шуларны бирергә булмаса чараң,
Ни артыклыгың бар, йә, әйтеп кара!

Аш-су җитә миңа, шулай ук кием,
Тагы кирәк булса, Аллам бирер, дим.

Ардаклык-арзанлык килә Алладан,
Үлем вә тереклек шулай ук Аннан.

Сердәш кирәк түгел моңайганымда:
Алла сердәш булып яши аңымда.

Моны белер һәрбер белекле-ушлы,
Бүтәнчә булалмас ич, и, илбашы.

Миңа Ходай биргән чаклы тәрбия,
Бирмәс ханнар, бийләр. Бирмәссең син дә.

Кем белә – калырсың минем кулыма...
Юк инде, чын хуҗам – Тәңре, Ул гына.

Син ризык бирмәссең, үзең туймыйча,
Ул исә туйдыра бер шарт куймыйча.

Сердәш кирәк түгел моңайганымда:
Алла сердәш булып яши аңымда.

Афәттән ялчы вә кол саклый алмас.
Мине көчлекчедән яклый бер Аллам,

Кичермәссең ич син явызлыгымны,
Ә Тәңре кичерә бар языгымны.

Ни ди, ишет, әнә гөнаһлы коллар
Күңел серен ачып тәүбә кылырлар:

«Миһербан, вафалы, чын бер Ходаем,
Бары синдә генәдер юнь вә ваем.

Теләген үтәрсең моңлы җанымның:
Терәге син барча ятим-ялгызның.

Сагышка дәва син һәм им һәр чиргә,
Тайганда-таяныч, ирексәм-ирмәк.

Куаныч, юаныч, сөенечләрем
Синең кәефеңнән тора, и, бәгем.

Күп эшләдем инде гөнаһ-языклар.
Рәхим итсәң, ләкин, алар аз чыгар.

Канәгатьмен, берни кирәкми артык,
Бу дөнья асылда үләксә, калдык.

Гөнаһны кичерсәң зыян юк сиңа
Кыйнама мине син, файда юк кыйнап».

И, илбик, бу дөнья, фани гомер бер
Алкынып алыр да шил булыр[2], кибер.

Нәрсәгә инанып озак уйларга?
Нәрсәгә юанып уен уйнарга?

Зая үткән икән кичкән көннәрең,
Заяга үткәрмик килер төннәрне.

Кара да туктаусыз аккан агымга,
Хәзерлән кичәргә теге ягына».

Мин үзем хәзер шул кичерештәмен:
Бийгә ни сүз илә ярдәм итәрмен.

Әйт илбиккә, ошбу хәлемдә калып,
Яшим әле аңар догачы булып.

Әгәр миннән ярдәм теләсә илбик,
Акыл-гыйлем бирсәм, файдалырак бит.

Мин инде бу калган тереклегемне
Хак ризалыгына багышлыйм, димен.

Канәгатьмен, берни кирәкми артык,
Бу дөнья асылда үләксә, калдык.

Ни шәп әйткән Хакка табынган бер ир
(Гыйбадәттә коты-бәхте тулган ир):

«Җиһанда бар ризык ашар-җийәрлек,
Кием дә табыла өскә киярлек,

Тамакка табылыр тереклегемдә –
Иям-Тәңрем бирер насыйп көнемдә».

Әгәр миннән ярдәм теләсә илбик,
Акыл-гыйлем бирсәм, файдалырак бит.

Әгәр ил эшенә ул ярар, дисә,
Ярарлык җирем юк, кистереп әйтәм.

[2] 1) Алкыну – «ташу, күтәрелү, көчәеп агу»: Шил – «елганың иң сай чагы» (бу сүзләр татар сөйләшләрендә дә бар).

Һәм әле кардәшем урнында кала,
Кирәк мең ир эшен ул эшли ала.

Әгәр мине изге дип исәпләсәң,
Үзең бер изге бул, әгәр теләсәң...

Дөньяда даны киң җәелгән ирләр
Бийгә килеп, теләп хезмәт итәрләр.

Соң, миннән илбиккә нindиен файда?
Файдасыз эшләрнең кызыгы кайда?

Хәзер сиңа миннән гозерем шулдыр:
Рәнҗемичә генә куй мине, калдыр.

Кардәшенә тагын сөйләде күп сүз:
«Шуларны, – дип, – телдән әйтеп
бирерсез».

Сүзен язып, төреп, ясады бөти,
Кардәшенә болай дип тәкъдим итте:

Әйтте ки: – Яздым мин теләк-сүземне,
Телдән сөйләгәнне белдең үзең дә.

Барып үтен, сөйлә хөкемдарга син:
Куйсын үз хәлемә һәм борчылмасын.

Ялавач сүз илтер, җавап китерер –
Аны мөмкин кадәр тизрәк җиткерер.

Ишет, ничек әйтә Өч урда[3] ханы
(Бөтен илгә мәгълүм иткән ул моны):

– Илчегә зыян юк, борчак сипмәсә,
Тапшырылган сүзне төгәл сөйләсә.

Ул ханның бер сүзе тагын яхшырак:
«Илче торсын хәвеф-хәтәрдән ерак»

«Илчегә үлем юк», диләр бит шуңа,
Тик сүзне дөп-дөрес тапшырсын гына.

Ялавачлар алар арадашчылар:
Арадашчыга соң нинди гаеп бар?

Ялавач тапшырган сүзне сөйләгәч,
Мактап алыр ханны – шул монда киңәш.

[3] Өч урда – билгесез төрки дәүләт.

Теләк тә бит, тели белмәсәң, имгәк,
Сорау да чүп, сорый белмәсәң юньләп.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ СҮЗЛӘРЕ

Җаваплап Үгделмеш әйтте шул сүзен:
–Ишеттем барсын да, ни әйтсәң үзең.

Хатың хатка каршы язылган, белдем,
Миңа хатны тапшыр – мин китим инде.

Вә ләкин, и, кардәш, шуны сизенәм:
Илбик сине тыныч куймас тиз генә.

Кабат мине сиңа җибәрер, шуннан
Чакыртыр ул сине, и, тәкъва туган.

Җавапта Уйгырмыш әйтте: – Энекәш,
Алай сөйләп яра салма күңелгә.

Мин үзем бармыймын ул якка бер дә,
Син дә азап чигеп, тәк килеп йөрмә.

Теләк тә бит, тели белмәсәң, имгәк,
Сорау да чүп, сорый белмәсәң юньләп.

Ишет, әнә тирән, зур гыйлемлеләр,
Яхшы-яманны күп сынап, ни диләр:

«Сорап, бирмәсәләр, кат-кат тыкышма,
Табылмастайны да эзләп тырышма.

Азапланма җәяү йөреп буш җиргә,
«Рәхим ит», димәсә хуҗа, син кермә».

Һәм әйтте Уйгырмыш: – Син инде тыңла,
Егет бул һәм кабат киләсе булма.

Үгделмеш аякка басты һәм әйтте:
– Сүзем бетте, китим, эшлим кирәкне.

Тагын кабатлады барча сүзләрен
Ничек аңлаганын һәм дә белгәнен.

Азапланма җәяү йөреп буш җиргә,
«Рәхим ит», димәсә хуҗа, син кермә».

**Шәрыкне ялкынлы яктылык баскан,
Көн-килен туенда ак йөзен ачкан.**

Шуннан атка менде, «сау бул» — дип әйтеп.
Юл йөреп, өенә кич җитте кайтып.

Кояш байды – йөзен җиргә яшерде.
Күк йөзе каралды нәкъ кеш шикелле[4].

Җир өсте күмергә, гүя, күмелде.
Уяулар йоклады – күзләр йомылды.

Үгделмеш түшәген сорады, ятты.
Йокысын йоклагач, күтәрсә башны:

Шәрыкне ялкынлы яктылык баскан,
Көн-килен туенда ак йөзен ачкан.
Күтәрелгән сыман мәрҗәнле калкан,
Җир өстенә Тәңре ак энҗе япкан.

Торып, өйдән чыгып, сарайга килде,
Рөхсәт сорап, илбик янына керде.

Сорады Уйгырмыш хәлен илбийе:
– Тиз генә аңлатып, сөйләп бир, – диде, –

Нинди сүзләр йөрде, эшем буламы?
Үзең ниләр белдең, һәм ул киләме?

Үгделмеш хат бирде, калкып тезеннән,
Һәм Илбик кичерде хатны күзеннән.

Кызарды шунда ул, көлемсерәде,
Күзләрен гарешкә шуннан терәде.

Һәм әйтте: – Кардәшең бик эре язган,
Ләкин ялганлыгы юк – туры язган.

Туры сүзе бераз кискен икәндер.
Мин ефәк җибәрдем – алдым тикәнне.

**Күтәрелгән сыман мәрҗәнле калкан,
Җир өстенә Тәңре ак энҗе япкан.**

Хәзер телдән сөйлә бар әйткәнен син,
Яшермәстән җөмлә ишеткәнеңне.

Вәзир бәян кылды барсын төп-төгәл,
Нинди сүзләр булды, ничек хәл-әхвәл.

Аңлатты: – Сүз йөрде һәртөрле бабтан,
Ул әйтте, мин әйттем бик әдәп саклап.

Минем сүзгә анык җавап сөйләде,
Кабатлап әйткәнне бер дә сөймәде.

Ни генә әйтсәм дә, монда килмәде,
Катгый таләп иттем – күңел бирмәде,

Уйгырмыш сүзләрен ишетте илбик.
Аларда ул күрде зиһен, аң, белек.

Теләк тагын үсте, ярсыды күңел,
Күңел шулай кунса, кешегә моң ул.

**Егетләр асылы әйтә шундый сүз:
Күңеле булмаса, кеше ирексез.**

Егетләр асылы әйтә шундый сүз:
Күңеле булмаса, кеше ирексез.

Бий күңеле бийчә: һәркем аңар кол.
Бийе кая китсә, колга шул ук юл.

Теләккә ирешми күңеле булмас,
Күңеле булмыйча йөрәге тынмас.

Янә илбик әйтте: – Әйе, Үгделмеш,
Кардәшең тәмаман чын кеше, имеш.

Ишетмәсәм иде аның сүзләрен,
Ни кылыгы, холкы, белеме барын,

Ишеттем – күңлемә кереп утырды,
Хәзер аның белән очраштыр, тырыш.

Дәвамы бар ■

[4] Кеш шикелле кара – борынгы төрки поэзиядә киң таралган чагыштыру. Кеш (җәнлек) тиресе элек-электән бик кыйммәтле һәм билгеле булган.

ТУКАЙГА ЯКЫНАЮ

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ

23 апрель көнне Габдулла Тукай әдәби музее һәм «Безнең мирас» журналы редакциясе хезмәткәрләре Тукайны халыкка якынайту мәсьәләләренә багышланган «түгәрәк өстәл» оештырды. Чарада ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ директоры, профессор Ким Миңнуллин, Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИның тукайчылар төркеме җитәкчесе, профессор Зөфәр Рәмиев, КФУ профессоры Хатыйп Миңнегулов, ТР хөкүмәтенең Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлекчәсе мөдире Галимҗан Гыйльманов, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, Татарстан китап нәшриятының «Мирас һәм сәнгать» редакциясе мөдире Венера Камалиева, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм музейның фәнни хезмәткәре Лена Тябина катнашты. Габдулла Тукай әдәби музеенда узган «түгәрәк өстәл»не музейның директоры Гүзәл Төхфәтова алып барды.

Гүзәл ТӨХФӘТОВА:

— Габдулла Тукай әдәби музеенда ел саен 25 меңнән артык кеше була. 4 фәнни хезмәткәр эшли, экскурсияләр барысы да шулар өстендә. Тукайның үзе һәм иҗаты, даирәсе турында төрле әдәби кичәләр уздырабыз. Күптән түгел генә Муса Бигиевка һәм Кәбир Бәкергә багышланган кичәләр оештырдык. Көзен исә, шәхесләребез сериясен дәвам итеп, Атилла Расих, Мөхәммәт Мәһдиевкә багышланган кичәләр узачак. Г.Тукай әдәби музеена балаларны экскурсияләр белән генә түгел, ә төрле музей бәйрәмнәре дә оештырып җәлеп итәбез. Шүрәле, Су анасы, Мияубикә һәм башка Тукай геройлары булып киенеп тә чыгышлар ясыйбыз. Төрле уеннар аша экспонатларның тарихын сөйлибез, Тукай иҗатын тагын да киңрәк ачарга тырышабыз. Төрле проектларыбыз бар. Шуларның берсе: «Исемдә калганнар»га — 105». Бу проект кысаларында Г.Тукайның әлеге әсәре татар, рус, инглиз, төрек телләрендә яңгырады. Төрек телендә — Надир Дәүләт, инглизчә Җәүдәт Сөләйман укыды.

Музейга килүче туристларның саны елдан-ел арта. Иң зур проблема да туристларны каршы алу белән бәйле. Саргайган түшәмебез аларның күңелен тетрәтә. Экскурсоводлар сөйләгәндә туристлар Тукайның авыр балачагын белеп елап кына калмыйлар, ә бинаны да күреп сыкраналар: «Татарның бөек шагыйренә кагылышлы ядкярләр ник шундый бинада, нигә аңа ремонт ясалмый?» — диләр. Әле бу — проблеманың күзгә күренгән өлеше генә...

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ:

— Чыннан да, Тукай музее шагыйрьнең тормышын, эшчәнлеген өйрәнү белән генә түгел, ә бәлки аның даирәсен гавамга җиткерү юнәлешендә дә эшли. Мин моңа аеруча басым ясап әйтер идем. Музейлар оештырырга, китаплар чыгарырга, юбилейлар уздырырга безнең мөмкинлегебез аз. Хәзер саф әдәбият кафедрасы да берәү генә калды. Бу Татарстанга гына түгел, ә бөтен Россиягә! ТӘһСИда берничә кеше татар әдәбиятын өйрәнә. Тукайны өйрәнергә кирәк, әмма башкаларны да онытмасак иде. Исхакый, Җәлил, Ибраһимов, Гафури, Дәрдемәнд һәм башкалар бар... Музей чаралар уздырган вакытта Тукай даирәсе, Тукайга мөнәсәбәтле булган башка шәхесләрне дә онытмыйча, аларны өйрәнүне, халыкка пропагандалауны дәвам итәргә тиеш.

Икенчедән, биредә Мөнип Таҗи улы эшләде. Ул музейда эшләве рәхәт, иң кыены халык җыю, дия торган иде. Әллә нинди яхшы чаралар оештырырга мөмкин, әмма халык килми икән, бу кызык түгел. Монда мәктәпләр, мәгариф оешмалары белән уртак тел табып эшләргә кирәк, дип саныйм.

XXI гасырда без нәрсәләр эшли алабыз? Дөрес, Тукайның үз заманыннан алып шактый зур эшләр башкарылган. Тукайның иҗаты шундый күренеш: ул әле бер ягы белән ялтырап китә, әле икенче ягы белән балкый. Чор барган саен аның кайсыдыр ягы актуальләшә, мөһимләшә бара. Шуңа күрә, Тукайны һич кенә дә өйрәнелеп бетте, дип әйтеп булмый һәм ул заман белән бергә алга барырга тиеш.

Мин совет чорын сүгүгә бер дә риза түгелмен. Ул чорда зур эшләр эшләнгән. Ә хәзер мөмкинлек була торып та без нәрсә эшли алабыз? Яңа фактларны, мәгълүматларны эзләү — хәзер дә мөһим бурычларның берсе.

Гүзәл ТӨХФӘТОВА. Без музейда яңа экспонатлар туплыйбыз. Билгеле ки, Тукай төрле җирдә булган, сәяхәт иткән. Ул яшәгән төбәктә булып, экспедицияләр ясау, аннан экспонатлар кайтарту мөмкинме? Фәнни оешмалар предметларны, шәхси әйберләрне тупламыйлар. Безгә бит теге яки бу шәхеснең тәлинкәсе дә, кашыгы да, киеме дә кирәк...

Ким МИҢНУЛЛИН:

— Моны өлешчә хәл итүнең бер юлы: Фәннәр Академиясендә командировкалар ел саен булып тора. Телләрне үстерү һәм татар халкының этник асылын саклау турындагы программаларда фәнни экспедицияләргә махсус финанс каралган. Без башка оешмалардан да фәнни хезмәткәрләрне ала алабыз. Монда тема, эчтәлек ягын аныкларга кирәк. Әйтик, сез безнең төркем белән чыгып үзегезгә нәрсә ала аласыз? Сезгә экспедициянең маршруты, эш юнәлеше кызыкмы?!

Разил ВӘЛИЕВ:

— Чыннан да, телләр программасы буенча археографик экспедицияләр оештыру каралган. Сезгә дә фәнни оешмаларга, китапханәләргә: «Әйдәгез, киләсе елга безне дә ияртеп Җаекка бармыйсызмы?» — дип теләктәшлек белдерсәгез була. Җаекта да безнең борынгы китапларыбыз, кулъязмаларыбыз бар. Белүемчә, археографларның бик күптәннән инде Җаек якларында булганнары юк...

Иң зур проблема да туристларны каршы алу белән бәйле. Саргайган түшәмебез аларның күңелен тетрәтә. Экскурсоводлар сөйләгәндә туристлар Тукайның авыр балачагын белеп елап кына калмыйлар, ә бинаны да күреп сыкраналар: «Татарның бөек шагыйренә кагылышлы ядкярләр ник шундый бинада, нигә аңа ремонт ясалмый?» — диләр.

ТР Милли китапханәсе хезмәткәрләре Төркия һәм АКШка фәнни экспедицияләр оештырды. АКШтан 30дан артык кулъязма һәм сирәк китаплар алып кайттылар. Басма китапларның күбесе Казанда басылган. XX гасыр башында безнең мөһаҗирләр чит илләргә букча тутырып китап алып киткән. Россиядән Кытайга күченгәннәре, чуалышлар башлангач, китапларын төяп Япониягә киткән, аннан кысрыклангач, Көньяк Кореяга күченгәннәр. Көньяк Кореяда хәлләр авырая башлагач, Канадага киткәннәр, әмма китапны калдырмаганнар. Ә бүген аларның нәселе АКШта яши. Менә бу китапларның тарихы гына да бик кызыклы. Ә анда исә Тукай китаплары да бар! Менә китап язмышы нинди гыйбрәтле! Казанда басылган татар китабы Җир шарын әйләнеп чыгып, йөз елдан соң безгә кайтты!

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. 90 нчы елларда Хельсинки университетының Шәрык бүлегендә булдым. Анда Казанда һәм Петербургта революциягә кадәр басылган татар китапларын күрдем. Бу китапларның бер өлеше Россиядә сакланмаган. Харбин, Токио

Иң суык, иң туңган вакытында аз гына акчасы булса, 2-3 көн генә җылынып чыгам, дип, Тукай «Амур»га кергән. Аның тәнен җылыткан «Амур» исән бит әле безнең! Әмма ул яңгыр, җил астында тора-тора, «Болгар»ның язмышына дучар булмагае.

нәшриятларында чыккан китапларның да күбесе анда бар.

Казакъстанның Кызылъяр шәһәрендә «Маяк» газетасы чыккан. XIX йөздән үк татарның бик зур мәдәни үзәге булган әлеге шәһәрдә Гаяз Исхакый, Габдулла Кариевлар эзе саклана. Шулай ук заманында татар мохите көчле булган Семи шәһәре дә бар. Шуларга фәнни экспедицияләр оештырып булмыймы? Андагы татар мирасы тәмам юкка чыгып беткәнче, нәрсә дә булса эшләп каласы иде бит!

Разил ВӘЛИЕВ. Әбрар Кәримуллин исән вакытта без байтак шәһәрләрдә татар китабын эзләп йөрдек. Киевның китапханәләрендә булдык. Анда искиткеч күп борынгы китапларыбыз бар. Хельсинки китапханәсендә дә татар китаплары байтак. Америка Конгресс китапханәсенең дә төрки китаплар бүлегендә татар китаплары искиткеч күп. Әгәр дә сез дөньяның мәшһүр китапханәләренә: «Тукайның нинди китаплары бар?» — дигән эчтәлектә хат язып, мәгълүмат алсагыз, бу сезнең өчен бик кызыклы булыр иде.

Зөфәр РӘМИЕВ:

— Фатих Сәйфи-Казанлы: «Китап палатасында Тукайның ике төпләм шигырьләре бар», — дип яза. Мин шуны эзләргә керештем, таба алмадым. Архивчылар: «1960 елга кадәрге чыганаклар тартмаларда ята, аны беркем дә карамаган, эзләмәгән, нәрсә бар икәнлеге билгесез», — ди. Югыйсә Ф.Сәйфи-Казанлы заманында шунда барып өйрәнгән, ә без барып күрә дә алмыйбыз.

Ләбиб ЛЕРОН:

— Киләчәктә «Тукай үзәге» оештырып булмасмы икән? Бер бүлмәдә Тукай, икенчесендә аның чордашларының иҗаты, өченчесендә бүгенге заман әдипләре тәкъдим ителсә, яхшы булыр иде...

Разил ВӘЛИЕВ. Без Туфан Миңнуллин исән вакытта Президентыбызга Тукай институты булырга тиеш, дип кергән идек. Бу Туфан абыйның идеясе иде. Пушкин, Абай институтлары бар. Ни өчен әле Тукай институты булмаска тиеш?! Рөстәм Нургали улы институт кирәк, мин идеяне яклыйм, әмма кечкенәдән башлыйк, ТӘһСИ каршында бер төркем төзик, диде. Шушы төркем, бәлки, киләчәктә зураеп, Тукай институтына әверелер.

Гүзәл ТӨХФӘТОВА. Ул — институт, фәнни үзәк. Ә «Тукай үзәге» теләгән һәркем өчен дә ачык булсын иде. Анда Тукай исеме кергән барлык китаплар, мәкаләләр тупланырга, алар белән теләгән һәр кеше танышу өчен барлык шартлар да тудырылган булырга тиеш. Сирәк китапларның, документларның, фотоларның электрон вариантыннан файдалану мөмкинлеге булу да мәҗбүри. Бу үзәк музей белән бергәлектә эш алып барса, уңышлы булыр иде.

Разил ВӘЛИЕВ. Без яңартып корылачак «Болгар» номерларында андый үзәкне эшләргә хыялланган идек. Әмма анда безгә нибары 24 кв.метр урын бирделәр.

Ким МИҢНУЛЛИН. Соңгы елларда институт текстологлары шагыйрьнең алты томлы академик басмасын төзү

Профессор Зөфәр Рәмиев һәм язучы Вахит Имамов

белән шөгыльләнделәр. Тиздән Татарстан китап нәшриятында аларның соңгы томнары басылып чыгачак. Бер ел элек без тукайчыларны институтның Язма һәм музыкаль үзәгенә күчердек. Хәзерге вакытта алар Тукай энциклопедиясен төзүне төгәлләү алдында торалар. Әйтергә кирәк, алга таба да Тукай темасы безнең фәнни тикшеренүләр планнарыннан төшмәячәк. Нечкәләп өйрәнүне сорый торган проблемалар, мәсьәләләр җитәрлек.

Тукай безне зур җитәкчеләр, җәмәгатьчелек, төрки дөнья алдына алып чыга ала. Институтта шактый чаралар уздырабыз. Төрки кардәшләребез игътибар итәрлек, алар теләп килерлек чараларыбыз күп түгел. Тукай, Ибраһимов, Урманче, Исхакыйларга багышланган конференцияләр үткәрсәк, чит ил кунаклары күпләп килә. Тукайчылар төркеме аша Тукайны һәм аның даирәсен өйрәнүдә яңа бер этапка чыгарбыз, дип уйлыйм.

Зөфәр РӘМИЕВ. Тукайның академик басмасына шагыйрьнең моңа кадәр читләштереп киленгән барча әсәрләрен, элек кыскартылганнарын тулысынча керттек. «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» кебек Тукай төзегән китаплар да өстәлде. Тукайныкы ихтимал дигән әсәрләрнең кайберләре алынды. Мәсәлән: «Сөй гомерне, сөй халыкны» исемле шигырьнең Сәгыйт Сүнчәләйнеке икәнлеге ачыкланды. Томнар азагына тулы рәвештә исемнәр күрсәткече бирелде. Шәрехнамәне «реакцион», «буржуаз» кебек сүзләрдән дә чистарттык.

Ким МИҢНУЛЛИН. Белгечеләр күптомлыкларны һәм энциклопедияне эшләр өчен Тукай чорындагы гарәби язулы матбугатны өр-яңадан актарып чыгарга тиешләр. Бу бик катлаулы эш. Аны бит соңгы чыккан томнардагы әсәрләр белән чагыштырып чыгарга да кирәк. Миннән Вахит әфәнде: «Тулы буламы инде бу томнар?» — дип сорый. Бу белгечнең әзерлегенә, аның шуның кадәр матбугатны карап чыгарга вакыты җиту-җитмәвенә бәйле. Газетадагы мәгълүматны күреп кала аламы ул? Яңа басма элекке 5 томлыкны 6 томлыкка күчереп кую, аңа нидер өстәү генә түгел. Бу өр-яңадан бөтен матбугатны өйрәнеп чыгу, дигән сүз!

Ләбиб ЛЕРОН. Без Тукайдан ераклашкан саен, Тукайга якынлашабыз. Тукай — безнең бренд, Тукай — безнең пәйгамбәр, Тукай — безнең маяк. Без,

кая барсак та, Тукайны телгә алырга, аны пропагандаларга тиеш. Федераль Сабантуйларын үткәрү матур традициягә кереп китте. Шушы Сабан туе кысасында, «Безнең мирас» редакциясе белән берлектә, Тукайның күчмә музеен оештырып булмыймы?

Икенчедән, Тукайны гади халыкка җиткерергә теләсәк, аның иң яхшы бер шигырен аерым китапчык итеп бастырыйк. Калын китап чыгарсак, кыйбатка төшә. Музейга килгән турист юка гына бер китапчыкны алып китсен.

Мин күптәннән «Шүрәле язы»н оештырырга кызыгам. Халык иҗатыннан алып, һәрбер татар әдибенең, рәссамының, рус һәм дөнья классикларының Шүрәле турында әсәре бар. Шуларны җыеп, бер «Шүрәле энциклопедиясе»н дә төзеп булмасмы икән? «Шүрәле» ул — безнең фольклор да, әдәбият та, сәнгать, театр, музыка да... «Шүрәле» — үзе зур бер дөнья.

Разил ВӘЛИЕВ. Безнең «Җыен» фонды Тукайның 130 еллыгына «Шәхесләребез» сериясеннән ике томлык чыгарачак. Тукай турында әлегә кадәр шактый күп истәлекләр чыкты. Әмма күбесе редакцияләнеп, цензура аша үтеп, алып ташланды. Томлыкларга кыскартылган өлешләр кире кайтарыла, яңа табылган документлар кертелә.

Ләбиб ЛЕРОН. Без журналыбызда Вафа Бәхтияровның истәлекләрен бастыра башладык. 1986 елда кыскартып бастырылган истәлекләрдә «Ф.Әмирхан белән Г.Тукай бик озак бәхәсләшәләр иде», — дип язылган. Монда бернинди хилафлык та юк кебек. Әмма Вафа Бәхтияровның кулъязмасы белән чагыштырып карасак, «кәртә уйнаганда» дигән сүз төшеп калган икән...

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ:

— Тукай китаплары әзер икән, алар нинди генә басма булуга карамастан, ул романмы, фәнни томнармы, аларны бастыру буенча эшләргә кирәк. Китапларын телләр программасына, башка милли программаларга, дәүләтнең социаль әһәмиятле басмалар исемлегенә дә кертик.

Венера КАМАЛИЕВА:

— Тукайның китапларын чыгару тәкъдиме белән безгә килегез, без аларны чыгарабыз. 2 яки 3 кенә шигыре булган китапларын да чыгарырга мөмкин, безнең бик яхшы рәссамнарыбыз бар.

Разил ВӘЛИЕВ. Без Төркиягә еш йөрибез. Анда Тукайга хөрмәт искиткеч зур. Бер очрашуга Төркия Президенты Абдулла Гюль килде һәм төрек телендә Тукай шигырьләрен укырга тотынды. Бөтен делегация вәкилләре көтеп тора, ә ул аерыла алмыйча Тукайны укый! Хәзерге Президентлары Рәҗәп Тайип Эрдоган да университетның актлар залында Тукай шигырьләрен укыды. Моннан бер атна элек кенә Казанга Төркиянең парламент җитәкчесе Җәмил Чичәк килде. Ул да үзенең чыгышын Тукай шигыре белән башлады. Төрек җитәкчеләре тарафыннан Тукайга нинди зур ихтирам! Анкара урамында Тукайга бюст, Истанбулда Тукайга һәйкәл тора. Әмма бер кимчелек бар: хәзерге заман укучысы өчен Тукайның төрек телендә саллы китабы юк.

Тукай йөргән урыннарны, Тукай музейларын без ничек кайгыртабыз? Безгә берәү: «Тукайның гомере ятимлектә үткән, Тукай бүген дә ятим!» — дип әйткән иде. Бу сүзләрдә күпмедер дәрәҗәдә хаклык та бар. Казанда нинди яхшы музейлар эшли! Япеев урамында Толстойга нисбәтле җимерек йорт тергезелеп килә, Боратынский музее ремонтлана, Аксёновка багышланган нинди затлы музей салып куйдылар. Аксёнов

«Түгәрәк өстәл»нең азагында Казан архитектура-төзелеш университеты студенты Кристина Почуева Г.Тукай әдәби музеен төзекләндерү проекты – диплом эше белән таныштырды

татар халкы, республикабыз өчен нәрсә эшләгән? Нинди файда китергән? Ә Тукай музее нинди хәлдә? «Болгар»ны җимереп ташладык! Сәйдәш музее җимерек! Шәриф Камал музее ябык! Ә үзен-үзе хөрмәт итмәгән халыкны беркем дә хөрмәт итми!

Тукайны җәмәгатьчелек, рәсми органнар тарафыннан да күтәрергә вакыт җиткәндер, дип уйлыйм. 2015 ел — Россиядә әдәбият елы. Башкортстан Республикасы юлларында Нажар Нәҗми, Мостай Кәримнең шигырьләреннән өзекләр, халык әйтемнәре, мәкальләре язылган язуларны карап барабыз. Бездә шулардагыдай берсен күргәнегез бармы? Тукайның шигырьләреннән дә бер яисә ике юлны һәр чатка язып куярга мөмкин бит югыйсә!

Тукайның портретларын ишәйтеп кибетләргә чыгару кирәк. Чит илләрдә мин шуңа сокланам: һәрбер зыялы милләттәшебезнең йортына керсәң, түрдә Тукай портреты, Тукай китаплары. Нью-Йоркка бардым. Анда татар өендә Тукай китаплары, Тукай портреты… Япония, Төркия, Финляндиядә дә шулай! Бездә андый нәрсә бармы? Бердәнбер Туфан абый, чит илдә күреп кайтып, Тукай портретын ясатты, аны өенең диварына элеп куйды. Сез кибетләргә кереп карагыз. Тукай портретын таба аласызмы? Юк, таба алмассыз!

Республикабызда туристлык агентлыгы оешты. Үткән ел Татарстанга 1,5 млн турист килгән, быел 2 млн. га житкерәбез, диләр, ә 2020 елга 6 млн турист килергә тиеш, дип планлаштыралар. Татарстанга килгән турист татарны күрәм, дип килә. Бирегә килеп тә Тукайны күрмәсә, Тукайны белмәсә, татарны тулысынча аңлап булмый. Бу җәһәттән туристлык оешмалары белән элемтәгә керергә кирәк. Казан шәһәрендә, һичшиксез, Тукай маршруты булырга тиеш.

Гүзәл ТӨХФӘТОВА. Габдулла Тукай әдәби музеенда һәм Милли музейда Татарстандагы Тукай урыннары белән бәйле «Шагыйрь бишеге», Казан буенча «Нурлы Казан» туристлык маршрутлары эшли…

Разил ВӘЛИЕВ. Шулай да, туристлык агентлыклары белән бергәләшеп, бу эшне тагын да киңрәк җәелдерергә кирәк. Казанда Тукай белән бәйле урыннарга истәлек такталары куелмаган. Тукай «Амур»да да яшәгән.

Бу — Тукайга бәйле сакланып калган бердәнбер бина. Сәламәтлек саклау министрлыгында Тукайга бәйле кечкенә генә бүлмә бар. Әмма аны баетасы, тулыландырасы иде.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Тукайга «Болгар»га караганда «Амур» якынрак, чөнки Клячкин шифаханәсенә ул шуннан киткән. Тукай «Болгар» турында: «Мин аны күрә алмыйм», — дип гел әйтеп йөргән. Иң суык, иң туңган вакытында аз гына акчасы булса, 2-3 көн генә җылынып чыгам, дип, ул «Амур»га кергән. Тукайның тәнен җылыткан «Амур» исән бит әле безнең! Әмма ул яңгыр, җил астында торатора «Болгар»ның язмышына дучар булмагае, дип куркам. Биредә дәүләт җитәкчеләренә җәмәгатьчелектән мөрәҗәгать кирәк. «Амур»ны сакларга иде.

Вахит ИМАМОВ:

— Тукай музеен мондый хәлдә тоту безнең өчен хурлык! Тукайдан тыш бу — Шамил йорты. Бүген Шамил — 20 млн мөселманның маягы. Без аны онытырга тиеш түгел! Шамил алган кыйбла без үлгәнче дәвам итәчәк!

130 еллык алдыннан Тукайга багышланган төрле күргәзмәләр булыр. Безнең Татарстанда гына да берничә Рәссамнар берлеге бар! Чаллы, Алабуга, Әлмәт төбәкләрендә оештырылган күргәзмәләрне безнең Казан, бөтен Татарстан халкы күрергә тиеш.

Менделеев районы Песәй авылы мәдәният йортында Бакый Урманченың ак мәрмәрдән ясалган Тукай сыны әрәм булып ята. Авторның хыялы буенча, Тукай челтерәп аккан чишмәгә яки фонтанга карап ятарга тиеш. Бүген Песәй клубы ярым җимерек хәлдә, дымлылык югары. Вакыт узу белән Бакый Урманченың сәнгать әсәре юкка чыгачак. Әлеге хезмәтне, һичшиксез, Казан шәһәренә кайтарырга кирәк һәм ул шушы бинада торырга тиеш!

Лена ТЯБИНА:

— Хәзерге заман кешеләре өчен татар, урыс телләрендә Тукай әсәрләренең аудио язмалары кирәк. Тукайның үзе исән вакытта 34 китабы басылып чыккан, шул китапларның репринт басмалары да булсын иде. Мин янә бер хыял белән янам: Татарстанда Тукайның 26 урындыгын булдырыйк. Аның янәшесендә авторның герое яки берәр рәсеме, китабы булырга тиеш. Кеше «Амур» каршында, Яңа Кырлай яки Кушлавычта булган урындыкларга утырсын, ял итсен, Тукай турында уйлансын. Горький исемендәге ял паркында ничек матур итеп ясап куйдылар әнә!

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Хәзерге вакытта Тукайның тууына 130 еллыкны үткәрү буенча план эшләнә, моңа тәкъдимнәр кабул ителә. Ул планны бүгенге сөйләшү нигезендә тулыландыру мөмкин булачак.

Ләбиб ЛЕРОН. Тукайның 130 еллыгын бренд итеп күтәрергә кирәк!

Гүзәл ТӨХФӘТОВА. Бер гасырдан артык татар халкы Тукай белән бергә атлый. Бик күп табышлар, уңышлар белән бергә эшләнәсе эшләребез дә шактый. Иң зур бурычыбызның берсе — Габдулла Тукай әдәби музее бинасына ремонт ясау, аның яңа, заманча таләпләргә тулы килгән экспозициясен төзү. Гомумән, XXI гасырда Тукай мирасын өйрәнү, җыю, саклау, пропагандалау юлында бердәм һәм берәгәйле булсак иде!

«Түгәрәк өстәл» утырышы барышында яңгыраган чыгышларны, фикер-тәкъдимнәрне басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Габдулла Тукай

● Сугыша Инҗил белән Коръән, диләр; алдый алмаслар халыкны юк белән — монда хәзрәтләр сугышмый поп белән!

● Күп сөекледер бөтеннән — Тәңрегә сынган күңел.

● Барчагыз Алла җебенә ныклап тотыныгыз. Алла җебе дигәнем үзара якынаю, дуслашудыр.

● Тәкъдир сезгә теләктәшлек белән елмая: мондый зур бүләкнең кирәк кадерен белергә.

● Тәңредән эшләргә — көн, эшләп аргачтын, бирелгәндер тыныч йокларга төн.

● Хак Тәгалә нәрсә кыйлса ирке бар.

● Каршылык юктыр Ходайның иркенә.

● Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һичкемгә хас түгелдер.

● Өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык намазлыкка утырган, ...күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын: Ходаем, ди, бәхетле булса иде сөйгән, газиз угълым! Тамадыр мескинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь; карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?!

● Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына; бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә.

● Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала! Рәхмәте бик киң Аның, һәрдәм таян син Аллага!

● Шыр ялангач калдырылып талансам да, тормышта бик каты алдансам да, тукта әле, егъламыйм, Аллам юл ачар әле, дидем... Алла юл ачты.

● Әйдә, дустлар, бер тибрәник, акны Тәңре яклар бит... Караны бер көн каралтып, акны бер көн аклар бит.



● Артка бакма, ... идеал һаман да алда ул; алга барганнарга тик табыла табылса — Алла ул!

***

● Безләрне туры юлга күндергән Коръән икәндер.

● Аңлангачтын Коръәндәге бик күп серләр, үз-үзендән агаралар дини керләр.

● Язылган һәрбер сүз шәригать булып китми... Шәригатемез — Коръәне хәдистер, Коръәне хәдис тә кыямәт барачак, анда бер дә шик-шөбһә юктыр.

● Без, «Хатәмен-нәбиин» аятенә иман иткән мөселманнар, һичбер вакыт Печән базарыннан пәйгамбәр вә мәзһәб башлыгы эзләмәскә тиешлемез.

● Пәйгамбәрнең вафатыннан соң асла могҗиза булмас.

● Ахыр заманга каршы бөлгән байлар пәйгамбәрлек дәгъвасы кыйлыр.

***

● Бу эшләрдә зәхмәтләмик муллаларны, дин эшендә башчы иттек без аларны.

● Мулла да, ахрысы, фәрештә түгел, аның да остабикәсе бар, балачагасы бар, фатир түлисе бар — ни эшләсен, ачка үлсенме?.. Ну, болай булгач, мулла гаеплеме? Әллә безнең милләт гаеплеме? Әлбәттә, милләт гаепледер... Бер мулла биш вакыт намазда, җомгаларда, гаетләрдә имам тора, никах, талак эшләрен карый, казыйлык итә, туганнарны, үлгәннәрне, никахланганнарны яза. Шул арада ук мәдрәсәгә кереп мөдәррис тә була... Зиратка да бара... Әүвәл бер кешегә шулкадәр эш бирү дөрест түгел, инде бирелгәч, аңар жалование бирмичә, теләндереп йөртү дөрест түгел.

● Нигә курка бу татар, кузгалса дини мәсьәлә? Барсы кыркылдый тавыктай: «Дин кырак! Дәһри кырак!»

● Җитми мыр-мыр хәтем — чын, саф Коръән кирәк.

● Вагыйзьләр безнең үземезнең ана телемез илә безгә, динемезгә, дөньямызга кирәкле вәгазьләр сөйләсеннәр. Халыкның тамырлары буенча каннарын йөгертеп, күз яшьләрен чыгарып, әллә кай җирләрен чеметтереп-чеметтереп алсыннар. Мөнбәргә менгәч, фәлән мәкам берлә җырлау, төгән көй илә көйләү бик зур ояттыр. Алай гавам халкын көйләп тирбәтеп йоклатканчы, бер дә кешесез сахрага чыгып, гарәп шигырьләре көйләсәләр, артыграк булыр иде.

● Вәгыйзьләр... халыкның җыелган җире мәҗлестә, милләт исемене бер-ике кәлимә булса да, халыкны гыйлемгә, сәнгатькә өндәсәләр, нинди яхшы булыр иде.

● Тәрбиямез дә коры, рухсыз, мәгънәсез, һич файдасыз рәвештә «дини» генә булмыйча, дини вә милли тәрбия булсын. Мөселман булганымыз вакыт татар икәнемезне дә онытмыйк.

● Хатибның сүзләре дару хөкемендәдер. Даруны, шифа биргәч, ачы булса да эчәләр бит.

Текстны басмага ***Зиннур Мансуров*** *әзерләде.* ■

ВӘЛИДИ ЗӘКИ (Әхмәтзәки; 1890-1970), сәясәт эшлеклесе, тарихчы галим, публицист, проф. «Ялтйолт» журналының 1913 елгы 55 нче санында басылган «Тукаев белән сохбәтләремнең хатирәсе» исемле язмасыннан (автор — Әхмәтзәки) күренгәнчә, Казанда «Касыймия» мәдрәсәсендә укыган вакытларда (1908-1912) Т. белән очрашуы турында («бик аз сохбәт итә алдым»; шунда ук: «шагыйрь илә байтак вакытлар сохбәт иттем») ул өч хатирә яза. Беренчесе — Ф.Әмирхан янында булганда сөйләшү. Ләкин ул озакка сузылмый, чөнки бүлмәгә бер-ике туташ килеп кергәч тә, Т. чыгып китә. Бераздан башка бүлмәдә дәвам иттерелгән сөйләшү вакытында шагыйрь моны: *«Мин хатын-кызлар мәҗлесендә утыруны бер дә йөкли алмыйм, алар белән үз арамда зур бер пәрдә бар кеби тоям. Ничек тә алар илә сүз оештыра алмам кебек. Ошбулар өчен хатын-кызлар мәҗлесендә утырмыйм»*, дип аңлата. Икенче бер очрашу вакытында Г.Ибраһимовның «Йолдыз» газетасында басылган «Төрек-татар-

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

рус тарихыннан» исемле мәкаләләре турында сүз булып ала. «Үзенең кауменда милли хисләрнең русларга караганда ким булмавын күрергә теләгән» шагыйрь В.гә «Ялт-йолт» журналында Г.Ибраһимов язуыннан көлеп язачагын әйтә. Т. бервакыт В.гә: *«Ишаннарны инде бик күп сүктек. Син ни әйтсәң әйтерсең, әмма мин соңгы вакытта яхшы ишаннарда халыкның рухы илә бер мөнәсәбәт күргәндәй булам»*, — дип тә сөйләгән икән. Мәгълүм ки, Т. «Халык әдәбияты» исемле лекциясендә (1910. 15 апр.) *«...безнең халыкта җырлар өчен әүвәлге ике юлның күп вакытта бер дә әһәмияте дә булмыйдыр. ...безнең җырларымызның күп тарафы шулай — әүвәлге ике юлы соңгы ике юлга ябышмаган»*, — дигән була. В, бер ай үтүгә «Шура» журналында «Җырларымыз хакында» исемле мәкалә бастырып, шагыйрьнең бу фикерен хата фикер итеп санавын белдерә. Аныңча, *«...бездә бик күп җырлар бар, аларның мисрагълары бер генә мәгънә илә бик яхшы бәйләнгәннәр. Һәм араларындагы мөнәсәбәт бик ачык күренеп тора»*. В. Тукай вафат булган айда ук «Мәктәп» журналында «Тукаевның әсәрләреннән «Шүрәле»гә гаид җентекләү» исемле, поэманы шагыйрьнең «иң матур әсәрләреннән берсе» дип атаган күләмле мәкаләсен бастыра, әсәрне «җентекләп узарга» тели. Автор анда Шүрәле турындагы әкияти чыганаклар турында сүз йөртә («төрле халыкларда иң иске, һәрнәрсәгә бер Алла булуына ышанган заманнан калган»), Катановның Шүрәле хакындагы әкиятләрнең татарлардан, руслардан тыш, нимечләрдә һәм финнәрдә бар, дип әйтүен искә ала, башка төрки халыкларда аның булмавын, себер татарларындагы урман иясенең Шүрәлегә туры килмәвен әйтә. Егетнең урманга баруы исә «кыйссаның рус әкиятләре илә мөнәсәбәте барлыгын уйларга юл була» (аныңча, егетнең урманга төнлә, якты айлы кичтә баруы шул турыда сөйли). Әсәрдә табигатьне сурәтләгәндә, шагыйрь анда «үзенең милли хосусиятләрен күрергә тели,

аның очы-кырые күренмәгән урманын Чыңгызның гаскәренә татбикъ итә» (охшата)». Мәкалә авторы әсәрнең беренче өлеше соңындагы бәйттә (*«Ачыла алдың тарихтан театр пәрдәсе: / Ah! дисең, без ник болай соң? Бездә Хакның бәндәсе»*) «милли тарих»ның караңгы нокталары күңелен тырнавы чагылуын әйтә, ләкин бу юлларны урынсызрак итеп күрә («билгесез һәм мәгънәсе әйтеп бетерелмәгән»). Әсәрнең форма ягыннан яңалыгы турындагы фикерләрен язып тормавын (бу юлы сүзне калдырып торачагын) искәртеп, теле һәм өслүбенә кагылышлы күзәтүләрен китерә: «саф казанча дип әйтерлек дәрәҗәдә мәхәлли тел»дә язылган; «төпле бер өслүб» тотылмаган, вәзенгә, гармониягә артык әһәмият бирелгән. В. мөһаҗирлектә китап булып басылган истәлекләрендә, Казанда яшәгән вакытларын искә төшереп, әле Тукай белән очрашуга кадәр үк булган бер фактны китерә. «Әл-ислах» газетасын чыгаручыларның гамәлләрендә «тәвәккәлсез, фикерләренең байтагы нигезсез тапкан В. бервакыт «Бәянелхак» газетасында татар мәдрәсәләрен үзгәртү турында фикерләрен язып чыга, әмма ислахчылар аларны ошатмыйлар: Тукай бер эпиграмма (мәгълүм түгел), Ф.Әмирхан бер-ике мәкалә бастыра. Күпмедер вакыт узгач, танышкач, Т. «Бәянелхак»тагы әлеге мәкаләнең авторы Габдулла Гыйсмәти түгеллеген, бәлки В. язганлыгын белә һәм эпиграммасындагы «кайбер сүзләрнең урынсыз булуын» таный. В. язуына караганда, Тукай аралашкан Ф.Әмирхан даирәсендә эчкечелек, карта уены белән мавыкканнар, шунлыктан ул алар белән якынлашмаган. В., «Болгар»да яшәгән Т. янына еш кына баруын, «Бер шәехнең мөнаҗәте» шигыренең асылы исә Шәйбәк (Шәйбани) ханнан ук килә дип сөйләгәч, шагыйрьнең берара чыгытай әдәбияты белән дә кызыксынып алганлыгын әйтә. В. шагыйрьнең «Әл-ислах» газетасында басылган бер шигырендә (В.гә кагылышлы) фикерләр бик дөрес чагылмаганын әйткәч, Т. бу турыда бер мәкалә дә язуын, әмма аны Ф.Әмирхан (В.чә: «тәкәббер һәм һавалы кеше») бастырмавын сөйли.

«Тукаев белән сохбәтләремнең хатирәсе»ндә автор шагыйрьне соңгы мәртәбә үләренә дүрт сәгать кенә калганда күрүен әйтә. В. язган мәкаләләрдә һәм истәлекләрдә Тукай иҗатына мөнәсәбәте шактый субъектив булганлыгы күренә. Аның фикеренчә, Т. мөтәфәккир (философ) түгел, үзенең шигырьләрендә яңа бернәрсә дә барлыкка китермәгән; «фәкать шагыйрь генә улган бу зат биш-алты еллык татар яшьләренең фикерләрен, уйларын гына» җырлаган. Хәлбуки, бу хатирә язылган вакытларда бөтен татар матбугатында чыгыш ясаучылар да Т.ны бөек милли шагыйрь итеп хөрмәтлиләр. В. Тукайга да, үзен кәрлә дип атап фельетоннар язган Ф.Әмирханга да күңелендә кер саклаган шикелле.

З.З.Рәмиев

Әсәр.: Вәлиди З. Жырларымыз хакында // Шура. 1911. №14. Б.445-447; Әхмәт Зәки. Тукаев белән сохбәтләремнең хатирәсе.// Ялт-йолт. 1913. №55; шул ук. // Мәгърифәт.1998. 25 апр. (З.Ислам кереш сүзе белән); Валиди Тоган Заки. Воспоминания. Уфа, 1994. С.77-78; Вәлиди Туган Әхмәтзәки. Хәтирәләр. Өфә, 1996. Б.71-72; Вәлиди З. Тукаевның әсәрләреннән «Шүрәле»гә гаид җентекләү. // Мәктәп. 1913. №4. Б.116-120;

ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Вафа Бәхтияров

ТУКАЙНЫ ТАЛАГАННАР

Казанда «Әл-ислах» газетасы урнашкан бина. 1908 ел

1908 елның апрель башларында кайбер иптәшләре Тукайның тормышын җиңеләйтү, тормышына экономия ясау теләге белән [шагыйрьне] частный бер бүлмәгә күчерү уен алга сөрәләр. Бу теләкне Тукайның үзенә дә белдерәләр. Ул бу фикергә кушыла, риза була. Кабанның уң ягында, тәрәзәсе күлгә карап торган Дурандин йортында фатир тотучы хатынның бер бүлмәсе айга биш сум белән алына. («Болгар»да Тукай сигез сум түли иде.) Шул бүлмәгә шагыйрьне күчерәләр. Ике-өч көн шул бүлмәдә тора. Беркөн Сәгыйть (Рәми — *ред.*) белән безгә (без яңа гына җәйге фатирга күчкән идек) килеп керәләр. Сәгыйть бераз тора да үзе генә кайтып китә. Тукайга безнең тормыш ошады булса кирәк, шул килү белән өч-дүрт көн бездә торып, Фатих (Әмирхан — *ред.*) белән бертуктамый карта уйнап үткәрәләр. Беркөн миңа ияреп идарәгә чыга. Кичкә таба идарәгә Сәгыйть килеп, Сәгыйть белән Тукай бергә чыгып китәләр. Бер сәгать вакыт үтми, болар тагын идарәгә әйләнеп кайталар. Фатир хуҗасының икенче фатиргамы яки икенче шәһәргәме күченгәнен, үзе белән Тукайның бөтен әйберен алып киткәнен сөйлиләр. Тукай мендәреннән, одеалыннан, сумкасында булган бөтен бельёларыннан, җаныннан да артык күргән Пушкин, Лермонтов мәҗмугаларыннан мәхрүм булып ялангач кала.

Кичкә таба мин Тукайны җәйге квартирабызга алып кайтам. Эш Фатихка аңлатыла. Бу эшкә без Фатих белән пошынабыз, кайгырабыз. Тукай, бернәрсә дә булмаган кебек, салкын гына тыңлап утыра. Һичбер төрле кайгыруын, борчылуын белдерми.

Шулай итеп, Тукай безнең белән бергә тора башлый. Бернәрсәсе дә булмаганлыктан, Тукайның тормышы берничә ай авыр була. Аннан акрын-акрын җайлана.

СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВТӘН АЛГАН ИЛҺАМ

1908 елның декабрь урталарында Хөсәен Әбүзәров («Таң» мәҗмугасының баш мөхәррире) Санкт-Петербург[2], Мәскәүдән әйләнеп кайту мөнәсәбәте белән үзенең

*Ахыры. Башы журналның 4-6 нчы саннарында.
[2] Авторда — Ленинград.

фатирында (Дегтярный урамы, хәзер ул йорт урынында бакча) яшьләр мәҗлесе ясый. Шул мәҗлестә «ислахчы»лардан Фатих Әмирхан, Габдулла Тукай, мин булдым. «Таңчы»лардан Сәгыйть Рәмиев кенә иде. Бу күрсәткәннәрдән башка берничәләп мин белмәгән башкорт, казакъ укучылары, студентлары бар иде.

Мәҗлес табыны бай-мул итеп әзерләнгән, һәртөрле нәрсәләр бар. Мәҗлес башланды. Берничә тапкыр рюмкалар күтәрелде. Мәҗлес җанланды. Шау-шу, үзара сөйләшүләр башланды. ... күңелле, җанлы рәвештә бара. Бары тик Сәгыйть Рәмиев әллә нигә күңелсез, рухсыз хәлдә, утырган урыныннан торып йөри-йөри дә тагын утыра, тагын торып йөри. Шул арада мәҗлес хуҗасы Хөсәен Әбүзәров тарафыннан тагы рюмкаларны күтәрергә, чәкештерергә чакырып әмер бирелә. Сәгыйть тә урынына утырып, рюмкасын күтәрә дә, тагы торып йөрергә тотына. [Аннары] Сәгыйть үзе утыра торган урындыкның артына килеп баса. Башын ...башына куя, бер күтәрелә, шул арада янәдән аякка басып, башын югары күтәреп, бер-ике мәртәбә көлтә чәчен ике кулы белән артка себереп, ике кул белән утыргычның артына тотынып, иң әүвәл кыска көйгә «Әминә гүзәлем» җырын җырлап җибәрә, мәҗлес халкына бик ошый. Шау килеп кул чабалар.

Искиткеч гайрәт, көч, дәрт, йөрәк белән үзенең «Аллам» шигырен «Ашказар» көенә җырлый. «Ашказар»дан соң акыллар хәйран булырлык көч, йөрәк белән «Әллүки»не башкара. Сәгыйть «Ашказар», «Әллүки» көйләренә җырлаган чакта мәҗлестә булган шау-шулар, сөйләшүләр, ашау-эчүләр онытылды. Мәҗлес тынып калды. Һәркем тирән уйга батты. Мәҗлес халкының кайберләре ике кулы белән өстәлгә таянып тора, кайсы Сәгыйтькә карап хәйран булып тора, кайсы өстәлгә башын куеп тыңлап утыра. Кыскасы, мәҗлестә булган бөтен халык икенче галәмгә китте. Икенче төрле әйткәндә, адәм баласы белми яхуд аңлап җитми торган бер исерү белән исерә... хәтта татар көйләреннән ямь-тәм тапмый торган... йорт хуҗасы карт урыс... утырган урыныннан торып, Сәгыйть янына барып, Сәгыйтьне аркасыннан сөеп, маңгаеннан үбеп җибәрде.

Сәгыйть җырлап бетергәч тә мәҗлестә булган тынлык берничә минутка кадәр дәвам итә. Сәгыйть «Ашказар», «Әллүки»ләрне җырлаган вакытта Тукай башын бер югары күтәрә, бер түбән төшерә, бер артка китә, бер алга килә, бизгәк тоткан кеше кебек, үз-үзен тота алмаган хәлдә үткәрә.

Бу Әбүзәровның яшьләр мәҗлесе, шул мәҗлестә Сәгыйть Рәмиевнең искиткеч көч, ялкынлы йөрәк белән «Ашказар», «Әллүки»ләрне җырлавы Тукайга нык тәэсир итеп, Тукайның моңлы йөрәгеннән... язылачак «Милли моңнар» шигыре килеп туа. Сүз ахыры итеп минем әйтергә теләгәнем шул: бу «Милли моңнар» ялкынлы, давыллы, моңлы-зарлы йөрәкләрнең уртак йөрәк җимеше [булды].

ҖЫРЧЫ ТУКАЙ

Тукай музыка турында яхшы ук консерватор кеше иде. Тукай татар мотивларын, татар музыкасын гына сөя, бирелеп тыңлый торган иде.

1908 елның март урталарында «Евгений Онегин» операсына алып барырга күпме тырышылса да, алып барып булмады. Без, бер төркем «ислахчы»лар, китеп бардык. Ул үзенең номерына менеп китте.

Татар көйләреннән яраткан көйләре — «Уел», «Ашказар», «Әллүки», «Зиләйлүк», «Минзәлә», кыска көйләрдән — «Җомга», «Порт-Артур», «Байкал күл», «Былбылым», «Мәхбүс», «Әминә гүзәлем» көйләре иде.

Сәгыйть Рәмиевнең җырлавын һәм шулвакыт татар яшьләре арасында бердәнбер мандолиначы Солтан Рахманколыйның уйнавын бик яратып тыңлый иде.

ТУКАЙНЫҢ КИЕНҮ РӘВЕШЕ

Тукайның Җаекта басмаханәдә эшләгән вакыты. Кулында – «Мелла Насретдин». 1905 ел

Солдат эшеннән котылып, Арчадан Казанга килгәндә, Тукайның тышкы киеме чапан дисәң, чапан түгел, җилән дисәң, җилән түгел, казаки дисәң, казаки түгел исемсез бер кием иде. Тужурка урынына кигән киеме Урал казаклары кия торган киемгә охшашлы, арты ике җирдән бөргән, үзе якалы, якасы өч каптырмалы, тездән капларлык хәлдә. (Уралда «Мелла Насретдин» журналын тотып төшкән рәсемен карагыз.) Башында искерәк малахай бүрек, муенында керләнеп беткән ак шарф, аягында авыл карчыклары гына кия торган искерәк ак киез ката һәм бер чалбар иде. Җиңнәре озын ике фабричный күлмәк. Кулдан тегелгән бер кара сатин күлмәге дә бар иде.

Күлмәк җиңнәре озын булганлыктан, теге тужурка урынына киеп йөри торган киемнең җиңнәреннән чыгып тора иде.

Бер-бер җиргә барырга булсак, шул күлмәкләренең җиңнәрен берничә җирдән баулар белән бәйли торган иде. Катып, битләре яргаланып беткән, шул яргаланып торган урыннарга тузан-туфрак тулган, бөтен гомерендә крем яхуд май күрмәгән, башлары күккә карап торган бер пар күн итеге һәм бер пар резин галушы бар иде. Менә Тукайның Җаектан алып килгән бөтен кием-салымы — байлыгы — югарыда күрсәтелгәннәрдән гыйбарәт.

Башына малахай бүрек, өстендәге исемсез тышкы киемне, муенына керләнеп беткән ак шарфны, аягына кыска балтырлы ак катаны кигәч, нәкъ авылның уртача көн күрә торган керәстиән малае булып күз алдыңа килеп баса торган иде.

Югарыда күрсәтелгән киемнәрне кигән хәлдә Тукай, мин (Вафа Бәхтияр), хәзер дә исән-сау Казанда мех фабрикасында бухгалтер булып хезмәт итүче Лотфулла Вахидов, өчәүләп Фатих Әмирханга бардык. Тукайның Фатих Әмирхан белән беренче тапкыр танышуы, күрешүе шул югарыда күрсәтелгән кыяфәттә булды[3]. 1907 елның декабрендә шул утырышта Тукай Казанда калырга һәм «Әл-ислах»та эшләшергә сүз бирде. Шулай итеп,Тукай «ислахчы»лар арасына кереп китте.

Мин дә, Фатих та Тукайның бу кыяфәттә йөрүен килештерми сөйли торгач, турыдан-туры әйтмәсә дә, Тукай үзе дә бу кыяфәттә йөрүен яратмады булырга кирәк, бер пальто алырга кирәклеге турында сөйли башлады. Уралдан язган шигырьләре [өчен] Шәрәфләрдән… алган акчага Тукай, мин, Солтан Рахманколый — өчәүләп чыгып, талчукта тегелгән киемнәр белән сату итүче Ахунҗановлардан унбиш сум илле тиенгә яңа пальто алып кердек. Бу яңа пальтоны киеп йөри башлагач, Тукай авыл малае кыяфәтеннән чыгып, шәһәр кустарь малае кыяфәтенә керде. Киез катасын ташлап, югарыда күрсәтеп үткән күн итеген киеп, чалбарны итек өстеннән чыгарып, резин галуш киеп, малахай бүрек урынына кепка киеп йөри башлады.

Яңа пальто алгач, теге сөмсез тышкы кием, малахай бүрек, әбиләр катасы берничә

[3] Фатих Әмирхан үзе «Тукайны танышырга Борһан Шәрәф алып килде», дип яза.

айлар караватастында аунап ятты, аннары бервакыт юк булды. Ничек юк булганнар, белмәдем. «Болгар»да хезмәт итүчеләрнең берсенә биреп чыгарган булса кирәк.

ТУКАЙНЫҢ АВЫРУЫ[4]



«Күп вакыт шагыйрь иртә йокыдан торып, караваты өстендә тезен кочаклап йөткерә иде...» Бакыйлыкка күчәргә берничә сәгать кала. Клячкин хастаханәсе. 1913 ел

Шагыйрьнең бала чагында авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә, ишектән ишеккә ярым ач, ярым тук хәлдә сөрелеп йөрүе, Уральскида караңгы, кояшсыз, дәвасыз йөрүе, чамасыз тузан арасында Мотыйгулла мулла Төхфәтуллинның иске мәдрәсәсендә ач, ялангач хәлдә «укуы»... Уральскида Камил Мотыйгый типографиясендә буяу-краска иснәп уникешәр сәгать тоташ эшләве [ахыр чиктә Тукайны үпкә чирле итә]. Шул явыз үпкә авыруы белән авырган хәлдә 1907 елның октябрь аенда Казанга килә. Казанга килеп, «ислахчы»лар белән катнаша. ...Эшли башлагач та мин аны профессор Казимбәккә алып барып күрсәттем. Казимбәк шагыйрьдә икенче стадия туберкулёз табып, сафланырга, тизлек белән Кырымга китәргә тиешлеген белдереп кайтарды. Профессор Казимбәкнең биргән дарулары белән берничә атналар дәваланып йөрде. Кырымга китәргә мөмкинлек булмады. Соңга таба бөтенләй дәваланмас булды. Дарулар алып кайтып бирсәм дә, дарулардан файдаланмый, тәрәзә төбендә ята бирде, берничә тапкыр даруларны эчәргә, файдаланырга кыстасам да, колагына алмады, минем әйткән сүзләрдән көлә генә иде. Соңга таба әйтмәс булдым. Бу эшне бөтенләй ташладым. Күп вакыт шагыйрь иртә йокыдан торып, караваты өстендә тезен кочаклап йөткерә иде. Йөткереп бетергәч, тагын ятып йоклый яки йокламый түшәмгә карап, дәшми, сөйләшми моңаеп кына ята иде.

1908 елның июль аенда югарыда күрсәтеп үткән авыруы өстенә икенче авыру эләктерә. Бу авыру белән бөтенләй йөрмәс хәлгә килә. Ике бот арасы шешә. Авырлык белән генә йөри. Бу авыруын тагы күрсәтер өчен, көчләп булса да, шагыйрьне доктор Рукавишниковка (Бауман урамындагы сәгатьле аптека белән янәшә йортка) ике тапкыр алып бардым. Доктор шагыйрьгә йөрмәскә, чыкмаска кушып, өч төрле дару язып бирде. Рукавишников биргән даруларны өч-дүрт тапкыр эчте дә, тагын эчмәс булды. Тагы бөтенләй ташлады. Шул ике төрле авыруы була торып, шуның өстенә доктор йөрмәскә кушса да, докторның сүзен тыңламый, авырлык белән йөргән хәлдә август аеның урталарында Галиәсгар абзый Камал белән бергә Нижний (Горький)[5] ярминкәсенә икәүләп киттеләр. Нижний ярминкәсендә ике-өч атна торып кайттылар. Ярминкәдән кайтканда шагыйрь соңгы авыруын бетереп кайтты. 1910 елның декабрь аенда, ахыргы атналарда микән... Казаннан киткәндә күрешкән чакта шагыйрь: «Бу күрешү — актык күрешүебездер, бу авыру мине тиздән алып китәчәк», — дип күзләреннән яшьләрен чыгарып, минем белән аерылышты. Шул күрешү актык мәртәбә күрешүебез булды. ■

---

[4] Аерым сәбәпләр аркасында, бу урында истәлекнең бер өлешен төшереп калдырабыз. Кызыксынучылар булса, текстны хәзерге хәрефләргә аударган Рабит Батуллага мөрәҗәгать итәргә мөмкин. — *Редакция*.

[5] Нижний, Горький — хәзерге Түбән Новгород шәһәре.

УРАУ ЮЛЛАР УЗЫП СЕЗГӘ КАЙТАМ...

Ләйлә Гарипова,
филология фәннәре кандидаты

Төхвәт Ченәкәй (Төхвәтулла Гыйззәтулла улы Ченәкәй, 1893-1959) – иҗаты «кара пәрдә» артында калган, оныттырылган язучыларның берсе. Аның язу эшчәнлеге 1913-1914 елларда башлана – шигырьләре «Шура», «Кармак» журналларында еш басыла, башлыча «Сәмави», «Һомаюн» имзалары белән чыга. Бер-бер артлы китаплары нәшер ителә («Өмет очкыннары», «Көрәш кырларында»). Алар, нигездә, Оренбургта дөнья күрә. Шулай ук тәрҗемә һәм театр тәнкыйте өлкәсендә дә активлык күрсәтә (Мортазин В., Ченәкәй Т. Татар театры тарихыннан. Мәскәү, 1926).

Иҗатының башлангыч чорында вакытлы матбугатта мактау алган Төхвәт Ченәкәй соңыннан кискен тәнкыйть утына эләгә, «җидегәнчелек»тә гаепләнә, төрмәләрдә утырып чыга. Шәехзадә Бабич, герой-шагыйрь Муса Җәлил белән дуслыгы үзенә «күләгә» булып ята, татар әдәбиятыннан сызып ташлана…

1998 елда «Казан утлары» журналында Әмирхан Еники Төхвәт Ченәкәйнең бормалы да, фаҗигале дә тормыш юлын, аның Муса Җәлил белән кызыклы мөнәсәбәтен, иҗатының ни өчен караңгыда калуын күрсәтеп яза. Язучының шигырьләрен туплап, китап итеп басмага әзерләвен дә искәртә. Ләкин, билгеле бер сәбәпләр аркасында, китап басылмый кала.

Укучылар игътибарына Төхвәт Ченәкәйнең әдәбият галиме, тәнкыйтьче Хатип Госманга язган хаты белән (зур булмаган әлеге мәктүбтә язучының бөтен бер тормышы күз алдына килеп баса, хатның кульъязмасы Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге фондында саклана. Ф.153) берничә шигырен тәкъдим итәбез. Шигырьләр Оренбургтагы «Вакыт» матбагасында «Иреклек җырлары» исеме белән басылганнар. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: 2011 елда «Түгәрәк уен» журналында Гөлсинә Хәмидуллинаның «Яшел тышлы кызлар дәфтәре» дип аталган мәкаләсе басылган иде. Анда унҗиде яшьлек кызның көндәлегеннән алынган шигырьләр китерелә. Халык иҗаты үрнәкләре буларак күрсәтелгән шигырьләр арасында Төхвәт Ченәкәйнең «Иреклек җырлары»на кергән «Уян, татар!» шигыре дә урын алган. Бер җирдән икенче җиргә, бер илдән икенче илгә күченү, әлбәттә, эзсез калмаган, Төхвәт Ченәкәйнең шигырьләре дә таралган, «югалган», «халык»ныкына әверелгән. Ә соңыннан аларны эзләргә, тупларга язучының вакыты да, сәламәтлеге дә, мөмкинлеге дә булмаган…

«ҮЗЕМНЕ КАЙТАРЫП БИРДЕЛӘР, Ә МАТЕРИАЛЛАРНЫ БИРМӘДЕЛӘР...»

Фатих Кәрим белән Төхвәт Ченәкәй. 1935 ел

Хатыйп иптәш!

Шушы елның 7 нче ноябрендә язылган хатыгызны 24 нче ноябрьдә укырга насыйп булды. Шул хатыгыздагы мәсьәләгә җавап йөзеннән шушы хатны язам.

Иң элек революцион, прогрессив, яңа татар әдәбиятына дулкынлы юллардан йөреп, кулдан килгәнчә хезмәт күрсәтергә тырышып картайган шигырь агасын искә төшереп, хат язучы сезгә иң беренче, Казандагы мине белмәгән, ишетмәгән, күрмәгән әдәбиятчыларга, язучыларга, шагыйрьләргә, иң тәүдә театр эшчеләренә, артистларга-артисткаларга, иң башта музыкачыларга, җырчыларга, иң алда социалистик илнең алтынчы бишьеллыгын төгәлләп башкарыр өчен җан көчен аямыйча тырышкан мактаулы хезмәт гаскәре — Казан халкына чын шигырьле сәлам!

Сәламнән соң каләмгә күчәм.

Минемчә дә нәкъ шулай — сезнеңчә.

1. Татар поэзиясенең антологиясе бу хат барганга чаклы басылып чыккан булмаса, әле җыйналу өстендә булса, әгәр минем кайбер шигырьләр иң яраклы табылса, сез аларны казынып таба алсагыз, антологиядә аларның аралашуына каршылыгым юк.

2. Гражданнар сугышы чорындагы поэзия җыентыгында катнашу турында сезгә шуны искәртәм.

Мин 1914-1915 елларда яза башлап, матбугатка төрле лирик шигырьләр чыгара башлаган булсам да, иң чыккан, күпләп, 1917-1919 елларда күбрәк Оренбургта чыга торган газета-журналларда язышa башладым.

Аннан соң шул елларда язылган шигырьләр, алардан соңгы еллардагылар (1920-1924) шулай ук Оренбургта аерым кечкенә җыентыклар булып басылгаладылар.

Шунысы үкенечле, ул шигырьләрнең оригиналлары да, алар басылган газета-журналлар да үземдә саклана алмадылар. Аларны эзләргә, эзләр өчен гизәргә кирәк. Иң кимендә Чкаловка[1] барып килергә туры килә. Анда барып килер өчен экономик, физический мөмкинлек юк. Бер-береннән кечкенә 5-6 бала-чага. Аларның иң зурысы унбиштә, берсе биштә, кечкенәсе бишектә, барып булмый ничек тә. Саулыгым да чамалы.

Кулымда төрле чорларда язылган аз-маз лирик җырларым бар. Шуларны бүген-иртәгә «Совет әдәбияты» журналына җибәреп карыйм. Әгәр алар яраклы булып басылсалар, шуларның гонорарыннан юл расходлык акча җыештыра алсам, Чкаловка барып,

[1] Чкалов — 1938-1957 елларда Оренбург шәһәренең атамасы.

Заказное
Город Казань. 12
Школьный переулок
Дом 3-б квар. 2

анда калган нәрсәләрем арасыннан бераз шигырьләр сайлап җибәрә алыр идем. Юкса, минем бала-чагалы семья тормышымнан билетлык кына да акча арттырып булмый, иптәш.

3. Мин Бабичның тәрҗемәи хәлен, үзенең 10-15ләп көндәлек дәфтәрләреннән һәм туган авылына барып җыйнаган материаллардан, төрле кешеләрнең, үземнең аның турындагы истәлекләрдән файдаланып, бер тарихи әсәр булып калсын, дип, бик озын итеп (дәфтәр бите белән 100-150 бит чамасы булырга кирәк) язып, Башкортстан нәшрият бүлегенә тапшырган идем. Бер үк вакытта (1919-1920 елларда) аның табылган барлык басылган, басылмаган шигырьләрен дә акка күчереп тапшырдым. Тик шул югарыдагы тәрҗемәи хәлнең копиясе (оргиналы дисәк тә була) үземдә саклана иде.

Тик, үкенечкә каршы, үзегезгә мәгълүм, «Җидегән» мәсьәләсе буенча Казан НКВДсы минем 3-4 ящик язма-басма материалымны алды. Үземне кайтарып бирделәр, ә материалларны бирмәделәр. Бабич биографиясенең оригиналы да шунда калды. Сез Язучылар союзы исеменнән сорап карасагыз, аны табып бирмәсләр микән?

Минем күзләрем яхшы күрмиләр, бу хатка караңгы лампа яктысында гына, бик ашыгыч кына яздым. Танып укый алырсызмы, белмим. Әгәр танып укый алмасагыз, әйтеп язарсыз. Икенче тапкыр, үзем язып, башкадан күчертеп җибәрермен...

Сәлам белән Ченәкәй.
27.11.1956 ел

Төхвәт Ченәкәй шигырьләре

КИҢ СУЛУ

Бар иде илдә кара гүрдән караңгы тын яту,
Китде ачылып «нурани хөррият» исемле бер капу.

Түкде нурлар, сипде нурлар, нурга күмде ил йөзен,
Ялтыратды киң җиһанның күп йирен, күп диңгезен.

Кузгалып ил диңгезе шатлык белән шәп кайнады,
Чын ирекне котлар өчен сандугачлар сайрады.

Тарсынып типкән йөрәкләр алдылар иркен сулу,
Бар күңелләрдә теләкләр — ярсып алга омтылу.

Аңкыды корган чәчәкләрдә матур, чын гөл исе —
Бу азатлыкның, рәхәтлекнең гүзәл бер билгесе.

Милли моңлар яңгыратды күкне, гарше әгъляне[2]
Изге нурлар ялтыратды илне, йирне, кәгъбәне.

Килде киң, иркен тереклек, бирде ямьле иртәсен.
Ух!.. Яшәсен ул иреклек, мәңге-мәңге китмәсен.

[2] Гарше әгъля — күкнең иң югары катлавы.

МАТУР УЙЛАР

Әйдә, туганлар, тартышка!
Безгә өлеш бар тартышда,
Чын тартышлар китмәс бушка,
Әйдә, туганлар, тартышка!

Безне ак көн, бәхет көтә,
Нурлы алтын тәхет көтә,
Безнең инде башкаларга
Рәхбәр[3] булыр вакыт җитә.

Искә алып иске ханларны
Чыңгыз, Бату ханларны,
Кайтарырга вакыт җитде
Иске даннарны, шанларны.

Дошманлардан аласы бар,
Иске хан манарасы бар,
Бабайлардан калган пайтәхетебез —
Казан каласы бар.

Уйганыйк без, кузгалыйк без,
Шул малларны кулга алыйк без.
Канығып барыйк, тартып алыйк та,
Анларны кулланыйк без.

Кулга тоткач үткер кылыч,
Юлга чыккач, юк куркыныч,
Коткарыйк илне дошманнан,
Шунсыз безгә юктыр тыныч.

Эшлик эшләр — алга барсын.
Дошманлар хәйранга калсын,
Дан, дәүләтләр, шан, шәүкәтләр
Җанланып мәйданга бассын!

Йитәр, бик күп тоткын булдык!
Явыз дошманга кол булдык.
Мәзлум[4] булдык, мәхкүм[5] булдык,
Бар рәхәтдән мәхрүм булдык.

Инде һичкем куркыта алмас.
Безгә киртә, курку салмас.
Чишелде тел, кул-аяклар,
Безне һичбер көч тоталмас.

[3] Рәхбәр — юл күрсәтүче.
[4] Мәзлум — изелгән.
[5] Мәхкүм — хөкем ителгән.

ИЛ АНАЛАРЫНА

Сәлам сезгә, и туганлар!
Сезгә якты таңлар атды.
Чын иркенлек чишмәсеннән
Сезгә татлы баллар акды.
Сезгә инде ирек килде,
Көтелмәгән сәгадәтләр,
Матур җәйләр, ямьләр килде,
Нинди күңелле сәгатьләр.
Моңа кадәр тормыш сезгә
Аш урынына ташлар атды,
Гөнаһсыз ак йөзегезгә
Яшь урынына канлар акды.
Чорнадыгыз, төрендегез
Киң чүпрәкләр, чапанларга.
Исерекләрдән кыйналдыгыз —
Кысылдыгыз капкыннарга.
Арзан-арзан сатылдыгыз
Ерткыч байлар кәефе өчен,
Зинданнарга ябылдыгыз
Золым ирләр гаебе өчен.
Сезнең гали хакларыгыз
Аяк асда таптaлдылар,
Зур эш — күкрәк көчләрегез
Илтифатсыз ташландылар.
Искә алып шундый кара
Тарихларны, алга атлагыз!
Моннан соң үз хакыгызны
Башкалардан таптатмагыз!
Сезгә инде ирек кояшы
Кызганмый нурын сачде,
Тигезлекләр биреп истикъбальнең
Якты юлын ачды.
Нурлы йөзләр! Сез бу дөнья
Җәннәтенең хур кызлары,
Якты көнләр кояшы,
Караңгы төнләр йолдызлары.
Сез бу заман илләренең
Башлары — үз аналары,
Төрек-татар милләтенең
Кашлары, күз каралары.
Милләт өчен көндез-кичен
Талсын ак беләкләрегез!
Сез бит илнең аналары,
Хезмәт көтә илләрегез.
Эшләгез, и ак күкрәкләр,
Аксын маңгай тирләрегез! ■

БЕР ГАСЫРДАН СОҢ...

Факил Сафин

Зариф Мөэминовның әсирлектән җибәргән хатлары...

Былтыр Беренче бөтендөнья сугышы башлануга 100 ел тулды. 1914 елның 28 маенда Австрия-Венгрия тәхетенең турыдын-туры варисы эрцгерцог Франц Фердинанд хәрби манёврларда катнашу өчен Боснияңең Сараево шәһәренә килә. Һәр елның нәкъ шушы көнендә азатлык өчен көрәштә баш салган милләттәшләре рухын яд иткәнгә (XIV гасырдан алып XX гасыр башына кадәр Сербия Госманлы империясенә карый), серб милләтчеләре бу гамәлне үзләрен кимсетү дип кабул итә һәм эрцгерцог атып үтерелә.

Алмания императоры Вильһельм II «мондый хәлне кичерергә ярамый» дип, карт Франц Иосифны котырта һәм, нәтиҗәдә, Австрия-Венгрия Сербиягә каршы сугыш игълан итә. Русия Сербияне яклап чыга. Шул рәвешле үзе дә сугышка катнашып китә. 1 августта Алмания Русиягә сугыш игълан итә... Бөтен дөньяны ялмаган бу канкоешка бары 1918 елның 11 ноябрендә

генә нокта куела (Русия, зур югалтулар кичереп, мартта ук солых төзи). Анда Русия мөселманнарының да күпләп катнашканлыгы билгеле. Татарларның саны миллионга җиткән, дигән мәгълүматлар да бар (бу хакта тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев хезмәтләре аша танышырга мөмкин).

Сугышка алынып әсирлеккә төшкән татар-мөселман гаскәриләре арасында Зариф Мөәминов кебек укымышлы, зиһенле милләттәшләребез дә шактый. Арада язучылар да булган. Без ул чор турында Мөхәммәт Галинең «Карпат» повесте, Афзал Таһировның «Солдатлар» романы аша таныша алабыз. Зариф Мөәминовның «Солдат йөрәге» бәянын укыгач, ул язганнар белән алда атап үтелгән солдат-әдипләрнең әсәрләре арасында сугыш, сугышка карата фикер йөртү рәвешендә аваздашлык барлыгы ачык тоела.

Сугыш башланганда Зариф Мөәминов хәзерге Мөслим районына кергән Күбәк мәдрәсәсендә эшли. Зирәк һәм үз сүзен кистереп әйтүче алдынгы карашлы, абруйлы мөгаллимне 1914-1915 уку елында мәдрәсә казые итеп тә сайлыйлар. Үзенең сугышка алынуын 1954 елның 20 апрель датасы куелган бер язмада болай тасвирлый ул: *«1914-1915 елгы уку елына аяк баскач, 15 февраль көнне мине Алмания сугышына җибәрделәр. 1915 елның май аенда безне Австрия фронтына китерделәр. 1915 елның 5 июнендә разведкага җибәрделәр. Төркемдә ике урыс солдаты, ике татар егете бар иде. Ике австрия әфисәрен, бер немес әфисәрен блиндажларыннан тотып алып, әсирлеккә алып чыктык. Шул ук көнне штык сугышында ике немесне кадап ташладым, өченчесен пленга алдым. Шушы батырлыгым өчен һәм хәрби заданиене яхшы итеп үтәгәнгә, 191 нче Ларго-Кагульский полкның командиры мине беренче дәрәҗәдәге Георгий хачы белән бүләкләде. 1915 елның 8 июнендә, сул кул һәм сул аягым яралану сәбәпле, австриялеләр мине пленга алдылар. Ел ярым дәвалангач, эшкә ярарлык хәлгә килдем. 1916 елның октябрендә хәзерге Югославиядәге Бүснә-Һәрсәк (Босния-Герцеговина) һәм Хорватия җирләренә китерделәр. Сараево, Травник, Загреб шәһәрләрендә такта яру заводларында эшләдем.*

Әсирлектә чакта төрле милләт кешеләре белән таныштым һәм алардан күп төрдә хикәяләр ишетеп, дәфтәрләргә теркәп бардым. Шунысы кызганыч, 1917 елда Травник шәһәреннән Сараево шәһәренә күчерелгән вакытта, сумкалары-бызга тентү ясап, немес полицияләре минем тарафтан җыйналган 500дән артык төрле халык әкиятләре язылган 50дән артык дәфтәремне конфисковать итеп алды. Үземне 15 көн аерым камерада арестта утырттылар. Шушы көннәрдә солдатлар хәрәкәтендә актив катнаша башладым.

1919 елның гыйнвар аенда үз илебезгә кайттым. Илдә совет власте урнашкан иде. Кайтуга, мине волость мәгариф шурасына сайлап куйдылар. Мәктәпләре булмаган авылларда мәктәпләр ачарга ярдәм иттем, үзебезнең авылда да мәктәп ачып, укыта башладым.

1915 елда беренче алман сугышында йөргәндә ишеткәннәрдән чыгып язылган «Солдат йөрәге»ндә күп кенә җөмләләр кайсы урысчадан, кайсы хорватчадан, кайсы немесчәдән тәрҗемәләр. Аларны китапча матурлап язып чыгу кирәк булыр».

Өч сугышта (Беренче бөтендөнья, Гражданнар, Бөек Ватан сугышы) катнашкан, соңрак фольклорчы, мәгърифәтче-әдип буларак танылу алган Зариф Әхмәтлатыйф улы Мөәминовның язма мирасы соңгы елларда гына табылып, гарәп графикасыннан кириллицага Татарстанның атказанган укытучысы, шагыйрь Мөҗәһит Әхмәтҗанов тарафыннан күчерелде. Кулъязма-җыентык язучы Факил Сафин тарафыннан әдәби эшкәртелеп, искәрмә-аңлатмалар биреләп укучыларга тәкъдим ителә. Зариф Мөәминов турында «Чын мирас»та (Факил Сафин, «Әкиятче бабай», №1, 2014) шактый этрафлы итеп язылган иде. Шул ук журналда (№2-3, 2014) мәгърифәтче-әдипнең «Мәрьям» повесте да дөнья күрде һәм укучыларда зур кызыксыну уятты. Әлеге әсәр дә укучылар өчен шактый гыйбрәтле булыр, дип ышанабыз.

Зариф Мөэминов

СОЛДАТ ЙӨРӘГЕ

(Автобиографик бәян)

I

1915 елның май аена керү белән 240 нчы запасной батальондагы маршевой роталарда киеренке эш башланды.

Якшәмбе көнне «Тревога» белән уяттылар. Командирның ачы тавышын ишетүгә барысы да, йөрәкләренең күкрәк читлеген ватардай булып какканын тоеп: «Әһә, юкка түгел бу, сугышка кузгалабыз икән», — дип уйлап алдылар. Җаннарга кайнар кан йөгерде, кул-аяклар хәлсезләнеп калды. Бераздан иркенрәк тын алдылар, кайсыдыр белдеклесе хәбәр итеп өлгерде — чынлыкта хәрби өйрәнүләргә кузгалыш икән бу. Командирлар ут чыккандай шулай юри кыланалар. Сугышка бармыйбыз икән ич әле! Күңелле булып китте, дәрт тулышты, бер-беребезгә шаян сүзләр дә әйтешеп алдык. Стройга тезелеп басуга: «Марш!» — командасы яңгырады. Аяк астында тузан бутала башлады. «Запевай!» Таң вакытында стрельбага баручы солдатларның җыр тавышы бөтен шәһәр халкын татлы йокысыннан уятты. Әллә нигә моңсу яңгырады бу җыр. Өч-дүрт катлы йортларның чардакларында, гөлләр арасында, эчке күлмәкчән хатын-кызлар башларын түбән иеп елашалар. Урамның ике ягында да асфальт өстенә яңгыр тамчылары биешкән сыман — меңнәрчә күзләрдән яшь тама. Аларны күреп олы яшьтәге солдатлар чынлап йомшыйлар, җырның соңгы куплетларында аларның тавышлары кысылып чыга. Ә яшь солдатлар тагын да моңлырак итеп, горурланып җырлыйлар. Арадан шаянрак яшь бер солдат әкрен генә, көлемсерәгән тавыш белән иптәшләренә:

— Фельдфебель дә җылый башлады, прапорщиклары усалрак ахры, — диде.

Шулвакытта батальон командирының:

— Игътибарны читкә юнәлтмәскә! Аякларыгызны төз тотыгыз, кычкырыбрак җырлагыз! — дигән ярсулы командасы яңгырады. Әйтерсең, бу тавыш меңгә якын урамны каплаган солдатларны уйларыннан бүлеп, янә бер мәртәбә йокысыннан уятты, батальонның атлавында бердәмлек барлыкка килде. Әле генә елап барган фельдфебель авызын югары күтәреп ачы тавыш белән җыр башлап җибәрде. Ул, җебеп баруыннан ояла төшеп, сул ягына аскан шашкасын кысыбрак тотты.

Ату мәйданына тезелеп торган мишеньнәр каршысына килеп җиткәч, фельдфебельләргә кызуга туры килде. Усалландылар, җебеклекнең эзе калмады. Бу вакытта әлеге кара мыеклы фельдфебельнең урамда елавына беркем дә ышанмас иде. Взводныйлар отделениеләргә бүленгән солдатларны орышалар, сүгенәләр. Ул ара булмый, ротный командир килеп җитте. Анысы алай кычкырынмый, тик кайбер йомшак солдатларның (беренче нәүбәттә татар солдатларының) борыннарын кысып тарта. Гаҗәп, шушы урысча бер сүз әйтә алмаган татар солдатлары арасында мишеньнең күзенә үк бәрүче дә бар икән. Ул ятып атарга тиеш булса да, чүгәләп яки аягүрә басып атарга рөхсәт сорады.

— Мин охотник, ятып аны сукыр да ата... — диде ул урысча вата-суга, әмма эре кыяфәт белән.

Мишень тикшерүчеләр «отлично» билгесе күрсәткәч, әфисәрләр батальон командиры янына җыелдылар. Күңелләре булган әфисәрләр, төз атучының янына килеп, иңсәләреннән каккаладылар. Аларның «Рәхмәт!» диюләренә каршы «Рат-

сы стараться!» дип тиешенчә җавап та кайтара белми торган бу солдат — татар солдаты иде. Әфисәрләр арасыннан берсе аннан:

— Сугышка баргач, немесләргә каршы шулай ата алырсыңмы? — дип сорады.

— Керешкәле картус кигән немесләрнең берсен дә калдырмам. Алар бүреләрдәнерткычрак, — дип җавап бирде татар солдаты, бар белгән урысчасын җигеп. Татар солдатлары шактый күп икән, стрельбищеда алар сынатмадылар. Әфисәрләр инде аларга чак кына булса да яхшырак күз белән карый иделәр. Запас батальонда татарлар өчен — мулла, урыс солдатларга — поп булачак, дип белдерү ясадылар. Мулла белән попка эш кайда да табылып кына тора икән. Әбәттән соң шәһәр уртасындагы мәйданга батальон солдатларын алып килделәр һәм татарларны урыслардан аердылар. Татарларны кызыл фәскә марля урап кигән яшь кенә бер мулла үз тирәсенә җыйналырга кушты. Урысларны поп чакырып алды. Тик шунысы бик гаҗәп булды: марилар, чуашлар ике арада калдылар. Алар мулла янына да, поп янына да бармадылар. Әфисәрләрнең берничәсе шул милләт кешеләренең урысча белүчеләре белән ниндидер әңгәмә ясап утырды. Татар солдатларын мулла патша хәзрәтенә турылыклы булып гадел хезмәт итәргә ант эчтерде. Татар солдатлары арасында укыган егетләр дә бар иде. Алар куркынычлы сүзләрне кирегә әйтеп ант бирделәр. Мулла туктатып:

— Кайсыларыгыз анда ялгыш укыйлар? — дип кабатласа һәм кисәтсә дә, алар сүзләрен төзәтмәделәр. Мәсәлән, мулла: «Әгәр дә падишаһ хәзрәтенә зәррә кадәр хыянәт итсәм, мине Аллаһы Тәгалә рәхмәтеннән мәңгегәчә мәхрүм итсен», — дигәндә, алар: «Мәхрүм итмәсен», — дип укыдылар. Урысларны поп ничек ант иттерткәндер — попның укуына караганда, урыс солдатларының ачык башларына пумала белән ниндидер су чәчеп йөргәне күбрәк күренде. Марилар һәм башка динсез милләтләр дә ант иттеләр. Алар казармадан бербөтен икмәк алып килеп, вак-вак телемнәргә турап, үзләренчә нәрсәдер укып, берәр телем ипи ашадылар. Аларның бу кыланышларын күреп торучы әфисәрләр көлмәде. Хосусан, урыслар алардан бервакытта да көлмәде. Ә татар-мөселманнар фронтка барып кергәнче мари-чуашларны мыскыллап йөдәтте.

— Сез аллагызны бер телем ипигә ягып ашадыгыз, — дип көлделәр. Мари милләтендәге солдатлар үзләренең антлары хакында төпле фикерләрен аңлатып биргәч, бу антның мөселман һәм православие солдатлары антларыннан өстенрәк булуы ачылды. Икмәк һәм тоз бирүченең кадере һәрнәрсәдән өстен икәнлеген, икмәк-тоз бирүчегә карата кылынган хыянәттән дә зур хыянәт юклыгын алар бик төпле рәвештә аңлатты.

Май аеның матур бер көнендә 240 нчы запасной батальонда хәрби белем алган төрле яшьтәге солдатлар эшелонга төялеп фронтка киттеләр. Суточный акча егерме сигез тиен иде. Аңарга көнлек ризык алып була. Дүрт кадак ипи — унике тиен, ярты кадак колбаса — унбиш тиен. Тагын бер тиен, мөгаен, тарта торганнарга тәмәкелектер инде. Кипятокны бушлай бирделәр. Тагын ун көнгә хисаплап чәй һәм шикәр дә өләштеләр. Бу эшелон бәхетле булды, күрәсең. Фронтка барып җиткәнче ике урында тукталып, аларны яхшы ашлар белән сыйлап, кунак итеп тә алдылар. Суточной өстенә һәр солдатка тагын ике булки, ике пачка папирос, бер кап шырпы тараттылар.

Һәрбер вагонда солдатлар үзләренчә өздереп җырлый, моңланалар. Һәр халыкның үзләренчә моң сыйфаты бар. Ул моңны шул халык кына аңлый ала. Менә татар солдатлары төялгән вагон. Монда татарның моңлы көйләрен сузалар:

Урак урган җирләрем,
Печән чапкан җирләрем.
Күкчәчәктәй күкрәп калды
Туган-үскән җирләрем.

Урсам, уракларым үтми,
Чәчтем каты җирләргә.
Җибәрсәм, сәламем җитми,
Киттем ерак җирләргә.

Исән бул, җанашларым,
Сау бул, кара кашларым.
Исән йөреп, саулар кайтсын
Инде газиз башларым.

Әй нимесләр, нимесләр,
Йон эшләпә кимәсләр.
Рәсәй солдатлары сезгә
Мәңге башын имәсләр.

Мылтыгымны төзәрмен,
Колһуалла укырмын.
Бисмиллалы пуля белән
Нимесләрне чукырмын.

Менә урыс солдатлары төялгән вагоннар уза. Русия халыкларына гына хас булган яңгыравыклы авазлар яңгырый. Мөгаен, алар да ватаннарын өзелеп сөюләре һәм дошман нимесләргә нәфрәтле булган моңнарын җырлыйлардыр. Әнә бит алар да: «Жизнь свою положем...» — дип сузалар. Ягъни: «Туган илем өчен гомер дә кызганыч түгел», — дип җырлыйлар.

Иң кызыгы — марилар. Марилар татарларга кушылып беравыздан җырлыйлар. Нинди гаҗәп халык бу марилар?! Үзләренчә дә, татарча да, урысча да сөйләшәләр, җырлый да беләләр. Өч төрле тел осталары булганнар. Ике мари үзләренә кызу-кызу сөйләшә. Яннарына бер татар килде исә, шунда ук татарча сөйләшә башлыйлар, урыс килсә, шунда ук урысча сөйләшергә керешәләр. Шул ук вакытта алар мари булдылар һәм мари булып калалар да. Беркем гаеп итми, көлеп бер сүз әйтми. Икмәк белән ант итә мари, икмәкне олылый, кадерен белә. Яшәгән илне, илдәге халыкларны хөрмәт итә, телләрен өйрәнә. Үзенекен дә онытмый. Тел белү — мәгънәле эш ул. Мари халкы артык гади, ихлас, эчкерсез. Кайбер җүнсез кешеләр шул сыйфаты өчен мариларны кимсетмәкче була. Мариларны татарлар үзләренә, урыслар үзләренә аудармакчы булып күп җәфа чиктергәннәр. Бу аларның исем һәм фамилияләреннән дә күренеп тора. Әнә кара кашлы, кара

бөдрә чәчле яшь кенә мари егете. Аның исеме Хәмәтьяр. Фамилиясе Миңнеяров. Ягъни аның исем-фамилиясендә мөселманнардан кергән «Хәмәт», «Миңнеяр» бар. Менә сипкелле түгәрәк йөзле, саргылт кашлы тагын бер мари егете. Монысының исеме — Михаил, фамилиясе — Таңгылбаев. Михаил урыслардан килеп кергән. Асманбай, Уразбай, Миңнехан — боларны төп мари исемнәре дип була. Шулай ук кызлар исеме Сылубикә, Тукбикә, Гөлбикә, Гөлбистан, Таңсылу, Айсылу — бу исемнәрне дә мариларның татарлашуыннан килеп чыккан, дияргә була. Мари егетләре барысы да зур бер авылдан. Нибары дүрт кенә егеткә солдат булу бәхете (!) эләгүе белән мактаналар. Яшьтәшләре утыз сигез булып, шуларның утыз дүрте, күзләре бозык булудан, «негоден» булып калганнар.

— Сез мариларда күз бозыклыгы киң таралган. Мари халкының сәер үзенчәлеге бу дип әйтәләр, дөресме? — дип сораган идем.

— Менә безнең күзләребез урысныкыннан да, татарныкыннан да, немеснекеннән дә ким түгел. Сезнеңчә фикер йөртсәк, ягъни күзләребез таза булгач, без мари халкы булудан туктыйбызмыни инде? — дип каршы сорау куйдылар.

Мариларның күпчеле күз авыруы белән изалана. Бу хакта алар менә болай сөйлиләр:

— Бездә бәйрәмнәр еш була. Бу бәйрәмнәрдә савыт-сабадан, хәтта бер сөлгедән берничә дистә кеше файдалана. Шул рәвешчә, үзләре дә сизмәстән, марилар арасында бер күзе бозык булган кеше йөз кешене боза ала. Моны алар белә, әмма гадәт шулай, мәҗүси аллалары каршында гөнаһлы калудан куркып, бу йоланы үзгәртә алмыйлар. Без ни өчен күзләрне бозылудан саклап калдык, дисезме? Без урыслар арасында яшәдек. Аралашып, урысларга эшләп үстек. Урыслар безнең һәрберебезгә аерым сөлге тотарга һәм аерым савыттан ашарга өйрәттеләр. Без ярлы халык. Без мари бәйрәмнәренә катнаша алмадык, — диләр.

Паровоз кычкыра-пошкыра алга чаба. Юл кырындагы будкалардан хатыннар яки сакаллы ирләр — юл эшчеләре — яшел материя уралган кыска гына таяк тотып чыгалар һәм шушы кечкенә әләмчекне җир селкетеп барган эшелонга табан сузып калалар. Яшел таякны күрү белән үк паровозга дәрт өстәлә, ул пошкырып, көпчәкләрен тагын да кызулатып җибәрә. Паровоз сызгыра, шпаллар селкенә, рельслар чажылдый. Яшел киемнәргә төренгән хәрби халыклар бу берничә йөз метр озынлыктагы сөйрәлеп, үкереп шуыша торган коточарлык зур аждаһага охшаган эшелонның кемнәргә каһәр булып алга ашкынуын сизәләр. Содатларның йөрәкләре тагын да ныграк кага. Шушы, һич куркуны белмичә, гайрәт белән кызулап алга ыжгыра торган эшелон, бермәл эчендә дошман тылына сөзеп кереп, нимесне тар-мар итеп бетерсен иде дә... Хыял... Зур стансаларга якынлашкач, паровоз үзенең килеп җитүен белдереп, мәһабәт тавыш белән озак итеп кычкыра башлый, инде стансага җитеп, дистәләгән рельслар арасына килеп кергәч, тынычлана төшеп, моңсу гына тагын бер тапкыр кычкыра. Аның бу соңгы тавышы бер караганда исәнлек сорауга охшаса, икенче исәптә «шушы зур һәм матур вокзалда туктап, азрак ял итәргә булмасмы?» дигән шәфкать өмет итүгә охшый иде.

Ярсып килгән паровоз матур итеп эшләнгән вокзал турысына җитүгә, җыерылып каткан кара шинельле, ялтырап торган зур җиз сәмруг кошлы кокарда тагылган фуражкалы дежурный ялтырап торган җиз пудовкага (зур кыңгырау) кызу-кызу, бик каты итеп чүкеч белән сугып ала. Туктап тору юк. Паровоз бу өметсез чаң тавышын ишетү белән, үзендә һичкем җиңә алмаслык кыргый көч барлыгын күрсәтеп, тагын да катырак алга омтылып чаба башлый. Рельслар тагын да катырак чажылдый, вагон көпчәкләре тонык тавыш белән шаулыйлар. Вагоннарның ачык ишегенә шыгрым тулып яшел киемле солдатлар өелешкән. Солдатлар төялгән вагоннар очып-очып вокзал кырыннан узалар. Вокзал алдын-

да җыйналган төрле матур күлмәкле хатын-кызлар, башларын эшелонга игән хәлдә, күзләренә ак яулык тоталар. Кайберләре эшелонга горур караган хәлдә, ак яулыкларын солдатларга болгыйлар, кайберләре матур ап-ак кулларын изиләр. Аларны күреп солдатлар да хәрәкәткә килә: яулык болгыйлар, кул изиләр һәм горур тавыш белән:

— Йомшамагыз да, еламагыз да, җиңеп кайтырга барабыз! — дип кычкыралар.

Шаян урыс солдатлары:

— Не плачь, Мар-ус-ся! Скоро вернемся!.. — дип кычкыралар.

— Дай бог, пожалуйста, вернитесь все живыми… — диләр чибәр марҗалар, аларга каршы.

Менә бер зур шәһәр стансасы. Паровоз үз маршрутын бетерә дә, бу эшелонны калдырып, теге очтан урап үзе китергән эшелон кырыннан кире килә башлый. Ул солдатлар белән үз телендә саубуллаша башлый: «Хушыгыз инде, батырлар. Сезгә уңышлы көрәш телим. Илнең язмышын сезгә тапшырам. Шаять, сынатмассыз, нык булыгыз», — ди ул гүя. Тагын бер кат нык кына сызгыртып ала һәм, ягулык запасын тупларга дип, күмер склады ягына ашыга.

Стансаларның төрлесе бар. Без хәзер генә килеп туктаганында күренеш катлаулырак. Вокзал кырындагы юлда бер эшелон тора. Туклы бер эшелонга яралылар төялгән, болар — фронттан илгә, лазарет-госпитальләргә кайтучылар. Башларын-кулларын ак марля белән ураган яралылар сак һәм әкрен генә хәрәкәт итә. Ак халатлы сестралар сабыр, йомшак тавыш белән аларны юата, тәрбия кыла. Бу эшелонда бернинди рух күтәренкелеге күренми. Киресенчә, һәркайсында әрнүле уй-фикерләр кайнаша. Мондый эшелонны күргән кешеләрдә дошманга нәфрәт тагын да көчлерәк яна. Күптәнме, әлеге эшелондагы аяксыз, кулсыз, күзсез калучылар яңа гына килеп туктаган 240 нчы батальон солдатлары кебек тере, батыр йөрәкле, сукса тимер өзәрлек таза егетләр иде бит. Алар да фронтка барган чагында горур кыяфәттә, дәртле җырлар җырлап, шаярышып-көлешеп фронтка ашкыналар иде…

240 нчы батальон солдатлары сәгать саен фронтка якынлаша. Алар дошман булган немесләргә каршы үзләренең икеләтә-өчләтә, хәтта бишләтә артык көрәшергә тиеш булуларын сизәләр иде. Фронтка баручыларны монда кадәр китергән паровоз, ягулык, су запасын алгач, сау солдатларны калдырып, яралылар төялгән эшелонның башына барып туктады. Ул аларны алга, Русия үзәгенә алып китәргә тиеш. Бу юлы инде паровоз яңгыраулы түгел, бичара тавыш кына чыгарып, сулкылдап алды. Сугыш гарип-горабасы төялгән эшелонны кабул иткән вакытта ул дошманга каты нәфрәт, каты ләгънәт сүзләрен әйтеп кабат-кабат кычкырды һәм, яралы солдат белән сак мөгамәлә иткән табиб кебек, әкрен генә әлеге эшелонны үзенең бетмәс-төкәнмәс көче белән сөйри башлады. Йөреше кызганнан-кызды. Янәшә юлларны узу белән шундый каты кычкырды ки, дошман булган немесләргә тагын бер кат ләгънәт әйтүе булды бугай.

Күп вакыт узмады, инвалидлар эшелоны үтеп китүгә, яннан каты шаулап-сызгырып, кыргый көч белән, стансага тукталып та тормыйча, пушкалар-снарядлар төялгән сансыз вагоннарны сөйрәп бер эшелон үтте. Моны күреп, солдатлар: «Немесләргә — колбаса!» — дип кычкырдылар.

Бара торгач, 240 нчы батальон солдатлары төялгән эшелон чиккә якынлаша башлады. Бу вакытларда сугыш Австрия-Венгрия җирендә бара иде. Чиккә якынлашкан саен эшелонның бару тизлеге акрынайды. Кайбер стансаларда солдатлар төялгән җидешәр эшелон тукталып тора иде. Солдатлар вагоннарыннан төшеп ачык яланда, матур болыннарда йөриләр. Якташлары белән, хәтта туган-тумачалары белән үк очрашалар, хәл-әхвәл белешәләр, алдан ук китүчеләр үзләреннән соң булган авылдагы хәлләр, тагын авылдан кемнәр киткәнлеге, кемнәрнең нинди

хәлдә кайтканлыгы, өйләнеп киткәннәре — хатыннары, балалары, яшь солдатлар — авылдагы сөйгән кызлары хакында сорашалар. Авылда чакта үзләренең шаян эшләре турында сөйләшәләр, көлешәләр. Фронт юлларында иң ямьле очрашулар менә шушы инде. Санаулы көннәр үтәр, монда очрашып сөйләшкән, шау килгән солдатларның язмышы ничек булыр? Кем бетәр, кем калыр? Калучылар булса, ничек булып калыр? Шулай да, гомерлеккә гарип булып калганчы үлү артык икәнлеген һәрбер солдат (бигрәк тә яшьләр) аңлый, язмышларына — йә исән-имин калуны, йә яу кырында ятып калуны юрыйлар иде.

Ник шулай булмасын! Сугыш бит ул — үтерешү... Кайберәүләр пленда калу хакында сүз кузгаталар. Ләкин шунысы бар, солдатлар немесләрдә плен калудан шулхәтле куркалар. «Үзең үлгәнче, юк дигәндә ике немесне үтереп үләргә кирәк. Пленда калсаң, ни гарьлек! Илең күзенә, халкың күзенә ни йөзең белән күренерсең...» — диләр. Шунда күкрәгенә Георгий хачы таккан олы яшьтәге калын сары мыеклы башкорт солдаты:

— Каушап утырмаң, егеттәр, нисместәр менән өс мәртәбә осрастым. Улар һугыса белә, атакага эсеп күтәреләләр, кыдгану-фәләнне белмәйләр, дуңгызды кадаган кебек рәхәттәнеп кадый бирәләр, — диде һәм өстәп куйды: — Русия һолдатын касан, кемдең һындырганы булды? Бедгә беркем дә каршы тора алмай!

Солдатны, сакаулап сөйләшкәч, авызына вак (тәмәке) салып сөйләшүче татар солдаты дип белдем мин.

— Сөйләвен бик сөйкемле сөйлисең, абзый кеше. Авызыңнан вагыңны төкереп сөйләш әле, — дигән идем, теге агай кызып китә язды.

— Нәмә бас катыраһың, нәмәдәй вак булһын миндә? Татар түгел бит мин, асаба башкорт. Моңа тиклем башкортны осратмаган икән һин, — диде.

Кыенсына калдым. Оренбург губернасыннан икән бу башкорт агае.

Башкортларны беләм мин. Безнең якта халыклар ике төркемгә бүленеп яши. Бер төрлесенең урман-җире күп. Андыйларны башкортлар дип йөртәләр. Аларның җирләре гомерлеккә бүлеп бирелгән. Икенче төрлесенең, гомумән, күпчелек халыкның, җирләре бик аз, урманнары бөтенләй юк. Андыйларны типтәрләр дип йөртәләр. Бу аерма каян килеп чыккандыр? Ул хакта беркем бер сүз сөйләүче юк. Шулай яши бирәләр. Урман, җир бирелгән башкортларга патша хөкүмәте, ни сәбәптәндер, күп җәһәтләрдә җиңеллек тә биргән. Типтәрләр белән башкортлар арасында күремсезлек, хәтта эчке бер дошманлык хөкем сөрә. Типтәрләр һәрчакта башкортларга бәйле: тормыш өчен иң кирәкле булган читән чыбыгы, утын ишене башкортлардан сатып алырга мәҗбүрләр. Бер төрле сөйләшәләр, бер дин тоталар, кыз биреп, кыз алып торалар, тик типтәрләр кимсетүләргә дучар булып гомер кичерә. Авылда бер урамда башкортлар яшәсә, типтәрләр икенче урамда яши, аралашып йорт салу юк. Ниндидер аерымлану, каршылык бар. Башкортлар туктаусыз типтәрләр өстеннән әләк язалар, патша хөкүмәте аларның һәр әләгентикшереп, типтәрләрне тинтерәтеп бетерә. Һәрчак башкортлар өскә чыга, беркайчан да типтәрне яклаган хөкем булмый. Исең китәрлек! Типтәрләр үз хакларын даулыйлар, мондый тормышка һич риза-бәхил түгелләр иде.

Әлеге башкорт солдатының сүзләрен тыңлаганда, башыма шундый әрнүле уйлар килде. Мин үзем типтәр гаиләсендә туып-үскәнгә күрә, башта аны нәфрәтле караш белән каршыладым: безнең авылдагы кебек, типтәрләрне рәнҗетеп көн итүче бер ялачы, дип уйлаган идем. Баксаң, бу башкорт агае безнең авылдагы башкортлардан бөтенләй икенче төрле икән. Хәтта аның икенче бер милләт кешесе икәнлеге билгеле булды. Бездәге башкортларның бездән тел аерымлыгы юк иде. Ә чын башкортның үз теле бар икән. Ияләшмәсәң, аңлап бетермәле түгел. Эчкерсез, ярдәмчел, йомшак күңелле, башкаларны хөрмәт итә торган кеше булып чыкты бу башкорт.

Солдатларның сугыш хакында, сугыш хезмәте хакында бәхәс алып барган чагында, ил өчен утка керергә риза булып та, патшаны нәфрәт белән искә алулары гаҗәп иде.

Солдатлар арасында акыллы башлар күп. Берсе әнә сүз башлап, очыныпмы-очына:

— Без патша исеменә тик ант кына бирәбез. Чынлыкта илебез өчен ант эчәбез. Явыз немесләргә Русиягә килеп керергә ирек бирсәк, без Русияне немесләргә саткан булабыз. Немес патшалар моннан күп еллар элек Русияне таптаганнар. Русия халыкларын теләгәнчә мыскыл иткәннәр. Юк, безгә немес патшасы кирәк түгел. Урыс патшасы сугышка чакырганда «урыс», «татар», «башкорт», «чуаш», «мари» дип тормый. Әле бик яхшы яшәп ята идек. Әгәр дә урыс патшабыз үз рәгыятенә (вазифаларына) начар карый башласа, тәхетеннән алып ташларга Русия халкының көче җитмәс, дисезме? Шулай булгач, без, Русия халыклары, Русиянең үзенә дә хуҗа, патшага да әле без хуҗа! Русиягә кул сузарга теләгән теләсә кайсы дошманның алгы тешләрен коеп бетерү, арт сабагын укыту — Русия илендә яшәүче барлык халыкларның бурычы. Солдат егетләр моны әйбәт белә, изге бурыч дип саный…

Икенчесе сүзгә кушыла:

— Чыннан да, үз туган җиребез безгә кадерле. Русия солдатлары моңа хәтле күптапкырлар булган сугышларда дошман гаскәрләрен үз җирендә кыйнады. Менә хәзер дә безнең сугыш дошман җирендә бара. Дошман гаскәре илгә бәреп керә башласа, уйлап карыйк, бер генә авылны дошманга калдыру да ни дәрәҗәдә авыр булыр?! Илне дошманга бирү солдат өчен хурлык, йөз каралыгы. Андый мәсхәрәлекне безнең Русия солдатлары моңа хәтле күрергә күнекмәгән, мәсхәрәлек көненә калырга бервакытта да язмасын!

Укыган, грамотный егет өстәп куя:

— Русиянең җиңелүе — патшага гарьлек түгел, безгә гарьлек… — Ул, сүзен өзеп, көмеш портсигарыннан папирос алып, берне авызына капты һәм бу әңгәмәне бирелеп тыңлап утырган миңа сузды. Моңа хәтле юри дә бер папирос тартканым булмаса да, шундый грамотный кеше тәкъдим иткәч, тартасы иттем. Гомеремә беренче мәртәбә авызга папирос каптым. Егет, шырпысын сызып, башта минекен кабызды, аннан үзекенә ут элде. Гаҗәп, күңел күтәрелде, аңа дустанә рәвештә елмайдым.

II

Бу зур стансада без берничә көн тордык. Тимер юл төрле якларга тармакланып, эшелонны төрле тарафларга җибәрә. Өч көннән соң бары тик урыс солдатларыннан гына торган ике эшелонны төрек фронтына җибәрделәр. Аның артыннан ук төрле милләт халкыннан торган ике эшелонны алман фронтына озаттылар. 240 нчы батальон солдатлары белән тагын да бер эшелонны Австрия-Венгрия фронтына озаттылар. Башта бу эшелоннар Люблин шәһәрендә туктап торды. Берничә көннән соң полный музыка белән Галициягә озаттылар. Без үзебезнең генерал Брусилов корпусында хезмәт итәчәгебезне аңладык. Без Буг елгасы буйлап фронтка кереп киттек. Безнең часть — 48 нче дивизия, 191 нче Ларго-Кагульский полк булды.

Без сугышка керәсе көнне Львов өчен канлы көрәш бара иде. Урыс гаскәрләре каршылык күрсәтә алмыйча чигенәләр. Ләкин без катырак булып чыктык — каршы торабыз бит! Һәр төнне җидешәр тапкыр атакага ташланабыз. Дошман ягында Австрия-Венгрия солдатлары белән немесләр катнаш иде. Гаҗәп хәл шунда иде — без һәр кичне дошманнарның фронтларын өзәбез, меңнәрчә пленныйлар алабыз. Тик, ни өчендер, дошман гаскәрләрен һәнүз куасы урынга, кояш чыгу

белән һәр көнне егерме биш-утыз, хәтта кырыгар чакрым артка чигәбез. Русия солдатларының кан түгеп алган җирләрне, авылларны ташлап китәбез. Солдатларга бу бик гарьлек тоела.

Үткән көнге уңышлы атакадан соң безнең полк унбиш чакрым гына чигенде. Бары ике авыл, бер баяр усадьбасын гына калдырдык. Кичке разведчиклар хәбәр җиткерде: австриялеләрне нимес солдатлары ташлап киткәннәр. Позициядә тик австриялеләр генә калганнар икән. Кояш баюга без атакага хәзерләнә башладык. Ротный командирлар хәзер үз роталарын яхшылап стройда тоталар иде.

Мин ротный командирга, алдагы көннәрдәге хәлләрне күздә тотып, ризасызлыгымны белдердем:

— Без һәрбер төнне дошманның оборонасын өзәбез. Ә ни өчен кире чигәбез? Шулай ук Русия солдатлары хакында уйлаучы кеше дә юкмыни? Безгә яңадан бик авыр түләргә туры килмәсме? — дидем.

Ротный командир атта килеш ротаның каршында тора иде.

— Бу синең эшең түгел. Урынсызга тыгылып, солдатларның хәрби хәрәкәтен аксатырга телисең икән, чык стройдан, атам мин сине! — дип кычкырды һәм кобурасыннан наганын чыгарды.

Канның кайнар чагы. Тиз генә кругны (мылтыкның саклык йозагы) ычкындырдым да, винтовкамны төзәгән хәлдә, стройдан чыгып, ротныйга каршы берике адым атладым. Сизәм: бер-бер хәл булса, иптәшләр минем якта булачак. Бу хәлне көтмәгән ротный командир урман эченә чаптырып кереп югалды. Фельдфебель, взводный, отделение командирлары берсүзсез катып калдылар. Һаман кайнарланам. Иптәшләр тынычланырга кушып үгетләделәр. Фельдфебель миңа стройга керергә кушты һәм йомшак тавыш белән:

— Солдатлар тинтәк түгел, аңлыйлар, әфисәрләр барысы да — ишәк, фәләнтөгән итим, — дип каты сүгенеп алды.

Фельдфебель команда бирде. Атакага барачак роталар җыйнала торган җиргә тезеп алып китте. Баштагы кызулык атака вакытында да сүрелмәде. Бу атакада берүзем өч нимес солдатын пленга алып чыктым. Беренче Георгий хачын бирергә булды командир Брусилов. Ләкин орден кулга кергәнче каты яраланып, дошман ягында пленда калдым. Әсир төшкән көнем — 1915 елның 8 июне булды.

Бу көнгә кайтыйк. Безне әлеге качкан ротный командир каршы алды. Эшнең болгавыр чагы, миңа бәйләнеп, аны-моны тикшереп тормадылар. Шыпырт кына дошман позициясенә алып киттеләр. Сапёрлар салган басмага килеп җиткәндә, тавышларын кысып кына команда биреп, берәр сафка сузылырга куштылар. Әмма австриялеләр йоклап ятмый икән бит! Без килгән юл өстендә тузан күтәрелүдәнме, әллә алар алдан ук күреп-сагалап торганнармы — без басма аша елганы кичә башлау белән пулемёттан ут ачтылар. Солдатлар яралананалар, үлеп суга коелалар. Приказны бозучы булмады, солдатлар һаман тынлыкны саклый бирде. Дәррәү сафлар белән кичүдән туктатып, басмадан берәмләп кенә үткәрә башладылар. Басмадан үткән солдатлар елга яры буйлап чылбырга тезелә барды. Югалтулар күп булса да, елга аша кичү тәмамланды. Австриялеләр прожектор белән яктыртып, безне күзәтергә кереште. Елга аша чыгуыбыз сер түгел иде инде. Ул да булмады, безнең артиллеристлар прожекторны беренче снаряд белән үк бәрделәр һәм пехота атакага ташланды. Австриялеләр ягыннан бер пуля да очмый иде инде. Авыл буйлап казыган окопларын ташлап, сызып өлгергәннәр. Полк авылга килеп керде. Авыл тып-тын кебек. Бары ерак урам очында ике-өч пулемёт буран очырып ата. Пулемётка каршы барып булмый. Полк һөҗүменнән ярты сәгатькә тукталды. Безнең артиллерия авылны тупка тота башлады. Анда да, монда да пожар күтәрелде. Пехота авылның аргы ягына чыкты. Җәйге төн болай да якты, инде таң яктысы да отыры көчәя иде. Яшеренер җир юк, барысы да уч төбендәгедәй ачык күренеп тора. Австриялеләр, авылны калдырып, куе

бодай басуына чыкканнар да, җиде кат чылбырга таралып ятканнар икән. Һөҗүм итүчеләргә тагын котырып ут ачтылар. Кире авылга чигендек. Унбиш минут үткәч, австриялеләрнең чылбырлары арасына безнең артиллерия снаряд яудыра башлады. Безнең яктан һава шары күтәрелеп тора иде. Аннан дошман турында мәгълүмат рәсемгә төшерелеп, безнекеләргә тапшырыла. Австрия артиллеристлары бик еш атсалар да, һава шарын бәрә алмадылар. Полк тагын атакага ташланды. Сигез йөздән артык исән австриялеләр пленга бирелделәр. Пленныйларны кабул иткәндә, дивизия командиры генерал Брусилов үзе дә катнашты.

Генерал, пленныйлар сафына карап торганнан соң, әрле-бирле йөренеп алды һәм каты итеп:

— Ник бирелдегез? Винтовкасын ташлап, кул күтәргән солдаттан да чиркангыч кеше юк! — диде.

Австрия солдатлары беравыздан:

— Русиягә каршы сугышырга теләмибез, безнең алар белән бүлешәсе әйберебез юк, — дип җавап бирделәр.

Шунда арадан бер чех солдаты:

— Бу фронтка без Франциядән килдек. Ун көн йөрдем шушы фронтта. Урысларга каршы бер пуля да атмадым, — диде.

Австрия солдатларының: «Сугышырга теләмибез. Бүлешәсе әйберебез юк», — дигән сүзләре безнең Русия солдатларында да бик зур тәэсир калдырды. Стройга тезелгән полк солдатлары бердәм башларын түбән иеп җиргә карадылар. Безнең дә австриялеләр белән бүлешәсе әйберебез юк! Алай булгач, бу сугыш нигә кирәк? Патшага ант биреп кердек бит бу сугышка. Генерал да патша кушканга күрә генә солдатларга сугышырга куша. Кем туктата соң бу сугышны? Австрия патшасы Франц Иосиф белән Русия патшасы Николайның нинди бүлешәсе әйбере бар икән? Бу сорауга җавап бирергә солдат акылы җитми. Томанлы бу мәсьәлә солдатларны аптырата. Генерал Брусилов кыска гына аңлатма ясады. Тамагын

кырып алды. Солдатлар барысын да аңлый бит. Чынлыкны ярып салып та булмый. Кыен юлдан чыгарга кирәк иде:

— Балалар, — диде ул, — бүгенге уңыш өчен сезнең полк командиры полковник Красильниковны Беренче дәрәҗә хач-медаль белән бүләклибез. Моннан соң да шулай яхшы сугышыгыз. Һөҗүмдә катнашкан солдатларның һәммәсен хач-медаль белән бүләкләячәкмен. — Бераз тын торды. — Иртәгә 190 нчы полк һөҗүмгә бара, сез дә ярдәм итәрсез. Без бүген сигез йөз пленный алдык. Дошманның әле көче сындырылмады. Дөрес, аларның солдатлары күп түгел. Ләкин алар коралга бездән баерак. Мылтык һәм патроннарыгызны теләсә кая ташлап калдырмагыз. Без моңа хәтле дошманнарны куып бардык. Дошманнарны үз кораллары белән кыйнап алга бардык. Кызганыч ки, хәзер чигәбез. Барлыюклы коралларны дошманга калдырып чикмәгез. Йә, балалар, сезгә, ради бога, уңышлар телим, — диде дә, җиңел автомобильгә утырып китеп барды.

Безне, солдатларны, тынгысызлык биләп алды. Австриялеләрнең сугышырга теләмәүләре хакында ешрак уйланабыз. Ләкин безне шул гаҗәпләндерә: австриялеләр сугышырга теләмиләр икән, нигә соң алар үзләре башлап ата башлыйлар һәм күпләребезне үтерәләр? Без һөҗүм итә башласак, тизрәк пленга чыгу ягын карыйлар. Бу урыс солдатларын шикләндерә. Без бервакытта да алдан стрельба ачмыйбыз. Алар ата башлыйлар. Солдатлар арасында: «Австриялеләр үз җирләрендә сугыша бит. Урысларны куып чыгарып бетергәч, солых була икән», — дигән сүз таралды. «Алай булгач, аларга каршы сугышып йөрүнең нигә кирәге бар? Сугышмыйча гына үзебезнең иске чиккә китәргә дә, солых ясап, бөтенләй өйгә кайтып китәргә кирәк», — диешәбез.

Арадан берсе:

— Нимес патшасы кайзер Вильһельм: «Русияне бетерми торып, солых ясамыйм», ди икән, — диде.

Аның бу сүзләре кабына башлаган өмет утын сүндерде дә куйды. Сугышны башлавы гына ансат, туктатуы бик кыен икән ләбаса. Бер генә патша да алдан башлап солых турында сүз кузгатмый. Солдатларны алар таракан, кырмыска ише бөҗәкләр урынына да күрмиләр.

Солдатларның берешәсе килми, теге иптәшләренең сүзеннән көләләр.

— Русияне бетерү — бәрәңге әрчеп ашау гына булмас. Дошман нимесләрне Русия туфрагына бер табан да бастырмабыз! — диләр.

Андыйларга каршы сүз әйтүче табыла:

— Менә хәзерге кебек, гелән генә чигәргә кушсалар һәм көн саен егермешәр чакрым чигерсәләр, кая барып чыгабыз? Дошманны үзебез ияртеп кайтып керәбез түгелме соң өйгә? Солдатларга нинди приказ бирелә, шуны үтиләр. Ил өчен дип, үзләренә үзләре приказ бирә алмыйлар, үз башлары белән сугышып та йөри алмыйлар, — ди берсе. Аңа каршы беркем дә җавап бирмәде. Дөресен әйткәндә, мәсьәлә бик томанлы иде.

Өч көн йоклап ял иткәннән соң, кояш баеган вакытта, ротный командир килде. Ул алдагы төнгә сугышчан заданиене аңлатты. Приказ аңлаешлы — моннан өч көн элек кенә үзебез калдырып киткән авылны кире сугышып алырга. Ул авылны өч көн буена австриялеләр төрле ныгытмалар белән ныгыттылар инде. Мин ротный командирның приказын тыңлап бетердем дә шеренгадан өч адым алга чыгып бастым һәм винтовкамның курогын төшереп, шунда ук бер патронны ствол эченә кертеп, затворны чатлатып ябып куйдым һәм ротныйга карап:

— Моннан соң сугышмыйм мин! Өченче көн үзебез дошманга сугышсыз-нисез биргән авылны бүген бер юләр солдат та сугышып алырга теләмәс! — дип кычкырдым.

Фельдфебель каршыма йөгереп килде.

— Нәрсә өчен син һәрвакыт хәрби тәртипне бозасың?! Кем рөхсәте белән стройдан чыктың әле? — дип бәйләнә башлады. Взводный һәм отделение командирлары килеп җитте.

Ротный командир, үч алырга җай чыгуына куанып, җикеренә:

— Тиз генә коралсызландырыгыз һәм кулга алыгыз! — дип боерык бирде.

Шул мәлдә бөтен ротадагы солдатлар хәрәкәткә килде.

— Коралсызландырырга хакыгыз юк! Кагылмагыз! Ротныйдан башлап барыгызны да менә хәзер үк атып бетерәбез! Авылны үзебез алырбыз һәм кире бирмәбез! — дип кычкырган тавышлар колакка кереп калды.

Ротный командир тагын урман арасына кереп югалды. Солдатлар ротный командир качу белән, үзлекләреннән диярлек, тәртипкә килделәр. Фельдфебель эшне сузмаска теләп, кызу-кызу команда биреп, полкның башка роталары җыйнала торган җиргә алып китте. Безнең рота барып җиткәндә, башка роталар маршка кузгалып киткәннәр иде. Юл өстендә тәре тоткан бер поп янынннан үтеп баручы солдатларны чукындырып тора иде. Безнең полкта күпчелек мөселманнар һәм мари, чуашлар иде, попка бөтенләй игътибарсыз үттек. Колоннаның уң ягыннан элемтәчеләр кәтүшкәләрен сүтә-сүтә чыбык сузып баралар. Калкулыкның сыртына менеп җиттек. Тәбәнәк урман шунда бетте. Тирә-якта, төнне тагын да караңгылатып, биек манаралардай чинар агачлары үсеп утыра. Агачлар авылны уратып алган иде. Әйтерсең, бу биек булып үскән төп-төз агачлар бу авылның мәһабәт сакчылары — гыйфритләре иде. Авыл өстен әллә кайдан ике прожектор әледән-әле яктыртып ала, яктылык нәкъ без менеп җиткән калкулык өстеннән шуыша, урман буен яктыртып ала, урамнарны капшап үтә. Прожектор леп итеп сүнү белән, күзләр берничә секундка бернәрсә күрә алмый. Мондый мәл кыска гына булса да, солдатны читен хәлдә калдыра. Урман кырыенда берничә минут туктап тордык. Иплэп кенә приказ бирелде, шыпырт кына кем аяк өсте, кем мүкәйләп, кем ятып шуышып, түбәнгә таба — авылга карап кузгалдык. Прожектор яктырткан арада безне шәйләп алдылар, өстебезгә пулемётлардан ут ачтылар.

Взводный минем яннан шуыша икән. Ул миңа:

— Мукминов, синме бу? — дип пышылдады. Раслаган төс биреп, аваз чыгардым. — Австриялеләр урысларга каршы ачыктан-ачык сугышырга теләмиләр, пулемёттан гына сибәләр, — дип сөйләнүен дәвам итте.

Ни дип җавап кайтарганмындыр. Хәтерләмим. Полк командиры Красильниковмы, башка командирмы, кайсыдыр каты итеп команда бирде:

— Ур-ра! Ур-ра! Эт җыккырлары, алга, калмаска!

Һәммә солдат беравыздан «Ура» кычкырып алга йөгерә башладык. Дошман ягыннан бер пуля да килми иде. Чәнечкеле тимерчыбыктан үргән ныгытма кырына килеп җиттек, шунда полк шып туктады. Кайчылы солдатлар чыбыкны кисеп өлгергәнче берничә минут үтте, әмма кайчылылар юлны ачканчы дошман пулемётларының кургаш бураны полкның ярты солдатын җиргә егып салырга өлгергән иде инде. Күтәренке «ура» тавышлары тынды. Баш күтәреп булмый: прожекторлар туктаусыз яктыртып торалар, ул да булмады, бер-бер артлы анда да, монда да снарядлар төшеп ярыла башлады. Җир актарыла. Солдат гәүдәләре һавада очып йөриләр. Кул астына үлгән солдатның кайчысы килеп эләкте. Аны алып, чәнечкеле читәнне кисә башладым. Сул як калак сөягемә бер осколка килеп бәрелде, уң ягым белән җиргә аудым. Үлмәс җанга бер сәбәп дигәннәр, баштүбән, ярты гәүдәм белән чокырга тәгәрәп төштем. Аякларым өстә калды. Шул ара булмады, сул ботыма пуля килеп тиде. «Аһ» иткәнче бер кул, бер аяк белән генә калдым. Шулай да исән калудан өметне өзмим, чокырга бөтен гәүдәм белән яшеренергә

тырыштым. Пуля сызгыруларын чамалап ятам. Мөгаен, миннән бер карыш югары җирдә энә булса, тыз-быз очкан пулялар шул энәне дә өзәр иде. Бу гарасат ярты сәгать чамасы дәвам иткәндер. Миңа ул чиксез сыман тоелды. Ату тавышлары, ниһаять, туктады. Бөтен полк, чалгыдан чапкан төсле, кырып ташланган. Нибары җиде солдат яраланып исән калган. Шуның берсе мин идем. Моны соңрак белдем.

Кояш чыккан вакытта ике дошман солдаты күренде. Хәлем мөшкел, тик аңым бар, хәтерләп ятам. Яраларым каты булса да, сөякләр исән, ахры. Иткә пуля тисә дә, рәтләнергә өмет бар. Бу кайзер солдатлары үлеп җитмәгән яралы урыс солдатларын кайсын атып, кайсын штык белән кадап миңа табан якынаеп киләләр. Боларның эт өргән кебек «һау-һау» дип сөйләнүләреннән австрия немесләре икәнлеген белдем. Киләләр болар. Инде чират миңа да якынлаша. Үз-үземне белештермичә, башымны күтәреп:

— Бу нинди вәхшилек, кешеләрме сез, әллә этләрме? — дип кычкырдым. Болар минем өскә ташландылар. Прикладлары белән гөжт итеп яралы аягыма китереп суктылар.

— Үтерегез, үтер! Ләкин шуны белегез, Русия гаскәрләре киләчәк орышта сезне дә үтерер! Инде яраланып, үлми калсагыз, болай кыйнамаслар, госпитальгә дәваларга җибәрерләр, — дип ыңгыраштым.

Шушы сүзләрне әйтеп өлгерүгә уң яктан килгән бер Австрия әфисәрен күрдем. Ул ачылы тавыш белән нәрсәдер кычкырды. Немес солдатлары катып калдылар. Әфисәр нигәдер бик каты ачулана һәм каны тәмам кызган иде. Кычкыра-кычкыра минем янга килеп җитте. Әлеге немес солдатлары смирнога бастылар. Әфисәр боларны уңлы-суллы чапкалап алды. Үзе бик каты кычкырып: «Санитар!» — дип эндәште. Тавышына янәшәдәге чокырдан ике санитар чыгып, монда табан йөгереп килделәр. Исән калганнар аз иде. Мине һәм тагын бер иптәшемне култыклап алып, зур чокыр аша салынган күпер астына китерделәр. Нәкъ шушы вакытта безнең яктан урыс артиллеристлары авылны бик каты тупка тота башлаганнар иде. Австрия солдатлары керер тишек таба алмыйча анда-монда йөгерешәләр, торым-торымга авыл пожар белән чолгана бара. Тупка тоту бер сәгать чамасы дәвам итте. Исән калган Австрия солдатлары авылны ташлап, елга яры астына тулдылар. Безне күреп йодрык яныйлар, мылтык белән кизәнәләр. Хәлем юк, шулай да яндагы әфисәргә әйтеп каласы сүзем бар.

— Австрия солдатлары пленга алындылар исә, Русиягә каршы сугышырга теләмибез, диләр. Үзләре урысларга каршы аталар-аталар да, пленга чыгалар. Сугышта бераз өстен чыксалар, яраланып та үлми калган урыс солдатларыннан үч алып, аларны газаплап, үтереп йөриләр. Сезне моннан соң кеше дип әйтеп буламы? Этләр икәнсез! — дидем.

Әфисәр җавап кайтармады. Солдатларга ачулы карап:

— Яраларын яхшылап бәйләдегезме? — дип сорады. Аннан миңа төбәлеп: — Урысның көче бармы әле? — диде.

Мин аңа:

— Җитәрлек, — дип җавап кайтардым. Тавышымда ныклык сизелсен дип кычкырыбрак әйтергә тырыштым.

Ул миңа тагын үткер карап:

— Нигә кәпрәясең? Урыс түгеллегең күзеңә чыккан бит, — диде.

Урысча ярыйсы гына сөйләшсәм дә, башка кавем икәнен һәркем чамаларлык иде шул.

— Казак син! Һай, бик усал халык сез, казаклар! — диде.

— Сезнекеләр сугыш мәйданында бер дә батыр түгел. Яраланган Русия солдатлары янында ай-һай батыр кыланалар, — дип баягы сүземне дәвам иттем.

—Үлми калганнарны аталар, кадыйлар, кыйныйлар. Урыс командирлары солдатларны бу эштән тыялар, яралы дошман солдатын лазаретка җибәрергә кушалар. Приказны үтәмәгән солдатка кырыс чаралар күрелә...

Әфисәрнең йөзеннән кара төс йөгереп үтте. Ул да солдатларның рәхимсезлеген хупламавын белдерде.

— Сугыш шулай инде ул... — дип кенә куйды. Аннан күзгә карап, сорашуын дәвам итте. — Варшаваны кайчан бирәсез? Одессаны? Киевтан кайчан табан ялтыратасыз?

Мин турысын ярдым:

— Безнең солдатларда настрой әйбәт, шәһәрләрне түгел, кечкенә бер авылны да дошманга бирмәсләр!

Офицер янына солдатлар җыела башлаган иде, алар бу сүзләремнән көлешергә тотындылар.

— Алай бик настройлы булгач, урыслар ни өчен чигенәләр соң? — диде икенче бер әфисәр.

Күреп торам, башка яралы урыс солдатларына игътибар итмиләр. Минем тирәгә җыелды болар.

— Нигә чигенәбезме? Сезне шулай алдап китерәбез. Менә таулар тирәсенә барып җитегез әле, күрерсез күрмәгәнне. Арт сабагыгызны укыта башлагач, кабат: «Без урысларга каршы сугышырга теләмибез», — диярсез дә, пленда калырсыз...

Әфисәрләрнең йөзләренә тыелгысыз ачу галәмәте чыкты.

— Син — казак! — дип кабатлады Австрия әфисәре. — Явыз нәрсә! Чыкмаган жаның гына калган, бетле тәре, телеңә салынып ятасың!

— Мин казак түгел, мин чыкылдап торган Казан татары!

— А-а, ишеткәнебез бар. Русия татарлары сугышчан халык ул. Әүвәл заманнарда Аурупаны буйсындырганнар. Сугыша беләләр. Тик сугышуыгызның ата-анасы юк. Авыл-калаларны аласыз да, кире чигенәсез. Аурупаны алгансыз, аннан кая киткәнсез, шайтан белсен... Бу сугышта да шул — һөҗүмнәр ясап, авылны бер аласыз, аннан чигенәсез, аннан тагын кире алып азапланасыз. Ни үзегез сугышмыйсыз, ни безгә рәхәтләнеп сугышырга ирек бирмисез. Мәзәк халык икәнсез...

Шуннан соң безне санитарлар кулына тапшырдылар. Арбаларга төяп, сикәлтәле юлдан көне буе каядыр бардык. Кич булгач, янып беткән бер авылга туктап, авыл очында янмыйча калган бер амбарга тутырып кундырдылар. Яралар сызлый — чистартып, кабат бәйләп куючы юк. Икенче көнне атлар белән сөйрәтә торган кечкенә вагонеткаларга төяп, бер тимер юл стансасына китерделәр. Анда берәр банка консерва һәм берәр чирпәк (кечкенә чүмеч) какао бирделәр. Аннан соң тимер юл вагоннарына төяп, Краков дигән шәһәргә китерделәр. Стансада сортировать итеп, тагын да арткарак — Ржев дигән кечкенә шәһәрчеккә китерделәр. Бер йортка кертеп салдылар. Бу йортның бүлмәләре үз солдатлары өчен лазарет итеп файдаланылган. Хәзер хәрби әсирләр өчен лагерь икән. Монда әсирләрне иң нык интектергәне бет булып чыкты. Ул хәшәрәтләр әсирләрне тере килеш ашыйлар бит.

Көз җиткәч, безне бу лагерьдан Дрезден шәһәре кырындагы лагерьга җибәрделәр. Монда да бет иде. Дөрес, сирәк-мирәк мунча керткән булалар, аратирә кием-салымнарны кайнар парда тоткан булалар, ләкин бу «төзәтенүләрдән» соң бет тагын да ныграк котыра. Плендагы тормыш шул.

Яраларым көчәеп, уналтынчы елның башында лечениегә җибәрделәр. Минем өчен башкарак тормыш шуннан соң башланды.

Дәвамы бар ■



МИН БЕЛГӘН МУСА ГАЛИ

(Шагыйрь сурәтенә бер штрих)

Рауль Мирхәйдәров

Муса Гали... Муса ага... Ничек якын минем өчен бу исем, колагымны, йөрәгемне, җанымны, хәтеремне ничек рәхәт иркәли ул, үткән гомеремнең җылы кайтавазы булып күңелемә ята. Мин аның белән 1975 елда, Малеевкада таныштым. Беренче килүем, беркемне дә шәхсән белмим, һәм, табигый, бу җирләр яраткан урыныма әверелер дә бик күп еллардан соң миңа «карт малеевкачы» исеме тагылыр, дип уйлап та карамыйм әле (әйе, андый, кызганыч ки, сафлары көннән-көн сирәгәя бара торган туганлык та бар). Малеевканың иркен, затлы ашханәсенә аягымны тәүге атлаганда, исемнәре, сурәтләре, китаплары буенча таныш кешеләр — язучылар! — өстәлләргә урнашып беткән иде инде, кая төртелергә белми аптырадым. Бай ассортиментлы зур имән буфет каршындагы 1 нче номерлы өстәлгә күз ташладым: анда шагыйрь Сергей Остро-

Сулдан уңга: **Муса Гали, Рауль Мирхәйдәров, Мостай Кәрим. Малеевка. 1982 ел**

вой, аның хәләл җефете — мәгълүм виолончелист ханым һәм миңа таныш түгел кеше белән бергә Мостай Кәрим утыра. Әлбәттә, мин Мостай аганы шунда ук танып алдым, безнең заманда яшь язучы өлкән каләмдәшләрен, аларның иҗатын яхшы белә иде. Ә Сергей Островой белән икесе арасында утырган әфәнде үзенең күркәмлеге, итагатьлелеге белән игътибарымны җәлеп итте — озын буйлы, төз гәүдәле, көмеш чәчләренең куе «энәле» «керпесе» килешеп тора; аксөякләрнеке сыман ак йөзе, зур күзләре — һәммәсе дә бу кешенең шагыйрьлеге турында сөйли иде. Тышкы кыяфәт вакыт-вакыт алдаштыргаласа да, бу юлы мин ялгышмадым: Муса Гали, чыннан да, искитмәле шагыйрь булып чыкты. Безнең карашлар бер мизгелгә очрашты, шул арада мин ихтирам белән баш иярга, исәнләшергә өлгердем.

Малеевкадагы тәүге аш өстәлем әле дә истә, анда, миннән (прозаиктан) кала, шагыйрьләр генә тамак ялгады: Сергей Поликарпов, Лариса Васильева, Киевтан Павло Мовчан. Бик өметле күренгән әлеге яшь каләм иясе ерак 1975 елда ук Украинаның сәясәте һәм бәйсезлеге өчен борчыла иде, соңыннан яңа Украинаның күренекле җәмәгать эшлеклесенә әверелде ул, егерме елдан артык Югары Рада депутаты булып торды. Кайчандыр сәясәт безнең илләрне шулай ерагайтыр дип кемнең башына килеп карасын анда! Ләкин «бөекдержавачыл» Сергей Поликарпов белән Павло Мовчан арасында нинди усал, куркыныч бәхәсләр уянганы әле дә күз алдымда, мин аларны бүген, утыз ел гомер узганнан соң да, яхшы хәтерлим. Украинада милли мөстәкыйльлеккә өмет кузы шулвакытта ук пыскып-кызарып утырган лабаса!..

Иҗат йортлары — гаҗәп урын: монда илнең барлык кыйтгаларыннан язучылар бергә җыелып таныша, аралаша, эшли иде, бүген без анык беләбез — дөньяда аның тиңнәре бул-

маган һәм, мөгаен, булмас та. Шундый исәп тә бар: совет илендә чыккан миллионлаган-миллионлаган китапларның икедәнме, өчтәнме бере йә Малеевка, йә Переделкино, йә Комарово, йә Ялта, йә Пицунда, йә Күктүбә, йә Дубылты, йә Гагра, йә Дүрмән-Ташкентта — кыскасы, теге яисә бу Иҗат йортында язылган. Язучылар иртәнге якта, гадәттә, эшли иде, аннары, сәгать уникеләрдә чаңгы шуарга чыга, аннары төшке аш, төшке аштан соң — йә йорт тирәли, йә күршедәге Глухово авылына кадәр сәйран кылу... Һәркемнең үз маршруты бар. Озак вакыт Мостай Кәрим белән Муса Галинең «сукмагы» үзенчәлекле, үзгә иде, җәмгысе унлап чакрым йөри торган булганнардыр, моңа икеөч сәгать вакытлары үтә иде, тагын кемнеңдер бу юлны кабатларга атлыгу-алгысынганын белмим. Төштән соң, һава торышына игътибар да итмичә, кузгалалар — әүвәл елга буйлап атлыйлар, аннары Руза шәһәрчегендәге Кино йорты аша узалар, кәефләре яхшы икән, берәр чынаяк каһвә белән берәр чәркә коньяк җибәрәләр дә, ерак коттеджлар янындагы куе урман аша кире кайталар. Беренче елда мин шул иң ерак йортларның берсендә яшәдем һәм кичке бишләрдә аларның әкияти баһадирлар сыман урманнан чыгып килүләрен күреп кала идем. Көн салкын икән (ә ул вакытта кышлар гел салкын иде), бүрекләренең колакчыннары төшерелгән, баулары ияк астына бәйләнгән, ә үзләрен бәс сарган булыр. Һәм бик озак еллар буе шулай кабатланды — гадәтләренә хыянәт итмәделәр. Берсендә үзем сорап аларга ияргән идем, артларыннан көч-хәлгә өлгерә алдым, киночылар шәрабханәсендә генә рәт керде. Шуннан соң соранып йөрмәдем.

Кайвакыт төшкә кадәр үк чаңгыга басалар, ерак-еракта — урман эчендә — кара шәүләләре генә шәйләнә. Алар җитмеш яшькә җиткәнче чаңгыдан төшмәде.

Муса Гали шигырьләре

ЮГАЛТУЛАР ХАКЫНДА

Каз көткәндә онытылдым бермәл,
Алтын офыкларга күз атып.
— Аһ, нишлимен...
Кичер, әни, — дидем, —
Каз бәбкәсен кайттым югалтып.
Үтте, тынды сихри кыңгыраулар,
Мәктәп юлы белән мин кайттым.
Абайламый еллар урманында
Чәчүргечле кызны югалттым.
Утта көйде җаным.
Акты еллар
Яңгыр сибеп, яшен уйнатып,
Һәм әйттем мин:
— Ни кылыйм соң, әни,
Яшьлегемне кайттым югалтып.
Азмы затлар җирдә тәм таптылар,
Көмеш чишмәләрне болгатып.
...Кичер, әни, ялган өскә чыгып,
Дустымны мин кайттым югалтып.
— Нәрсәң калды бала?.. —
дигән сыман,
Бакты әни миңа тын гына.
Мәхәббәтем имин, намусым саф, —
Бар байлыгым хәзер шул гына.
Югалганнар инде кире кайтмас,
Югалырлык түгел болары;
Чү, кояшмы,
әни башы мәллә
Күтәрелде шулай югары.

ТӨП БАШЫНА...

Ярсый бүген, үрсәләнә дөнья,
Ярларыннан чыкты кара сулар.
Изгелекне нәфрәт кысрыклый,
Бизде мәллә кеше яратудан?

Сулдан уңга: **Муса Гали, Рәсүл Гамзатов, Мостай Кәрим, Виктор Боков. Переделкино. 1993 ел**

Ике атнадан мине төп корпуска күчерделәр, мин Мостай һәм Муса агалар белән көненә өч тапкыр коридорда, газета кибете каршында һәм, әлбәттә, ашханәдә күрешә башладым. Кичке аш яисә кино карар алдыннан язучылар Александр Серафимович бюст-сыны торган холл янындамы, яисә кышкы бакчадамы төркем-төркем җыйналып тора, аралаша, гәпләшә, Шәрык һәм Кавказ республикаларыннан килгән язучыларның барысы да Мостай Кәримне уратып ала иде, мин дә шул төркемгә кушылдым.

Көннәрдән бер көнне, караңгы төшкәч, ишегемне шакыдылар, ачсам — бусагада елмаеп Муса Гали басып тора, кулына минем юка гына тәүге китабымны («Полустанок Самсона») тоткан, мин аны, иҗат йортларының матур гадәте буенча, Малеевка китапханәсенә бүләк иткән идем.

— Якыннанрак танышасым килде әле, сине татар темалары борчуына шатмын, — диде ул.

Ул көнне без кичке ашка гына бүленеп алдык, дуслыгыбыз шул кышкы әңгәмәдә яралып шагыйрьнең үлеменә кадәр дәвам итте. Мин Уфада, аның өендә кунакта булгаладым, җәен без Пицундада, Ялтада күрешеп тордык. Еш хасталавына карамастан, Муса Гали бик актив кеше иде. Ул теплоходта бөтен дөньяны урап чыкты, Аурупаның барлык портларын, башкалаларын күрде, ә сәфәрдән әйтеп бетермәслек тәэсирләрдән тыш, аерым китап булып чыгачак бер бәйләм шигырьләр дә алып кайтты. Аның күзе — үткен, җаны — пакь, зәвыгы — нечкә иде, матурлыкны ул һәрвакыт тоя, күрә, сизә, аңлый белде. Икенче көнне ул мине Мостай Кәрим белән таныштырды. Һәм 1975 елдан алып 1991 елга кадәр Малеевкада, ә 1991 елдан алып 1998 елга кадәр Переделкинода — җәмгысе егерме биш ел! — мин шушы гаҗәеп кешеләр белән һәрдаим аралашып яшәдем. 1980 елда төзелешне ташлап, үземне баштанаяк әдәбиятка багышларга карар кылганнан соң, алар кебек үк, Иҗат йортларына икешәр срокка килә башладым. Без инде көненә өч тапкыр бер

өстәл артында утырдык, ә кичләрен, нигездә, минем бүлмәдә җыелыша идек. Бу мәҗлесләрдә нинди генә кызык әңгәмәләр тумады да нинди генә исемнәр телгә алынмады, нинди генә шигырьләр укылмады да нинди генә вакыйгалар сөйләнмәде! Ара-тирә, тамак чылатып алгач, җыр да яңгырый иде, әлбәттә. Тын гына утырган җирдән Мостай Кәрим: «Муса, әйдә, сузып җибәр әле», — дип сораса, Муса Галинең һич каршы килгәнен яисә киреләнгәнен хәтерләмим. Җанга үтеп җырлый, тавышы матур, белгән җырлары да күп иде — татарча, башкортча, украинча, дисеңме... Мостай ага да, Муса ага да — фронтовиклар, әңгәмә еш кына сугыш темасына да кереп киткәләде.

Муса Гали унсигез яшь тулар-тулмас фронтка китә, беренче көннәреннән үк алгы сызыкта хезмәт итә. Чандыр гына авыл малаена танкка каршы ата торган мылтык тоттыралар, шул корал белән сугышны башыннан ахырына кадәр уза. «Мин сул җилкәмнең гарип икәнлеген беләм, авырлык басып, аскарак төшкән ул, уң як белән чагыштырганда бу аерма күзгә бәрелеп тора, һәм, вакыт-вакыт, бигрәк тә төннәрдә, үтереп сызлый», — дип сөйли иде үзе. Көннән-көн онытыла барган сугышта биш-җиде грандиоз бәрелеш була, аларның һәрберсе мәгълүм, шулар арасында Днепрны кичү дә бар. 1943 елда алманнар ярны шулкадәр ныгыта ки, бу үрне яулау мөмкин түгел, дип ышаналар; ышанырсың да — елганың һәр карышы күз уңында, аяк очында гына, ә үзләре утырган як — бетон, бетон эченә дзотлар тутырылган. Муса абый Днепр аша ниндидер фәкыйрь генә салда йөзеп чыга, иңендә — коралы, аны югалту — баш бәясе тора. Йөзләгән, меңләгән кешене шушы сулар мәңгегә йотачак, аннан да күбрәген дошман пулясы кырып салачак, кемне чәрдәкләп үк атачак, елга кан төсенә кереп, төпкә җыелган мәеттән күтәрелгән, ташыган кебек тоелачак... Аның бригадасыннан

Урман аша узам. Җаным җылый,
Зират аша үтеп барам сыман.
Кабер ташы кебек төпләр, төпләр...
Тыным кыса, тәнем яна сыман.
Мине җәлләп ахры шунда бер төп
Кил, утырчы, диде, ымлап кына.
Утырдым мин шулай төп башына,
Тик мәгънәсен ачтым соңлап кына.
Төп башына! Әй, халкымның теле,
Күпме акыл, күпме кинаяләр!..
Минем хәлне күреп, кемдер көлә,
Көлмәгәннәр эчтән кинәнәләр.
Кинәнмәче, юләрләнмә, бәндәм,
Синеке дә бит ул шул ук төпләр.
Үлгән урман, кара көйгән гөлләр,
Синеке дә — агу сипкән күкләр.
Юләрләнмә. Безгә яшәү теләп,
Тик бер кояш калды көн кашында.
Мин генәме икән?
Әйләнәмә баксам —
Кешелек үзе утыра төп башында.

БҮГЕН ТӨНЛӘ ЯШЕН УЙНАДЫ

Бүген төнлә яшен уйнады,
Таудан-тауга шашып сикереп.
Ябырылган болыт явыннан
Үрә басты урман, җилкенеп.
Сабак укыды миңа шул урман —
Икеләнмә яшен алдында.
Йә тезлән син...
Йә чык алышка.
Яшәү дәртең булса каныңда.
Яшен ялмар, бәлки, мине дә...
Тик сыенып урын эзләмәм.
Тамчы каным тәндә калса да,
Мин тезләнмәм әле, тезләнмәм!
Дәһшәт уты мине өйрәтте
Икеләнмәскә вөҗдан алдында.
Ил хакына, җанны аямый,
Ялкыннарга каршы барырга.
Икеләнмәскә хаклык сагында,
Мәхәббәт дип утка кергәндә.
Сүнмәсен дип дусның учагы,
Учка салып күмер биргәндә.
Орынганда хәтәр тау-ташка,
Болытлардан чәчне сыйпатып.

Җылытканда хәлсез юлдашны,
Күкрәк белән җилне туктатып...
Бүген төнлә яшен уйнады.
Таудан-тауга шашып сикереп.
Икеләнмәскә!.. Рухым диңгезе
Кабатлады антын гү килеп...
Икеләнмәскә!.. Икеләнмәскә!..

е

Әй, кешенең йөрәк кыллары!..
Бөтен нәрсә сизелә кешегә.
Көннәр йончып китсә — сизелә.
Җир тетрәсә, ядрә ярылса,
Гүя, кыллар шартлап өзелә.
Зирәкләнде җаным. Дустыммы,
Дошманыммы бакса күземә,
Бер багудан күңел төбендә
Нәрсә ятулары сизелә.
Сары тамса яшел яфракка,
Гомер үтүләре сизелә.
Сызлый башлый иске яралар,
Һәм хәтердә еллар тезелә.
О, билгеле бары үземә,
Күпме җилләр бәрде йөземә.
Мәшәкатьтә, ыгы-зыгыда
Ару-талуларым сизелә.
Эремәс кар төште чәчләргә,
Йөрәгемнең тыны сизелә.
Аргамактай көн-төн ярсуда
Дөнья, дип, ул һаман өзелә.
Өзелсә дә, әйдә, өзелсен,
Куәт биреп соңгы сүземә.
Чыңлап китәр шунда күкрәгем,
Шулай булыр.
Шулай сизелә...

БАШКОРТСТАН ТАУЛАРЫ е

Әмирхан Еникигә

Талгын гына баеп барган кояш
Ирәндекнең үпте ташларын...
Онытыр төбәк җирдә бардыр ла ул,
Онытып кара Баймак якларын.
Акыл, хыял монда бер тамырдан,
Тормыш белән әкият — игезәк,
Үткәннәрдән безгә сабак укып
Асыл таулар ята җир бизәп.

бармак белән генә санарлык сугышчы исән кала. Яралы, контузияле Муса Гали, төннәрен кочаклап йоклаган, аның белән бербөтенгә әверелгән бу авыр мылтыкны кулыннан ычкындырмыйча, барыбер мәңге башбирмәс тоелган ярны буйсындыруга ирешә. Мөгаен, Украинаны, Днепрны шуннан соң яратып калгандыр ул. Әле дә ярый ул якларда хәзер нинди мәхшәр кубуын белми...

Муса Галине — Мостай Кәримсез, Мостай Кәримне Муса Галисез күз алдына китереп булмый; алар, туганнар сыман, гел бергә иде, бер-берсен тулыландырып яшәде, бер-берсенә нәрсә кирәклеген, бер-берсенең ни әйтергә теләвен сүзсез дә аңладылар. Икесе дә Башкортстанда туган. Икесе дә Уфада яши. Икесе дә башкорт әдәбиятына хезмәт итә...

Аңа кагылышлы тагын берничә детальне санап үтим. Муса аганың язу рәвеше (почерк) бик матур иде — язучы халкында сирәк күренә торган сыйфат бу. Төзәткәч, үзгәрткәч, яхшырткач, ул үз шигырьләренең чип-чиста итеп, төп-төз, тип-тигез хәрефләр белән яңа дәфтәргә — акламага күчерә. Их, ул вакытта хәзерге кебек каты тышлы, ак битле затлы дәфтәрләрнең булмавы! Нинди күркәм архив җыелыр иде! Шулай да, мин аңа бер-ике кыйммәтле язу кенәгәсе бүләк иттем, шагыйрьнең, бик ошатканга күрә, аларга иске шигырьләрен күчереп утырганын да үз күзләрем белән күрдем — шундый олпат язучыга кечкенә генә куаныч бирә алганыма мин әле дә ихлас куанам.

Мостай Кәрим, Муса Гали белән бик озак гомер хат языштык без, ул хатлар бүген туган ягымда — Казакъстанның Мартук бистәсендәге музейда саклана. Без һәрдаим Иҗат йортларында, Мәскәүдә, Уфада, Казанда очрашу урынын-вакытын язмача килешә идек, бәхеткә күрә, бергә төшкән фотографияләр дә бихисап — алар барысы да, альбом-альбом булып,

әле телгә алынган музейда җыйналган. Шуның белән шул: миңа да нәтиҗәләр, йомгак ясарга вакыт якынлаша, киләсе буыннар хәтта Казакъстанның ерак Мартугында да ике күренекле татар-башкорт шагыйре турында материаллар барлыгын белеп торсын, дим.

Мин 1990 елда Үзбәкстаннан Россиягә күчендем дә 1998 елга кадәр гаиләм белән Переделкино Иҗат йортында (106 нчы бүлмә) гомер кичердем. Шушы сигез ел буе бирердә дә күрешеп-очрашып тордык без. Аңарчы заманалар үзгәреп, дөньялар буталып, Малеевканы сатып җибәргәннәр иде инде. Юк ул хәзер! Мостай Кәрим белән Муса Галине хатыным да, үзем дә һәрвакыт ачык йөз илә каршыладык, алар Переделкинога ахыргача — аяклары йөргәнче, биредәге йортлар йөзен югалтканчы килеп йөрде. Еш кына яныбызга Әмирхан ага Еникине дә дәшеп, әңгәмәләребез яңа төсләр, яңа мәгълүматлар, яңа язмышлар белән байый иде. Татар-башкорт әдәбияты турында шушы күрешүләрдән туплаган гыйлемем институт курсына (аспирантура белән бергә) тиң булгандыр.

Каләм ияләре — кытыршы халык. Араларында, билгеле, әче телләнүчеләр дә юк түгел: һи, Рауль, дисез, аның бар эше — Муса Гали белән Мостай Кәримнең чемоданнарын ташып йөрү булды бит, янәсе. Ни әйтим? Мин шундый зур шәхесләр белән таныш булуым һәм аралашып яшәвем белән чиксез горурланам. Аларга һәрдаим ярдәмләшергә тырыштым, әйе. Файдамны күрделәр икән, әйтеп бетергесез канәгатьмен! Андый затлар белән күрешеп-сөйләшү — җан ләззәте иде. Бүген минем үземә дә җитмеш яшь инде, ләкин, хөрмәтле абыйларым исән булса, бик теләп, һич иренмичә, аларга яңадан чәй пешерергә, суыткычны бушатырга һәм кулдан килгәнчә табын җәяргә ашыгыр идем. Чирек гасыр дәвам иткән мондый бәхет һәркемгә тәтеми. ■

Сабантуйга без дә килдек әле…
Син бик өлкән, мин дә яшь түгел.
Сабантуйлар өчен гомер нәрсә,
Бар бит әле бездә яшь күңел!
Атлыйсың да, бу нинди тау, дисең,
Бу үзәндә, дисең, ниләр бар.
Атайлардан калган асыл мирас —
Озыннардан озын көйләр бар.
Шул көйләргә күптән син мөкиббән…
Йөрәгеңә моңнар уралсын.
Аларда бит катлы-катлы тарих,
Көйләрсең дә уйлар уйларсың.
Атлыйсың да, бу нинди тау, дисең,
Бу үзәндә, дисең, ниләр бар.
Чал дөньяның кырыс җилләреннән
Йөрәкләрдә калган җөйләр бар.
Үзгәрер бу дөнья, тик яман көч
Кул якмасын җирнең төсенә.
Син тауларга бактың, ә мин сиңа,
Сиңа бактым — таудай кешегә.
Тауларыма карап хәйран булдың…
Уралмыни сиңа ят төбәк?
Кояш баеп бара. Син көйлисең
Әллә әкият, әллә васыять.

Ярларыннан чыккан чая елга
Ул мин идем —
ташкын, диделәр.
Күкне ялмап янган ал ажаган
Ул мин идем —
ялкын, диделәр.
Ташны ташка бәргән хәтәр гайрәт
Ул мин идем —
давыл, диделәр;
Булды кайчак: авырымны — җиңел,
Җиңелемне — авыр, диделәр.
Барысын да үзем генә беләм,
Белә булыр Днепр ташлары…
Минем каннан шыткан гөлләр анда
Һаман үсә чайкап башларын.
Мин бәхетле булыр идем,
Җирем,
Еллар аша үргә менгәндә,
Ялкын күреп мине телгә алса,
Хәтерләсә давыл килгәндә. ■

100 МЛН



Татарстан Республикасы Президенты
УКАЗЫ

Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итү турында

Татарстан Республикасының икътисади һәм социаль үсешендә нефть һәм газ чыгару тармагының, Лениногорск шәһәренең зур роль уйнавын билгеләп, карар бирәм:

1. 2015 елда Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итәргә.

2. Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга (кушымтада бирелә).

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына өч ай эчендә, аларны үткәрү вакытларын, җаваплы башкаручыларны, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп, Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм аны уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Лениногорск шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ачык акционер җәмгыятенең «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оешуга 70 ел тулуны бәйрәм итүне киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты **Р.Н.Миңнеханов**

Казан, Кремль,
2014 ел, 01 сентябрь
№ ПУ - 830

ШӨГЕР ЯГЫ – КАРА АЛТЫН ИЛЕ

(тарихи-документаль очерк)

Гәрәй Рәхим,
Татарстанның халык язучысы

Иске Шөгер авылы басуындагы 1-нче скважина. 1943 ел

ЮЛ БАШЫ

1945 елның 30 маенда, СССР нефть промышленносте халык комиссары чыгарган 244 нче әмер нигезендә, Советлар Союзының нефть җитештерү Баш идарәсе 146 нчы карары белән, Татарстан АССРның Шөгер районындагы Иске Шөгер авылында 1945 елның 27 июленнән «Шөгер эреләндерелгән нефть промыселы» оештырылуын игълан итә. Бу — Татарстанда нефть эзләү, җитештерү һәм эшкәртү эшләренең дәүләт күләмендәге нигез ташы, ягъни тора-бара Россиядә, СССРда һәм бөтен дөньяда дан алган татар нефтенең беренче башлангычы була. Бүгенге атаклы «Татнефть» Ачык Акционерлык Җәмгыятенең, аның нефть һәм газ җитештерү идарәләренең (НГДУ), татар нефтенең башкаласы Әлмәтнең, нефть эзләү, табу һәм эшкәртү эшендә гаять зур уңышларга ирешкән Лениногорск, Бөгелмә, Баулы, Азнакай, Алабуга, Минзәлә, Түбән Кама, Зәй, Сарман (Җәлил бистәсе), соңрак Норлат, Чирмешән, Әгерҗе, Мөслим, Актаныш һәм рес-

Шөгер эреләндерелгән нефть промыселы. 1946 ел

3 нче скважина девон нефтен күккә чөйде! 1948 елның 26 июле

1971 ел

Һәр төбәкнең табигый байлыгы – табигый мирасы, аларны халык тормышында файдалану борын-борынгыдан шушы төбәктә яшәгән абориген халыкларның тормыш-көнкүреш тарихы белән тыгыз бәйләнгән.

публикабыздагы башка төбәкләрнең данлы нефть тарихы минем туган **Федотовка** авылыннан 18 чакрым гына көньяктарак булган шушы кечкенә генә **Иске Шөгер** дигән татар авылыннан башланып китә.

Әмма бу урында шунысын да әйтеп китү кирәк булыр — безнең һәм бөтен Рәсәйнең нефть эше галимнәре, тарихчылары, журналистлары һәм сәясәтчеләре үз китапларында, мәкаләләрендә, чыгышларында еш кына Россиядәге нефть тарихының чишмә башы бүгенге «Лениногорскнефть» НГДУсына кергән әлеге Иске Шөгер авылы булуын, аның татар нефте тарихының беренче нигез ташы икәнен «оныталар», сүз сөрешләрендә аны искә алмыйча гына узып китәләр.

Ниһаять, татар нефтенең дәүләт күләмендә башланып китүенең төп сәбәпчесе булып Шөгер төбәгендә нигез салынган «Лениногорскнефть» НГДУсына — 70, шушы нефть сәнәгате барлыкка китергән Лениногорск шәһәренә — 60 ел тулган олуг бәйрәм көннәрендә моңа ныклап игътибар ителер, дип ышанасы килә.

Әйе, Татарстан нефтен чыгарып СССРның сәнәгати җегәрен бик нык күтәреп җибәргән урын — территориаль яктан Шөгер төбәге, дәүләт дәрәҗәсендәге нефтьчелек эшен беренче башлап җибәрүчеләр нигездә Шөгер районы кешеләре иде.

Хәлбуки, Шөгер якларында нефть эше дәүләт дәрәҗәсендә инде Бөек Ватан сугышы башланып ике атна үткәч, ягъни 1941 елның июлендә (нәкъ мин туган көннәрдә!) Иске Шөгер авылы басуындагы 1нче скважина җирне бораулый башлаган, аннан тәүге мәртәбә 1943 елның җәендә тәүлегенә 20 тон-

Беренче номерлы скважина

на нефть биргән көннән, аннан да алдарак, 1938 ел азагында (моннан 77 ел элек!) бу авылга беренче нефть эзләүчеләр килгән көннән башлана. Авылның аксакалы **Мингалим** бабай ялан кырга нефть эзләргә килүчеләрне үз өендә фатирда тота.

Татарстан нефтен башлап җибәрүчеләрнең күбесе — элеккеге Шөгер районы кешеләре. Шулардан җидесе — Иске Шөгер авылыннан **Зиннәт Шәрифуллин** һәм **Фәсхетдин Шәрәфетдинов**, Сугышлы авылыннан **Җәлил Зәйнагов** һәм **Шакир Галиев**, Тимәш авылыннан (1935 елга кадәр ул да Шөгер районына керә иде) **Әхәт Гобәйдуллин**, Яңа Елховой авылыннан **Мәсгут Миңнекәев** һәм Ормышлы авылыннан **Ядкәр Ваһапов** СССРның тыныч хезмәттәге иң зур бүләге **«Социалистик Хезмәт Герое»** дигән олуг вә мәртәбәле исемгә һәм алтын медальгә лаек булдылар. Нәни генә район өчен бу бик зур күрсәткеч, әлбәттә.

Ниһаять, борынгы татар язма әдәбиятына нигез салган шагыйрь **Кол Галинең «Йосыф кыйссасы»** әсәрен беренче мәртәбә фәнни эшкәртеп 1839 елда ук Казанда аерым китап итеп бастырып чыгарган күренекле татар шагыйре **Утыз Имәни** яшәгән **Тимәш** авылында, шагыйрь өеннән ерак та булмаган тау битендә, атаклы **Ромашкино** нефть чыганагын ачып җибәргән 3нче скважина 1948 елның июлендә девон ятмасындагы нефтьне көчле фонтан итеп күккә чөя. Ул тәүлегенә 120 тонна нефть бирә башлый һәм СССР нефть промышленностенда иң зур рекордлы скважина була. Чагыштырып кына карагыз: Шөгер авылы янындагы беренче скважина 1943 елда тәүлеккә 20 тонна нефть биргән булса, нибары биш елдан соң Ромашкино ятмасының 3 нче скважинасыннан инде тәүлеккә 120 тонна, ягъни 6 тапкыр артык нефть чыга башлый! **«Лениногорскнефть» НГДУ**сының горурлыгы булган бу скважина Татарстан Республикасында нефть чыгару эшенең гаять тиз һәм

«Лениногорскнефть» НГДУсы җитәкчесе Рафаил Сәет улы Нурмөхәммәтов

киң колачлы булып үсеп китүенә нигез сала. Шунысы игътибарга лаек, Иске Шөгердәге 1нче скважинада да, Ромашкино ятмасындагы атаклы 3нче скважинада да бораулаучылар җитәкчесе Шөгер районының 1нче скважинадан ерак та булмаган Спиридоновка авылында туып-үскән **Сергей Кузьмин** була. Ул 16 яшеннән алып гомере буе нефть чыгару эшендә эшли.

Бүгенге көндә «Лениногорскнефть» нефть һәм газ табу идарәсе **«Татнефть»** берләшмәсендәге иң өлкән һәм иң уңышлы эшләүче НГДУларның берсе.

70 ел эчендә «Лениногорскнефть» идарәсе оештыру өлкәсендә шактый үзгәрешләр кичерде. 1945 елда **«Шөгер эреләндерелгән нефть промыселы»** дигән исем белән хезмәт юлын башлап җибәргән идарә 1950 елдан 1961 елга кадәр **«Бөгелмәнефть»** тресты составына кертелде һәм төрле исемнәр белән аталып йөрде. 1961 елдан 1970 елга кадәр аны **«Лениногорскнефть» нефть промыселы идарәсе»** дип йөрттеләр. Хәзер ул горур рәвештә «Лениногорскнефть» НГДУсы — нефть һәм газ табу идарәсе дип атала.

70 ел эчендә җитәкчеләре дә бай-

так алышынды — аларның барысы 15кә җыела. Шөгер ягы һәм Лениногорск нефтьчеләре аларның һәрберсен олы хөрмәт белән сагынып искә алалар, чөнки барысы да илгә мул итеп нефть чыгару максаты белән бергә, һәр нефтьченең эш һәм яшәү урынын яхшырту, аларны мәдәни, мәгариф, көнкүреш, спорт өлкәләрендә якыннан катнаштыру өчен бөтен көчләрен дә куйган җитәкчеләр.

1989 елдан идарә белән **Рафаил Сәет улы Нурмөхәммәтов** җитәкчелек итә. Ул бөтен хезмәт гомерен нефть эшенә багышлаган — 1974 елда Уфа нефть институтын тәмамлаганнан соң, **«Татнефть»** берләшмәсенең **«Сөләйнефть»** НГДУсында нефть һәм газ табу буенча оператор булып эшли. Шулай ук **«Җәлилнефть»** НГДУсы начальнигы, көнбатыш Себер нефть оешмаларында җитәкче була.

Рафаил Сәет улы һәр эшне җиренә җиткереп, намус белән башкара. Хезмәттәге уңышлары өчен ул Россия һәм Татарстанның орден-медальләре белән бүләкләнә, «Россиянең нефть һәм газ промышленностеның атказанган хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була. Республикабызның күренекле нефтьчесе — Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе лауреаты, техник фәннәр кандидаты.

Шулай итеп, Татарстан нефть оешмаларының иң өлкәне, аларның нигез ташы булган данлы «Лениногорскнефть» идарәсе, катлаулы, киң колачлы, гаять зур фидакяр хезмәт сорый торган көндәлек тормыш юлы үтеп, үзенең 70 еллык юбилеен бәйрәм итә. Бу идарә хезмәтчәннәрен бүген бөтен республикабыз халкы, Россия Федерациясенең нефть промышленносте җәмәгатьчелеге олуг юбилей белән чын күңелдән котлыйлар.

***

Татарстанның Лениногорск районы һәм шәһәре чагыштырмача яшь — алар узган гасырның 50-60 нчы елларында бу якларда гөрләп үсеп киткән нефть табу һәм җитештерүнең дөньякүләм дәрәҗәгә күтәрелеше нигезендә төзелделәр. Ул чакта тарихи яктан искиткеч кызыклы территориаль берәмлек булган Шөгер районы, бетерелеп, яңа төзелгән Лениногорск районы биләмәсенә бирелде.

Лениногорск шәһәре һәм районы үзенең оештырылган көннәреннән үк, ягъни менә инде 60 ел дәвамында Татарстан республикасының сәнәгать һәм рухи тормышында ил-көнгә сизелерлек уңышлы эшләр башкарып килә. Әле совет һәм коммунистлар җитәкчелеге елларында ук иҗтимагый һәм сәяси хезмәтләрен Лениногорскида башлап җибәргән күп кенә шәхесләр Татарстан хөкүмәте, партиянең өлкә комитеты, комсомолның Татарстан оешмаларында зур-зур дәрәҗәле җитәкчеләр булдылар. Лениногорск шәһәре һәм районы җитәкчеләре әле бүген дә бу күркәм традицияне дәвам итәләр.

Бу уңайдан хәзерге Лениногорск муниципаль районы хакимияте башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры **Рәгать Галиәгъзам улы Хөсәеновның** заманча эшчәнлеген аеруча уңышлы дип билгеләп үтәсе килә. Ул милли яктан бик чуар, төрле-төрле диннәргә инанып яшәүче, чын шәһәрчә генә һәм чын авылча гына тормыш алып баруны алга сөргән Лениногорск районы һәм шәһәре халкының бер максатка, бер гаиләгә тупланып яшәве, уртак хезмәт, уртак рухи тигезлек белән гомер итүләре өчен бөтен көчен куя һәм бу олы максатка ирешә дә. Бүген Лениногорск районы һәм шәһәренең Татарстанда күренекле яшәү рәвешенә ирешкән матур төбәк булуы әнә шул турыда сөйли.

Лениногорск районының күркәм Шөгер ягы, ягъни элеккеге Шөгер районы Татарстанның икътисади һәм мәдәни тарихында тирән эз калдырган төбәк иде.

Һәр төбәкнең табигый байлыгы — табигый мирасы, аларны халык тормышында файдалану борын-борынгыдан шушы төбәктә яшәгән абориген халыкларның тормыш-көнкүреш тарихы белән тыгыз бәйләнгән. Монда яшәгән төрле-төрле милләт, кавем, халык тормышы — безнең, бүгенге буын кешеләренең изге тарихы. Бу тарихны без мәңге онытырга тиеш түгелбез! Шушы хакыйкатьне искә алып һәм аңа хөрмәт йөзеннән мин туган Татарстаныбызны данлаган, аны матди һәм рухи биеклекләргә күтәргән нефтьчелек эшенең элгәре булган Шөгер ягының тарихи әһәмиятле ике генә өлкәсенә кагылып үтәсем килә. Алар нефть һәм мәдәният.

НЕФТЬ

Татарстанның бүгенге сәнәгати үсешендә, һичшиксез, нефть табу, җитештерү һәм эшкәртү иң мөһим, иң әһәмиятле урынны алып тора. Нефть — безнең Татарстанны бөтен дөньяга танытуда, Россиядә иң җегәрле республика дәрәҗәсенә ирешүдә, авылларыбыз, бигрәк тә шәһәрләребезнең Рәсәйнең башка төбәкләре белән чагыштырганда, ныклы тормышта яшәүләренә төп нигез.

Алда әйткәнемчә, Татарстан җирлегендә әнә шушы «галиҗәнап» нефть тарихының чишмә башы, аның халык тормышында кулланылышы, Татарстаныбызга һәм элеккеге СССРга нефтьне сәнәгати нигезләрдә бирә башлау эше нәкъ менә Шөгер ягында башланды.

Билгеле ки, нефть тышкы халәте ягыннан өч төрлегә бүленә: сыек нефть, куе нефть, каты нефть (битум). Кулланылыш ягыннан исә нефть ике төрле — халык арасында көнкүрештә куллану һәм дәүләт дәрәҗәсендә сәнәгатьтә куллану.

Туган Татарстаныбызда әлеге өч төрле халәтле нефтьнең иң беренче табылу, җир өстенә чыгару, аларның көнкүрештә һәм дәүләт күләмендә

2 млн тонна нефть табу уңаеннан Лениногорск НГДУсында оештырылган тантана делегатлары

җитештерелә башлау тарихы нәкъ менә Шөгер төбәге белән бәйле.

Мин үз күзем белән күргәннәргә таянып мисаллар китерәм:

Элеккеге Шөгер районының **Сарабиккол (Әби)** авылында **Шушма** елгасы ярына якын гына бер чишмә бар. Әби авылыннан өч кенә чакрым ераклыктагы минем туган авылым **Федотовка** (борынгы **Ана** авылы) керәшеннәре һәм тирә-яктагы башка авыл кешеләре бу чишмәне «Кара чишмә» дип йөрттеләр. Ни өчен? Чөнки бу чишмә суы белән җир астыннан бармак бите кадәр генә куе кара төстәге майлы сыекча таплары агып чыга иде. Бу майлы сыекча судан җиңел булу сәбәпле, гел су өстендә генә тора. Чишмәдән берничә адым гына түбәнрәк калын такталардан ясалган зур улак бар. Чишмә суы улакның өстеннән агып керә дә, аргы баштагы төбенә ясалган тишектән агып чыгып китә. Ә теге майлы кара таплар, суга бата алмыйча, улак өстендә кала. Шулай итеп, улакка кап-кара сыекча җыела. Авыл кешеләре дегет чиләкләре, махсус мичкәләр, чапчаклар белән киләләр дә, улак янындагы махсус ясалган озын саплы чүмеч белән сөзеп, әлеге кара майны җыялар. Кара майны Сарабиккол кешеләре генә түгел, ә тирә-яктагы унлап авыл кешеләре килеп җыя.

Һәр гаиләдә җигүле аты булган авыл кешеләре бу сыекча белән арба күчәре майлыйлар иде. Кара чишмәдән чыккан кара сыекча белән майланган арба тәгәрмәче бик җиңел тәгәри. Бу кара май белән яңа өй, мунча, каралты-кура төзегәндә нигезгә куела торган беренче ниргә бүрәнәне дә буйыйлар — ул аны мәңге черетми. Майны хәтта ветеринариядә дә кулланалар иде. Җәйге эссе көннәрдә сыерларның арты кортласа, шул майны сөртәләр — кортлар шундук юкка чыга.

Кара чишмәдәге кара майны кешеләр кайчан файдалана башлаганны беркем дә хәтерләми. Мөгаен, ул чишмә типкән көнне үк башлангандыр, бәлки бераз соңрактыр. Һәрхәлдә, бу кара майның, ягъни сыек нефтьнең моннан берничә дистә гасырлар элек үк кешеләр тарафыннан файдаланыла башлавына шик юк.

Шуңа таянып без, Татарстанда сыек нефтьнең җир астыннан үз агымы (самотек) белән чыгуына һәм аны кешеләрнең көнкүрештә куллана башлавына берничә дистә гасырлар вакыт узган һәм ул нәкъ менә Шөгер ягына бәйле, дип раслый алабыз. Журналистлар, галимнәр, нефть белгечләре Татарстанда нефть табылу һәм куллану тарихын ни өчен менә шуннан башламыйлар?! Мин моңа гаҗәпләнәм...

Алда әйткәнебезчә, сыек нефтьне табу һәм җитештерүне дәүләт күләмендә алып бару тарихы да Шөгер ягында башлана. 1944 елны Иске Шөгер авылы янында беренче буровой эшкә керешә, нефть күпләп табыла башлагач, аны хәзерге **Самара** өлкәсенең **Келәүле** станциясендәге тимер юл цистерналарына төяп, СССРның төрле төбәкләрендәге нефть эшкәртү заводларына озаталар. Шулай итеп, Татарстанның нефть сәнәгатенә беренче мәртәбә Шөгер ягында нигез салына.

Инде килик куе нефтькә.

Элеккеге Шөгер районының әлеге Сарабиккол авылыннан берничә чакрым гына көньяктарак **Карамалка** дигән мордва (мукшы) авылы бар. Бик борынгы заманнарда ук шушы авыл читендә, утырган бал сыман куе, ләкин кап-кара төстәге матдә тулган кечерәк бер күл булган. Бу матдә, артык куе булу сәбәпле, арба майларга ярамаган. Шулай да тирә-яктагы авыл кешеләре аны көрәкләр белән каерып алып, капка баганаларының җир астына күмелә торган өлешләрен, йорт-кураның нигез ниргәләрен буяганнар.

Майлы күл нефтьче галимнәрне дә кызыксындырган. Бөек Ватан сугышы алдыннан ук монда Казан Дәүләт университетыннан бер төркем галим-геолог килеп тикшеренүләр уздыра. Шунда алар күл эчендә иң борынгы җәнлек,

кош сөякләрен табып алалар. Кара бал (куе нефть) эчендә яткан сөякләр черемичә шулкадәр яхшы сакланганнар ки, галимнәр, аларны җыеп, Казанга алып кайталар. Бүгенге көндә КФУның геология музеенда бу кап-кара төстәге сөякләр белән танышырга мөмкин.

Патша хөкүмәте яңа чукындырылган мукшыларны Карамалка авылына XVIII гасырның 70нче елларында күчереп утырта. Аңа кадәр биредә Сарабиккол татарлары яшәгән һәм авыл Карамал Сарабикколы дип аталган. Карамал сүзенең килеп чыгышы әлеге кара күл белән бәйле түгел микән — «Кара мал», ягъни кара төстәге мал, көнкүрештә файдаланырлык байлык!

Соңгы елларда Татарстан нефтьчеләре куе нефтьнең Карамалка ятмасы белән бик нык кызыксына башладылар. Аның киләчәге бик зур, диләр, чөнки мондагы җир астында куе нефтьнең гаять зур запасы ята икән. Ләкин аны җир өстенә чыгару әмәле дә катлаулы.

Әмма монысы инде икенче мәсьәлә. Күргәнебезчә, Татарстанда куе нефтьне файдалану, аны чыгару тарихы да нәкъ менә Шөгер ягында башлана!

Ниһаять, нефтьнең өченче төре — каты нефтькә (битумга) килеп җиттек. Битумны табу, җитештерү һәм файдалану тарихы шулай ук Татарстанда, нәкъ менә Шөгер җирендә башлана.

1881 елда Шөгер якларына нефть эзләргә дип килгән Америка эшмәкәре **Л.Шандор** Шөгер авылы читендә кечкенә генә гудрон заводы салдыра. Заводка чимал чыгару өчен авыл янындагы текә тауны (хәзер аны авыл халкы **«Шандор тавы»** дип йөртә) тишеп шахталар ясыйлар һәм тау эчендәге гудрон (битум) чималын заводка ташу эшен җайга салалар. Шуннан башланган битум заводы йөз елдан артык Россиянең төрле төбәкләренә кыйммәтле битум җибәреп торды. Аны көне-төне Шөгердән Бөгелмә тимер юл станциясенә ташып, илнең төрле төбәкләренә озаталар иде.

Әлеге риваять раславынча, бер ат өере хәзерге Бәкер авылы янындагы күкертле күлгә кереп коена торган була. Карасаң, күпмедер вакыт үткәч, әлеге атлар ханның гаскәри атларыннан да тизрәк, көчлерәк, чосрак булып кырда чабып йөриләр икән!

Нефтьчеләрнең соңгы еллардагы эзләнүләре нәтиҗәсендә Карамалка ятмасында куе нефть белән бергә каты нефтьнең (битум) зур запаслары бар икәне ачыкланды. Димәк, бу якларда битум җитештерүнең дә зур киләчәге күренә.

Шулай итеп, Татарстанда каты нефть (битум) чыгару һәм файдалану эшенең дә чишмә башы, тарихы Шөгер ягыннан башлана икән.

Күренә ки, Татарстан җирендәге сыек, куе, каты нефть табу һәм файдалану тарихларының өчесе дә турыдан-туры Шөгер ягы белән бәйле. Нефть хакында язучы журналистлар, нефть тарихын өйрәнүче фәнни-тикшеренү институтлары галимнәре, Татарстан нефте өлкәсендә эшләүче җитәкчеләр, белгечләр, мөгаллимнәр колагына киртләп шуны әйтәсе килә: Татарстанның нефть тарихы моннан берничә дистә (бәлки йөз!) гасырлар элек хәзерге Лениногорски районының Шөгер төбәгендә, аның да Сарабиккол (сыек нефть), Карамалка (куе нефть) һәм Иске Шөгер (каты нефть) авылларыннан башланып китә.

***

Татарстан нефте үзенең составы белән Россиянең һәм дөньяның башка төбәкләрендә чыгарыла торган нефтьтән бик нык аерыла. Эш шунда ки, татар нефте составында күкерт бик күп. Шөгер якларында әлеге күкерт нефть составында гына түгел, кайбер чишмәләрдә һәм сазлыклы болыннарда ләм рәвешендә үзе генә дә җир өстенә бәреп чыга.

Әйтик, Сарабиккол авылындагы чишмә суы белән җир өстенә нефть тамчылары бәреп чыкса, Шөгер тирәсендәге кайбер чишмәләрдән күкертле су агып чыга.

Әнә шундый урыннарның берсендә Россиядә һәм Татарстанда атаклы дәвалану үзәге — **Бәкер курорты** эшли. Курорт Яңа Шөгер авылы янындагы атаклы Шандор тавының аръягындагы итәгендә, борынгы татарлар нигез салган Бәкер авылына терәлеп үк тора. Курорт янында күкерткә бай зур бер ләмле болын җәелеп ята, аңа күкертле чишмәләр агып төшә.

Әлеге күкертле чишмә суларын һәм күкертле ләмне бу як авылларында яшәгән кешеләр борынгы заманнарда ук төрле авыруларны дәвалау өчен файдалана башлаганнар. Әйтик, Бәкердән 8 генә чакрым төньяктарак урнашкан туган авылым Федотовка янында бер күкертле чишмә артык зур булмаган болынга агып төшә һәм анда күкертле ләм хасил итә. Авыл картларыннан ишетүемчә, безнең авыл кешеләре бу ләм һәм күкертле чишмә суын борынгы заманнарда ук тән сызлавын басу өчен куллана торган булганнар. Әле мин бәләкәй чакларда да (узган гасырның кырыгынчы-илленче еллары) безнең авыл кешеләре җәй көннәрендә бу ләмне зур капчыклар белән, күкертле чишмә суын мичкәләр белән ат арбасына салып авылга алып кайталар һәм яшел чирәмле ишегалдына алдан ук кеше сузылып ятарлык итеп эшләнгән зур тагаракларга салалар, ләм һәм су кояш күзендә җылынып беткәч, анадан тума чишенеп, шунда кереп яталар иде. Авылдашларым шушы ысул белән бил һәм муен хандрозын, кул-аяк сызлауларын, йөрәк өянәкләрен дәвалыйлар иде.

Бәкер курорты хәзер нәкъ шушы ысулны фәнни нигезләрдә файдалана, күкертле ләм һәм күкертле чишмә суларын сәламәтлек саклауның төрле өлкәләрендә файдалану алымнарын киңәйтә, күкертле суның иң файдалы өлешләрен генә аерып, **«Бәкер суы»** дигән шифалы суны күпләп чыгара һәм илебезнең төрле төбәкләренә тарата.

Бүгенге көндә Бәкер курортында чит илләрдән, Россиянең төрле төбәкләреннән, Татарстаннан килгән 15 мең ял итүче ел дәвамында файдалана һәм дәвалана.

Бәкер ләме һәм күкертле чишмә суының шифалы икәне халыкка берничә йөз гасырлар элек үк билгеле була. Шунысы кызык, бу турыда борынгы ногай татарларының бер риваяте безнең көннәргә кадәр сакланып калган. Анда әйтелгәнчә, хан җитәкчелек иткән атлы гаскәрдә шундый тәртип була — җайдаклы хәрби гаскәрдә озак еллар хезмәт иткән, инде катлаулы хәрби эшкә ярамый торган карт атларны, табигый үлемнәре белән вафат булсын өчен, табигатькә, ялан кырга чыгарып җибәрә торган булганнар. Үзбәкләрдә әле хәзер дә картаеп эшкә ярамый башлаган ишәкне үз үлеме белән үлсен өчен далага куып чыгаралар.

Иркен табигатьтәге «ветеран» атлар, бер-берсен табып, ат өере хасил итәләр һәм иректә үзләре теләгән бөтен үсемлек белән сыйланалар, эссе көннәрдә кыргый күлләрдә коеналар.

Әлеге риваять раславынча, бер ат өере хәзерге Бәкер авылы янындагы күкертле күлгә кереп коена торган була. Карасаң, күпмедер вакыт үткәч, әлеге атлар ханның гаскәри атларыннан да тизрәк, көчлерәк, чосрак булып кырда чабып йөриләр икән! Җайдаклы гаскәр башлыгы, моны күреп, әлеге атларны яңадан арканлы корыклар белән тотып, хәрби атлар төркеменә куша. Күкертле күлдә коенып, тәннәренә вә әгъзаларына шәп дәва алган бу атлар алдагы сугышларда һич тә сынатмыйлар. Дөрестерме, юкмы, әмма халык күңелендә сакланган әлеге риваять күкертле суның никадәрле дә шифалы икәне турында сөйли. Ә аның рәсми хакимият тарафыннан раслануы 1880 елларга карый. Шушы елны Рәсәй хакимияте тарафыннан Бәкер авылы янәшәсендә казна карамагындагы зем-

ство хастаханәсе салу мәсьәләсе куела. Әмма дә бу мәсьәлә, ул чактагы бик «белдекле» кешеләр тарафыннан төрле хәрам гамәлләр оештырылу аркасында, төзелми кала.

Шулай да, урыслашкан поляк һәм француз тоткыннары төзегән **Иске Куак** авылы янындагы элеккеге земство хастаханәсендә XX гасыр урталарында баш табип булып эшләгән күренекле врач **Игнатьев Максим Игнатьевич** узган гасырның 30-50нче елларында Бәкер авылы янындагы күкертле ләм һәм чишмә суының гаять шифалы икәнен Татарстан җитәкчеләренә дә исбатлый һәм 1932 елда Бәкергә Мәскәү сәламәтлек саклау белгечләрен чакырып, аларны монда курорт төзергә кирәклегенә ышандыра. Шул елны ук Максим Игнатьевич Бәкер авылы читендә нәни һәм гади генә биналар салып, анда тән сызлау белән чирләүче 8 кешене дәвалый.

Хәзер Бәкер курортының башланып китүен шушы 1932 елдан исәплиләр. Әмма минем шәхси карашымча, Бәкер тирәсендә шифаханә төзү зарурлыгының дәүләт тарафыннан танылуы 1880 елда икәнлеген искә алып, бүгенге курортка дәүләти-язма нигез салынуын һәм аның рәсми тарихын 1880 елдан башлап китү дөресрәк булыр иде. Шулай булганда Бәкер курортының рәсми-дәүләти тарихына быел 63 ел гына түгел, ә 135 ел тулган булыр иде! Кызганыч, бу юбилей елы бүген беркемне дә кызыксындырмый. Дөрес, соңгы елларда матбугатта басылган чыганакларда Бәкер курорты белән Бәкер авылы төзелгән 1700нче елларны берләштерү күздә тотыла. Әмма, минемчә, әле авыл төзелү белән үк анда күкертле ләм һәм су белән дәвалану башланып китә алмый. Авылның ялан кыр уртасында төзелә башлавы үзе үк гаять мәшәкатьле эш — һәркемгә торак йорт булдыру, чирәм җирләрне үзләштереп һәм урманнарны төпләп икмәк басуы ясау, авылны утын, су белән тәэмин итү, каралты-кура төзү, мал-туар асрау һәм аларга печәнлекләр булдыру, әлбәттә, дистә, йөз елларга сузылырга мөмкин. Ә менә 1880 елда инде мондагы ләм һәм күкертле суның файдасы, дәүләтнең фәнни оешмалары тарафыннан раслана, һәм Бәкернең сәламәтлек саклау үзәге булып оешуына нигез сала. Аның тарихын шушы 1880 елдан башлап китү генә реаль дата була алачак, дип уйлыйм.

Бәкер курорты биналарына нигез салган атаклы табип Максим Игнатьевичны мин күреп тә белә идем. Безнең авылдан 5 кенә чакрым ераклыкта булган Иске Куак авылы читендә патша заманында ук төзелгән һәм Максим Игнатьевич җитәкләгән, ул чор өчен бик зур булган хастаханә бөтен тирәяк авылларга, шул исәптән безнең авылга да сәламәтлек саклау хезмәте күрсәтте. Мин үзем берничә мәртәбә бу хастаханәдә ятып чыктым, мине дәвалаучы Максим Игнатьевичның хатыны, шулай ук күренекле табибә иде.

Максим Игнатьевич белән минем әти, **Родионов Василий Семёнович** Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда бик якын дуслар иде. Әтием безнең авылда урнашкан һәм районда бердәнбер булган «2нче бишьеллык» исемендәге промышленность товарлары җитештерү артеленең рәисе булып эшләде. Бу промартель авылдагы **«Алмаз»** колхозыннан да бай һәм җегәрле иде, аның рәисе булган минем әти районның партия һәм хуҗалык җитәкчеләре һәм күренекле кешеләре арасында яхшы билгеле шәхес булды. Әтием белән Максим Игнатьевичның якын дуслыгы күренекле табибның вафат булуына кадәр дәвам итте.

Бу дуслыкның матди нигезе дә булмады түгел. Дәүләт хастаханәләре бюджет акчасына гына карап торалар һәм матди яктан шактый ярлы яшиләр иде. Ә безнең әти артельдә җитештерелгән арба, чана, тәгәрмәч, тәртә, дуга, мебель, каен дегете, агач күмере, чыпта, аркан, эшкәртелгән юкә кебек

Бәкер ул – хозурлыкның мәркәз-үзәге!

хуҗалык кирәк-яракларын **Иске Куак** хастаханәсенә юнь генә бәягә бирә. Моның өчен ата коммунист булган минем әтигә райком җыелышларында нык кына дөмбәсләү дә эләгә иде. Ә Максим Игнатьевич, киресенчә, тирә-як авылларның сәламәтлеген саклауда ярдәм иткән өчен әтигә рәхмәтләр әйтә, аны өенә кунакка алып керә һәм алар икәүләшеп чиста медицина спирты белән сыйланалар иде.

Шул ук вакытта Максим Игнатьевич үзе башлап җибәргән Бәкер курортының матди тормышына да туктаусыз ярдәм итеп торды. Әлбәттә, бу курортка әти җитәкләгән артель эшләп чыгарган кирәк-яраклар, җиһазлар аз җибәрелмәгәндер, дип уйлыйм.

Әле былтыр гына без шушылар турында Бәкер курортының иң талантлы баш врачы, әлеге сәламәтлек саклау үзәген Татарстан һм Россиядә генә түгел, ә бөтен дөнья күләмендәге биеклекләргә күтәргән, республикабыз һәм нефть оешмалары җитәкчеләренең, Татарстанның күренекле галимнәре, язучылары, сәнгать эшлеклеләренең якын дусты **Ибраһимов Фаяз Ибраһим улы** белән сөйләшеп, истәлекләргә бирелеп утырган идек. Аның бөтенләй көтмәгәндә, кинәт кенә мәңгелеккә китеп баруы барыбыз өчен дә шәхси фаҗига булды.

Бәкер курортының киләчәге өчен күңелдә бердәнбер яктылык калды — курорт язмышын Фаяз Ибраһим улының малае, шулай ук күренекле табиб Ибраһимов Марат Фаяз улы үз кулына алды. Курортны кабул иткәндә үк ул монда әтисенең бөтен эшчәнлеген түкми-чәчми дәвам итәргә сүз бирде. Ә бу инде безнең яраткан Фаяз әфәндегә бик зур рухи һәйкәл булачак.

Югарыда сөйләгәннәрне гомумиләштереп шуны әйтәсе килә — беренчедән, нефть белән күкерт Татарстанның игезәк табигый байлыклары икән, икенчедән, нефть өлкәсендә бөтен Татарстанга, Рәсәйгә, чит илләргә билгеле булган Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Бөгелмә, Баулы калаларының, атаклы Бәкер курортының данлы тарихы Шөгер ягының бүген әллә ни күзгә күренеп тормаган шушы дүрт авылдан — Сарабиккол, Карамалка, Шөгер һәм Бәкердән башлана! Кызганыч ки, бу кире каккысыз хакыйкатьне бүген дөньякүләм белгечләрдән алып, гап-гади замандашларыбызга кадәр оныта бара...

Ахыры киләсе санда

БӘКЕР КӨЗЕ

Газинур Морат

Вахит улы Зәмил якташка

Болдинода булганым юк ансы,
Болдинода, бәлки, булмам да.
Бәкер көзе белән сихәтләнәм,
Сихәтләнәм көзге буранда.

Көзге буран урау сукмакларны
Алтын тәңкә белән түшәгән.
Илһам көтеп ятар чак түгел бу,
Галәми сүз эзләп түшәмнән.

Монда бугай – Озын күл буенда
Хозурлыкның мәркәз-үзәге,
Һәр адымда кизләү күзләп тора –
Җирнең мөлдерәмә күзләре.

Озын күлне бишек иткән кошлар,
Сәфәр көтеп, канат кагына.
Яше-карты тауга күтәрелә,
Мең баскычлы Сөю тавына.

Сөю тавы хәтерлидер әле
Хан кызының кыйгач кашын да.
Гап-гади бер егет булган яры…
Кавышканнар шул тау башында.

Сөю тавы күккә якынайта,
Гел үзенчә күкнең дәвасы.
Хан кызына гашыйк булган килеш,
Шул тауларда иде каласы.

Көзге буран хан кызының юлын
Алтын тәңкә белән түшәсен.
Ә безгә шул, баскыч саный-саный,
Тау башыннан кабат төшәсе.

Ә дөньяның бездәй ялгызларын
Ике аккош көтә күлендә.
Ике аккош…
Димәк, бу җиһанда
Без дә бигүк ялгыз түгел лә.

Без дә бигүк ялгыз түгел бугай,
Парлы булган чакта аккошлар.
Илдә кышлый торган аккошларга
Һәр кушкаен җыру багышлар.

Без дә ялгыз түгел –
Илдә кышлар
Пар аккошлар әле булганда…
Бәкер көзе белән сихәтләнәм,
Сихәтләнәм көзге буранда.

Сәхифәне Татарстанның атказанган сәнгатъ эшлеклесе, күренекле музыкант Максат Гомәров алып бара.

ИҢ БӘҺАЛЕ МИРАС!

«Халык җырлары – безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле һәм иң бәһале бер мирастыр. Төзек Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирасны туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман халык күңелендә. Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бер нәрсә булганы өчен дә, аларга әһәмият бирергә, аларны югалтмаска кирәк».

Бөек Тукаебызның бу сүзләре һәммәбезгә дә васыять булып яңгырый.

Әйе, бу зур мирасны без кабул итеп алганбыз икән, аны тагын да тулыландырып, баетып, киләчәк буыннарга тапшырырга да бурычлыбыз! Дөньякүләм глобальләшү заманында бу аеруча әһәмиятле һәм актуаль!

Әмма дә, ни кызганыч, бүгенге көндә халык җырларының бик аз яңгыравы, кайберләренең бөтенләй үк онытылып баруы күзәтелә. Шул ук вакытта татар җырының «Алтын фонды»нда 500гә якын җыр саклана. Фондка кермәгәннәрен дә исәпләсәк, бу сан бермәбер артыр иде.

«Татар җыры» сәхифәсенең асылы да шунда — бу кыйммәтле мирасны — халык җырларын — сезгә тәкъдим итү. Татар халык җырының «Алтын фонды»н булдыру ул — төрле елларда иҗат иткән җырчы һәм музыкантларның, композитор һәм шагыйрьләрнең, һәвәскәр башкаручыларның, Татарстан радиосының музыкаль редакциясе, тавыш яздыру студиясе хезмәткәрләренең гаҗәеп күләмдә зур, хөрмәткә лаек фидакяр хезмәте! Халык җырларын башкару буенча шунысын әйтергә кирәк, шул ук бер җырны һәр башкаручы үз зәвыгыннан, ходай биргән сәләтеннән, профессиональ әзерлегеннән, тавыш мөмкинлекләреннән чыгып, үзенә генә хас булган милизмнар кулланып, моң өстәп башкара. Бу — табигый хәл һәм ул башкару редакциясе дигән музыкаль терминга туры килә.

Шәхсән үземнең 35 еллык иҗатым дәвамында бик күп халык җырларының төрле вариантларын ишетергә, тыңларга һәм җырчылар белән берлектә башкарырга, студиядә тасмага яздырырга туры килде. Шул тәҗрибәмнән чыгып, җырның колаерак дип тапкан, күңелгә якын бер вариантын, баянга кушылып җырлау өчен эшкәртеп, сезгә тәкъдим итәм.

Сәхифәне халкыбызда киң таралган һәм яратып башкарыла торган авыл көйләреннән башлыйбыз. Бу җыр Галия Гафиятуллина башкаруында беренчеләрдән булып тасмага язылала һәм бүгенге көндә әлеге язма Татарстан Республикасының Дәүләт архивында саклана. ■

Авыл көе



Һавалардан очып үтте
Күгәрчен көтүләре.
Әл(е) дә булса исләремдә
Сау бул, дип китүләре.
Әл(е) дә булса исләремдә
Сау бул, дип китүләре.

Кызарып кояш чыкканда
Нурлар төшә түтәлгә.
Күзем төшсә, күңелем төшми
Синнән башка бүтәнгә.
Күзем төшсә, күңелем төшми
Синнән башка бүтәнгә.

Урман буе — салкын чишмә,
Суын эчеп туймадым.
Аерылганда кул бирмәдем,
Күрешербез, дип уйладым.
Аерылганда кул бирмәдем,
Күрешербез, дип уйладым.

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

Йосыф Баласагуни – Кыргызстан Республикасы акчасында

ЙОСЫФ ХАСС-ХАҖИБ БАЛАСАГУНИ (1016/1021 еллар тирәсе — 1083?) — Караханид төркиләренең башкаласы *Баласагун* шәһәрендә туган (шәһәр урнашкан урын хәзер Кыргызстан җиренә керә). Аның имзасындагы «Хасс» һәм «Хаҗиб» сүзләре күңелгә ошатып сайлап алынган сарай хезмәткәре мәгънәсендә. Караханидлар дәүләтендә ул баш министр булып исәпләнгән.

Йосыф Баласагуни безгә борынгы уйгыр телендә шигырь белән язылган *«Котадгу белек»* китабының авторы буларак мәгълүм. Бу күләмле (6722 бәетле, ягъни кушыклы) әсәрен ул 1069 елда тәмамлаган һәм аны Кашгарның караханидлар идарәчесе Табгач Бугра ханга бүләк иткән. Әсәрнең исемен *«Бәхет турында белем»* дип тәрҗемә итәргә мөмкин. Н.Исәнбәт китапның исемен «Котазгу белик» рәвешендә яза һәм аны *«Котаю белеме»* дип тәрҗемә кыла. Башкорт галиме Әхнәф Харисовта — «Котлылык белеге»/«Бәхетле булу гыйлеме».

Бу әсәрендә Йосыф Баласагуни Аллаһның берлеге һәм Аның дөньядагы барча әйберләргә кадәр үк булганлыгы турында яза. Аннары Пәйгамбәрнең һәм аның дүрт яранының фазыйләтләрен санап чыга.

«Котадгу белек» дидактик характерда язылган һәм күп кенә иҗтимагый, әхлакый, фәлсәфи проблемаларны колачлый.

«Котадгу белек»тә башлангыч астрономик белемнәр бирелә. Мәсәлән, барлык зодиак йолдызлыклары һәм планеталар телгә алына. Автор Сатурн планетасының ул вакытларда билгеле булган башка планеталардан ераграк урнашканлыгын әйтә. Ул йолдызлар түгәрәк буенча хәрәкәт итәләр, кайчагында бер-берсе белән көрәшкә ташланалар һәм җиңелгән йолдыз күктән атылып төшә, дип исәпли. Автор Айның тулган чагы аның Кояшка

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

каршы вакытка туры килүен дә белә.

Баласагуни «Бер Аллаһ» кешене һавадан, судан, уттан һәм балчыктан яраткан, дип яза. Укучыны ул «һәрнәрсәдә чаманы белергә» чакыра. Аның бу китабында мул очраган гыйбрәтле сүзләрдән берничә үрнәк китерик. *«Кешене дәрәҗәгә күтәргән дә тел, түбән төшергән дә тел; тел аркылы бәхеткә ирешергә дә, башыңны җуярга да мөмкин». «Сүзеңне белеп әйт — башың исән булыр; телеңә хуҗа бул — тешең сынмас». «Кеше ике нәрсә аркасында картаймас: берсе — аның күркәм эше, икенчесе — күркәм сүзе». «Акыл күрке — тел, тел күрке — сүз, кеше күрке — йөз».*

Баласагуни гарәп һәм фарсы телләрен камил дәрәҗәдә белә, ул — үз заманы ирешкән фәнне һәм әдәбиятны өйрәнгән зыялы кеше. Китабында дәүләт төзелеше, фән, мәгърифәт, акыл-зиһен, кеше гомеренең мәгънәсе кебек мәсьәләләрне дә күтәрә.

Әсәрнең өч кулъязмасы сакланган, аларның иң камилен (Фиргանә яки Нәманган кулъязмасын) 1913 елда З.Вәлидов Нәманган шәһәрендә тапкан.

Төрки әдәбият үзенең барлыкка килүе һәм үсүе белән күп яктан Йосыф Баласагунига бурычлы. Үзбәк, азәрбайҗан, татар, казакъ әдәбиятлары аның куәтле йогынтысын тоеп үскәннәр. Татар шагыйрьләре Кол Гали, Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни һ.б. Баласагуни традицияләрен дәвам иткәннәр.

КАБАК КАПКАСЫ *тар.* — Казан шәһәренең бер капкасы (1552 ел). Урыс чыганакларында — *Кабакские ворота*. Аның манарасы да булган, дигән фараз яши («Кабацкая яки Кайбатская башня»). Атама Һади Атласида да очрый. Урыс чыганакларына караганда, мәскәүлеләр Казанны алган вакытта Кабак капкасы хәзерге Засыпкинская урамы тирәсендә булган. Ризаэддин Фәхреддиннең «Казан ханнары» китабына (Казан, 1995) язылган йомгаклау мәкаләсендә (Солтан Шәмси, «Казан — ханлык мәркәзе») капканың исемен *Күбәк, Көбәк сүзе* (кеше исеме) аркылы аңлатырга омтылыш бар, әмма андый аңлатуның хаҗәте юк. Кабак сүзе — борынгы сөйләмдә шәһәр капкасын белдергән һәм хәзерге мишәр диалектында ул *«капка»* мәгънәсенә ия (*күк кабагы ачылу — күк капусы ачылу* гыйбарәләрен искә төшерик). *Кабак-капка* сүзе мәкальгә дә кергән (*«кунак килә — кабак ач»*). Дөрес, Казанда хан кирмәненең бер капкасы, чыннан да, Кибәк капкасы дип аталган, менә шунысы *Кибәк бәк* исеменә бәйле булса кирәк.

Ихтимал, *кабак-капка* күз кабагы шикелле югары күтәрелеп ачыла торган булгандыр. Электә шәһәр капкасын саклаучы *кабакчы* дип аталган. Кабакчы шәһәргә килгән кешеләрнең кем булуын тикшергән, сәфәрчеләрне һәм сәүдәгәрләрне кәрван-сарайга яки махсус йортка озаткан. Урыслар бу йортның үзен дә *кабак* дип атаганнар. Кыскасы, әлеге капканы *«кабак-капка»* дип парлы сүз белән атау отышлырак сыман, чөнки ул өстәмә мәгълүмат бирә.

КАГАН *бор. төр.* — Баш хан, югары идарәче, каһан. Ләкин чыганакларда *каган кан* — югары, баш хан атамасы да очрый. Каган/каһан титулын урыс кенәзләре дә йөрткән. Мәсәлән, Ярослав Мудрый заманында Киев Русе *Киев каганаты (каһанлыгы)* дип, ә кенәз үзе «каган Ярослав Мудрый» дип аталган. Илен чукынырга мәҗбүр иткән Владимир Святославович та борынгы урыс чыганакларында «җиребезнең бөек каганы Владимир» дип атала («Учение о Ветхом и Новом законе», митрополит Илларион). «Слово о полку Игореве» дастанында урыс кенәзе Олег та «каган» дип аталган.

Я.А.Кеслер *каган/каһан* сүзен борынгы яһүд титулы *коган* белән бәйләргә тырыша. Һәрхәлдә, без *Каганович* фамилиясен *патша улы* («царевич») мәгънәсендә дип карый алабыз. ■

ҖАЕКМЫ, ЙАЙЫКМЫ?

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә («Безнең мирас», №5) Җаек елгасы турында шундый кызыклы җөмлә укыдым: «Башкорт телендәге Йайык атамасы урыс теленнән алынган (аларда ул Яик дип атала), ягъни башкортлар бу елганы соң белгәннәр булып чыга». Әлбәттә, моны авторның шәхси фикере дип тә кабул итәргә мөмкин, ләкин тарихи яктан да, тел ягыннан да, хәтта ки география күзлегеннән дә бу фикер белән берничек тә килешергә ярамый.

Иң беренче чиратта, бу сүзнең ике тугандаш халыкта ни өчен аерылып торуына ачыклык кертик. Билгеле булганча, татар теле гасырлар дәвамында формалашкан, үскән, үз эченә күптөрле элементларны алган. Мәсәлән, сөйләм (бигрәк тә кайбер диалектларда) һәм язма телебездә кайбер сүзләрнең й-лаштырып яисә җ-лаштырып куллану очракларын әйтеп узарга була: йомырка — [җоморка], елан — [җылан]. Урыслар кулланган «Зилантова гора», «Зилантов монастырь» сүзтезмәләре дә, «Зилант» үзе дә шул татар сүзенең сөйләм формасыннан килеп чыккан. Бу — күзгә төртелеп торган факт. Инде башкорт теленә килгәндә, аның әдәби һәм сөйләм телендә сүзләрне й-лаштырып әйтү һәм язу ешрак күзәтелә: татарча «җыр» башкортча «йыр»га, татарча «җыен» башкортча «йыйын»га әверелә. Шуңа күрә татар, казакъ телләрендә җ-лаштырып әйтелгән елга исеме (тат. Җаек) башкорт телендә й-лаштырып әйтелүе һәм язылуы табигый (башк. Йайык).

Инде авторның «башкортлар бу елганы соң белгәннәр булып чыга», дигән фаразы шулай ук тарихи фактларга каршы килә. Башкорт халкы асылда Урал таулары тирәсендә формалашкан. Аларның этник тарихларында аерым туктамыйча (теләгән кешеләр башкорт халкы турында саллы хезмәтләр укый ала) шуны гына әйтергә телим: Урал таулары тирәсендә башкортлар элек-электән яшәгән булсалар, урыслар Көньяк Урал территориясенә һәм казакълар яшәгән далаларга соңрак килеп чыга. Шуңа күрә, Урал тауларыннан агып чыккан елгалар турында башкортлар элегрәк белгәннәр, бу башкорт халык авыз иҗатында да яхшы күренә. Шул исәптән, XVIII гасырда барган урыс колониаль хәрәкәт чорында Оренбург губернасы территориясендә барлыкка килгән ныгытмалар һәм шәһәрләре, авыллар һәм бистәләр, нигездә, моңа кадәр башкортлар һәм казакълар яшәгән җирләрдә урнашкан була һәм моны Мәскәү, Оренбург, Петербург архивларында сакланучы күп кенә документлар раслый. Кыскасы, Җаек турында башкортлар һичничек тә урыслардан белә алмаган. Бәлки, киресенчә, «Яик» атамасы җирле халыклардан «үзләштерелгәндер» әле.

Бу кечкенә мәкаләмдә хөрмәтле эзтабар, публицист-галим һәм язучы Адлер Тимергалинны һич тә хурлыкка калдырырга, аны кимсетергә ниятләмәдем. Теләгем бер генә: хатаны төзәтү, аңа журнал укучыларының игътибарын җәлеп итү иде.

Әскәр Гатин,
тарих фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының Татар халкын өйрәнү һәм тюркология кафедрасы доценты.

СЫРЛЫ БӘЛӘК

(ТР Милли музее фондларыннан)

Сырлы бәләк ярдәмендә хатын-кызлар кер үтүкләгән. Озынча агачның бер очында тоткыч урнашкан, бер ягында аркылыга түгәрәкләнгән сырлар ясала, ә икенчесенә төрле бизәкләр төшерелә. Кул белән сыгылган керне уклауга чорнаганнар һәм сырлы бәләк белән тәгәрәткәннәр. Керне шулкадәр тәгәрәткәннәр ки, әйбәтләп юылмаган киемнәр дә чистарганнар.

Этнографлар сырлы бәләкләргә төшерелгән бизәкләр ярдәмендә аны нинди халыкка һәм кайсы төбәккә хас булганын әйтә. Славян халыкларында сырлы бәләк уен коралы булып та кулланылган. Аның өчен бәләкне кыскарак, сырларын очлырак ясаганнар, ә көй матуррак чыксын өчен бер кырыеннан тишек тишкәннәр. Хәзер дә кайбер халык оркестрларында андый уен кораллары очрый.

***Гүзәлия Җәләлева** әзерләде.*

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның июль ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мөфти сайлау мәсьәләсе

Бүген «Болгар» залында көндезге 2 сәгатьтә шәһәр имамнары һәм мәхәллә вәкилләренең мөфтилеккә нинди кеше билгеләнүе мәслихәт икәне хакында мөзакәрә [фикер алышу] вә бу урынга кемне билгеләү мәслихәт булачагы хакында мөшавәрә [киңәшләшү] мәҗлесе булачак. Мәҗлеснең җаваплы рәисе Хисаметдин ахун Габделгаффаров булып, мәҗлескә һәр мәхәлләдән берәр имам иштиракь итәчәк [катнашачак]. Өченче көн һәр мәхәлләдә бу мәҗлескә иштиракь итәр өчен мәхәллә тарафыннан вәкилләр сайланган. Төрле мәхәлләләр тарафыннан вәкил сыйфатында ихтияр ителгәннәрдән бәгъзеләре болардыр: Әҗем мәхәлләсеннән Мифтахетдин Габделмәнов, Исмәгыйль Ибраһимов, Ак мәсҗед мәхәлләсеннән Галим Галиев, Садыйк Галикәев, Зәңгәр мәсҗед мәхәлләсеннән Мөхәммәтҗан вә Җамали хафизлар, Кызыл мәсҗед мәхәлләсеннән Хәйрулла читекче белән Әхмәдгәрәй Нагаев. Башка мәхәлләләр дә үзләре мөнасиб күргән адәмнәрен сайлаганнар.

Кояш. —1915. — №750. — 12 июль.

Мосафир

Гаскәриләр вә гаиләләренә ярдәм өчен тәшкил ителгән мувәкъкать [вакытлы] мөселман комитетының вилаятьләргә чыгарган вәкиле Габдулла әфәнде Шонаси[1] җәнаплары шәһәребездә мосафирдыр. Шәһәребездә берике көн калганнан соң, Габдулла әфәнде Пенза вә Самара вилаятьләренә китәчәк һәм андагы мөселманнар арасында да комитетның шөгъбәләрен ачтыру тәшәббесендә[2] булыначак.

Кояш. — 1915. — №752. — 14 июль.

Мәкәрҗәдә купеческий номерлар

Мәрхүм Әхмәт байның[3] мәдрәсәи «Мөхәммәдия» файдасына калдырган вәкыф номерлары бу ел иҗарәчеләр [арендаторлар] кулыннан алынып, мәдрәсәнең үз хисабына ачылды. Ярминкәнең иң уртасында вә һәр җәһәттән мөкәммәл хәзерләнгән булып, төшүчеләрне мәмнүн итәрлек булган бу номерларга мөхтәрәм мосафирларның илтифатларын җәлеп итәбез.

Мәдрәсәи «Мөхәммәдия» назыйре Әхмәдгәрәй Әҗимов.
Кояш. — 1915. — №756. — 20 июль.

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Габдулла Шонаси — Габдулла Сабир улы Ибраһимов (1885-1938), педагог, табигать һәм физика-математика дәреслекләре авторы.

[2] Тәшәббес — бер эшкә тотыну, керешү.

[3] Әхмәт бай — Әхмәт Мөхәммәтгали улы Хөсәенов (1837-1906), сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче. Аның Мәкәрҗә ярминкәсендә һәм Оренбургта зур кунак йортлары була.

Бәйрәм хөрмәтенә

Мәҗрух гаскәриләр вә аларның гаиләләренә ярдәм өчен ачылган Петроград мөселман комитетының рәисе, идарәханәбезгә мөрәҗәгать итеп, имамнарның гаеттә мәзкүр комитет файдасына иганә җыюларын үтенәдер.

Башланган эшнең юлда калдырылмавы наменә, гомум мөселманнар исеменнән ачылган бер мөәссәсәнең [оешманың] ярдәмнән гаҗиз булмавы наменә без имамнарны мөселман комитеты рәисенең бу мөрәҗәгатен игътибарсыз калдырмаска дәгъват итәбез.

Тантаналы гыйбадәткә җыелган күп меңләр мөселманнар үзләре өчен авыр булмаслык бик аз-аз тиеннәрне генә иганә итсәләр дә, күп куллардан тамган бу тамчылар шактый зур бер күл ясарлар вә шулай итеп мөселман комитетына чынлабрак эш күрә башларга имкян [мөмкинлек] бирерләр. Халкыбыз да гает көне хакы вә хөрмәте өчен яңадан бер юмартлык күрсәтүдән имтинаг итмәсәләр [баш тартмасалар] кирәк.

Моннан башка әле без казанлыларның да үзебезгә хаслап ачкан лазаретыбыз бар бит. Лазарет мөтәвәллиләре халыктан гает көннәре хөрмәтенә үз лазаретыбызда ята торган мәҗрух Ватан каһарманнарын хәтерләренә алуны үтенәләр. Мөселман лазаретында ята торган мәҗрух гаскәриләргә гаеткә махсус һәдияләр [бүләкләр] илтеп, аларга бу көннәрнең мөселман бәйрәмнәре икәнен хис иттерергә тиештер. Мөселманнар шатланган бу көндә, мөселманнар химаясенә сыгынган мәҗрухларны шатландыру, аларның авырулык белән үтә торган әчпошыргыч көннәренә төрлелек бирү вазифабыздыр.

Өмид итәбез, Казан мөселманнары бәйрәм хөрмәтенә бу ярдәмнәрне итеп, тагын бер кат үзләренең каһарман гаскәребезгә булган мәхәббәтләрен изһар итәрләр [күрсәтерләр].

Бәйрәмдә театр

Бәйрәм эчендә җомга көн 31 июльдә Новый клубта «Сәйяр» труппасы тарафыннан татарча спектакль куелачак. Тамашага Фатих Әмирханның әсәре — өч пәрдәлек «Тигезсезләр» пьесасы белән А.К. әсәре[4] — бер пәрдәлек «Ирем кайтты» дигән әсәр куелачактыр. Урынның бакчалы, татар көйләре уйнаучы музыка булуы белән бергә артистлар тарафыннан да тамашаның бәйрәмгә муафикъ булачагы вәгъдә ителәдер. Уен кичке 8 сәгатьтә башланачак. Билетлары хәзер дә сатыладыр.

Немецчә сөйләшергә ярамый

Шәһәрнең һәммә кибетләре һәм гомум һәркем керергә ярый торган урыннарга, мөәссәсәләр [оешмалар] ишекләренә русча: «Немецчә сөйләшү катгыя мәмнугъ [тыелган]» дигән мәзмунда [эчтәлектә] кәгазьләр — плакатлар ябыштырылган.

Кояш. — 1915. — №761. — 28 июль.

[4] А.К. әсәре — әсәрне Кәрим Апанаев русчадан ирекле тәрҗемә иткән.

Җүләр балык



Таҗи Гыйззәт гаиләсе белән Юхмачыга, Әлки ягына кунакка кайта, ял арасында пьеса өчен материал да җыймакчы була. Шушы эшләр арасында ул һәрвакыт Кече Чирмешән елгасына балыкка йөри. Болар кунак булып төшкән йортка Заһидулла исемле тагын бер кеше ялга кайткан була. Заһидулла абзый гомере буе кармак салып карамаган, хәтта балыкка йөргән кешене эшлексезгә саный торган адәм икән. Таҗи Гыйззәт исә Заһидулла абзыйны балыкка барырга тәки күндерә бит!

Су буена килеп җиткәч, бер чыбык табып, җеп-кармак тагып, Заһидулла абзыйга тоттыра да:

– Син, Заһидулла, миңа бик якын утырма, һава бик тыныч, икәү утырсак, балыкларны куркытырсың, – ди.

Заһидулла абзый йөз адымнар читкә китеп, кармагын суга ташлый да, исе китмичә генә, Таҗи Гыйззәтнең «юк эш» белән шөгыльләнгәнен күзәтә башлый. Гыйззәт булыр-булмас кечкенә алабуга, кызыл канатлар, чабаклар каптыра да савытына салып куя. Заһидулла абзыйны күзәтеп тору шөгыле дә ялкыта. Ул иренеп кенә үз кармагын тартып карый: кармак чыкмый. Төпкә эләккән ахрысы, дип уйлый Заһидулла абзый, ныграк тартып карый — зур гына балык капкан.

– Та-җи-ий! – дип җир селкетеп акыра башлый Заһидулла абзый. – К-апты-ы!

Куркуыннан, каушавыннан Заһидулла абзый зур гына корбан балыгын ярга сөйрәп чыгара. Гыйззәт атылып килеп тә җитә. Кеше тоткан шулкадәрле зур балыкны күреп, кайсы балыкчының гына күзе кызмас икән?! Кайсы балыкчының гына күңеле кымырҗымас икән?!

– Ничек капты бу сиңа? Ничек ала алдың син мондый зур балыкны? – дип хәйран кала Таҗи Гыйззәт.

Юлда кайтканда да Таҗи Гыйззәт корбан балыгына карап- карап ала да:

– Ничек капты бу сиңа, ә? Ничек ала алдың син моны, ә? – дип куя. – Җүләр балык булгандыр ул. Җүләр булмаса, беренче тапкыр кармак салучыга килеп капмас иде...

Шул көннән соң әлеге Заһидулла абзый ата балыкчы булып киткән, дип сөйлиләр.

Ширияздан Сарымсаков
хатирәләреннән.

Батулланың «Тузга язмаган хәлләр» китабыннан.

Мирасворд

Шагыйрь Наис …

Мәче башлы ябалак (диал.)

Шәехзадә …

Жырларга кергән елга

Язучы … Рәфыйков

Ерткыч җанвар

Озынча кәрҗин сыман зур әрҗә

Мәхмүт Хәсәновның нефтьчеләр тормышы турындагы романы

Эгей диңгезендәге утрау

Татарстандагы нефть чыганагы

1907-1921 елларда Казанда эшләгән нәшрият

Дару (иск.)

… Гали, … Шәриф

Амаяк …

Иранда авырлык үлчәү берәмлеге

Нигериядәге шәһәр

Финляндиянең җирле атамасы

Административ-территориаль берәмлек

Әңгәмә, сөйләшү

Киләсе ел (диал.)

Аудару

Нефтьтән алына торган машина ягулыгы

Тау тәкәсе

Татарстанның нефтьчеләр башкаласы

Морза, түрә

… Мартин (Пуэр-то-Рико җырчысы, актер)

… Ши Мин

Бурят эпосы

Беренче татар газетасы

Кытай шашкасы

«Гөләндәм туташ хатирәсе» романы авторы

Драматург Шаһи-морат …

Камыштан ясалган үзбәк курае

Монгол кылычы

«…, яки гамәл вә җәза» романы (Р.Фәхретдин)

Ояда калдырылган йомырка

Чилидагы елга

Гарәп хәрефе

Ыргы (иск.)

Мал - …

… карлыгачы

Рәис Габдулла төзеде.

6 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Ганс, Ижау, Саба, анар, әләм, Нерис, келт, га, Әмәт, уа, фырт, Дейл, яки, «Сәвилә», илә, «Елантау», оби, Регул, Яков, Вито, әмма, Галиев, ир, Балтай.

Өстән аска: әтәч, ялик, әкә, Кабо, Хисаметдинов, Геб, Жан, Сабантуй, Хәлил, Нуаре, «Алсу», мирт, Ломе, Гыйниятов, вату, Ги, Гыйлаев, Каф.

Казан һәм Казансу. 1950 нче еллар

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / июль

- **115 ел элек (1900)**

22 июльдә мәшһүр математик Хәмид Мозаффар улы Мөштәри (1900-1981) дөньяга килә.

- **110 ел элек (1905)**

28 июльдә күренекле тюрколог, Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт Чагатай (1905-1989) дөньяга килә.

- **95 ел элек (1920)**

25 июльдә Уфа каласында беренче мәртәбә Гафур Коләхмәтовның «Кызыл һәм кара» («Ике фикер») драмасы уйнала.

- **90 ел элек (1925)**

8 июльдә Шамил Усмановның «Памирдан радио» исемле фантастик повесте «Эшче» газетасында басыла башлый.

- **85 ел элек (1930)**

29 июльдә Мәскәүдә Кызыл Армия һәм Кызыл Флот язучылары берләшмәсе — «ЛОКАФ» төзелә. Татарстаннан Үзәк идарәгә Кави Нәҗми белән Мирсәй Әмир сайлана.

- **80 ел элек (1935)**

30 июльдә Казан янындагы хәрби лагерьда Татарстан язучылары Союзы сугышка каршы әдәби кичә оештыра. Кичәне Кави Нәҗми ачып җибәрә.

«Совет әдәбияты» журналында Галишәр Нәваинең «Фәрһад һәм Ширин» поэмасыннан «Фәрһадның тууы» исемле өзеге басыла. Үзбәкчәдән Әхмәт Исхак тәрҗемәсе.

- **65 ел элек (1955)**

«Совет әдәбияты» журналында Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романы басыла башлый.

- **45 ел элек (1970)**

Памир тавындагы бер пикка Муса Җәлил исеме бирелә.

- **20 ел элек (1995)**

«Мәдәни җомга» газетасының беренче саны дөнья күрә.

РАДИК МИНҺАҖЕВ

«Авыл бәйрәмендә»
Киндер, майлы буяу. 2015 ел

Радик Вакыйф улы Минһаҗев 1963 елның 4 июлендә Әлки районының Карамалы авылында дөньяга килә. 1982 елда Казан сәнгать училищесын, 1990 елда Харьков сәнгать-сәнәгать институтын тәмамлый.

Радик Минһаҗев — Татарстанның (2000) һәм Россиянең (2004) Рәссамнар берлеге әгъзасы, Чистай каласында яши. Рәссамның әсәрләре шәхси һәм дәүләти тупланмаларда саклана.

«Яз исе килә».
Киндер, майлы буяу. 2008 ел



«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ АЛДАГЫ САННАРЫНДА МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ МОҢАРЧЫ БИЛГЕЛЕ БУЛМАГАН ШИГЫРЬЛӘРЕ ҺӘМ АЛАРНЫ САКЛАП КАЛГАН ГОБӘЙДУЛЛА САЛИХОВНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ БЕЛӘН ТАНЫША АЛАСЫЗ!

«1942 елның октябрендә безне эшелонга төяп Польшага озаттылар, Седлец шәһәрендәге хәрби әсирләр лагерена алып килделәр. Монда мин якташым, татар шагыйре Муса Җәлил белән таныштым. Аның алты шигырен күчереп алу мөмкинлеге булды. «Дустым хисе», «Дустыма», «Сөйгән дустым», «Озатып калучы», «Туган ил сулары» һәм «Картлык». Мин аларны алып кайттым һәм әле дә үземдә саклыйм. 1943 елның февраль аенда Седлец шәһәрендәге лагерьда башкисәрләр Муса Җәлилне һәм тагын бер кешене кулга алды (фамилиясен хәтерләмим). Беренче көнне лагерь капкасы янында, капка сакчылары күзәтүендә, көне буе гимнастёркада гына тоттылар. Көн салкын иде, төньяк-көнбатыштан бертуктаусыз салкын җил исте. Алар сикергәләп җылынырга тырышты, арып, карга егылдылар. Әмма аларны кабат басарга мәҗбүр иттеләр. Икенче көнне шул ук урында, бу юлы шинель кигәннәр иде, кулларына икешәр кирпеч күтәреп тордылар. Өченче көнне инде без аларны күрмәдек...»
РӘЗИН НУРУЛЛИН. «АККА КАРА ТӨШСӘ, ЮГАЛМЫЙ...»

Индекс:
Татарстанда – 54132
Россиядә – 70275
www.beznenmiras.ru

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман урамы, 29/11) кибетеннән сатып алырга мөмкин.

4 612750 670172

№07 / 2015